Таким образом, «Şi:ri:n» (**شيرين**) – Истина, Правда, а Перхат – это влюбленный, который проходит испытания в поисках Истины. «Ширин-Перхат» вместе означают *сладкую истину*.

По отдельности эти имена не могут дать того общего значения. Это связано с влиянием языка художественной литературы на объединение этих значений. Лингвистический язык не есть то же самое, что и художественный язык. Язык художественной литературы в своих рамках дает два значения, поэтому анализировать значения имен, появившихся в рамках художественных произведений, в отличие от других имен, нужно проводить совместно с анализом произведения. Собственно, изучение литературы отдельно от языка и языка отдельно от литературы все равно, что жить в доме без крыши или фундамента.

Таким образом, рассмотрев особенности именования близнецов у туркмен, можно прийти к следующим выводам:

1. Именование близнецов, исходя из художественной литературы. Здесь, в основном, должны учитываться смежные понятия в именах героев. Особенность, присущая востоку.

2. Согласно туркменскому менталитету обозначение имен близнецов в виде законченной мысли или словосочетания: Эзиз, Дунья/Дунья, Эзиз (называют разнополых близнецов, имея в виду драгоценность мира); Абат, Дунья/Дунья, Абат (называют девочек-близнецов, желая иметь крепкий мир); Мукам (Мукамлы), Мекан (называют мальчиков-близнецов, представляя страну всегда цветущей, как весна) и другие.

3. Сохранение фонетической созвучности в именах близнецов: Хабыл-Кабыл, Гулайым-Мылайым.

В целом, в туркменском языке имена близнецов связаны с антропонимами, которых можно объединить в единую форму.

**Литература**


1. Атаниязов С. Как тебя зовут? – Ашхабад, 1978.
2. Атаниязов С. Этимологический словарь. – Ашхабад: “Мирас”, 2004.
3. Борисов И.В. Антропонимы, как картина личности. – М., 2016.

*Гыйлаҗев Таһир Шәмсегали улы*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Gilazov Tagir Shamsegalievich*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

# КАЗАН ТЮРКОЛОГИК МӘКТӘБЕНЕҢ КҮРЕНЕКЛЕ ВӘКИЛЕ ҖАМАЛ ВӘЛИДИ ГЫЙЛЬМИ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ ТАТАР ТЕЛ ГЫЙЛЕМЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ
# PROBLEMS OF TATAR LINGUISTICS IN THE SCIENTIFIC ACTIVITY OF THE FAMOUS SCIENTIST OF THE KAZAN TURKOLOGICAL SCHOOL JAMAL VALIDI

Аннотация. *Мәкаләдә Казан тюркологик мәктәбенең күренекле вәкиле Җамал Вәлидинең татар тел белеменең актуаль мәсьәләләрен яктырткан хезмәтләре тикшерелә. Галимнең милли тел, аның баскычлары һәм үсеш үзенчәлекләре хакындагы гыйльми карашлары өйрәнелә. Җ. Вәлидинең татар теле морфологиясе, синтаксисы, диалектологиясе һәм башка тармакларны формалаштыруга һәм аларның үсешенә керткән өлеше билгеләнә. Шулай ук тел гыйлеме өлкәсендә актив эшләгән аерым галимнәрнең эшчәнлеге хакындагы бәя һәм хөкемнәре игьтибарга алына.*

Abstract. *The article examines the scientific works of the famous representative of the Kazan Turkological School Jamal Validi, which highlighted the current problems of Tatar linguistics. The theoretical views of the scientist on the history of the national language are studied, his point of view on the features of the development of the language. The contribution of the scientist to the formation and formation of the morphology, syntax and dialectology of Tatar linguistics is estimated. And also the subject of this article is the work of J. Validi, dedicated to famous linguists.*

Төп төшенчәләр: *татар тел гыйлеме, морфология, синтаскис, диалектология, үсеш, милли тел.*

Keywords: *Tatar linguistics,, morphology, syntaskis, dialectology, development, national language*

XX гасырның беренче утызеллыгында әдәбият белеме тармагында нәтиҗәле эшләгән күренекле галим Җамал Вәлиди тел гыйлеме үсешенә дә зур өлеш кертә. Казан тюркологик мәктәбе вәкиленең киңкырлы гыйльми эшчәнлегендә әдәбият фәненең лингвистика белән тыгыз бәйләнеше күзәтелә. Әдәби тел тарихы, татар теленең грамматик төзелеше, орфография һәм лексикология, диалектология һәм шивә-сөйләш үзенчәлекләре мәсьәләләрен яктырткан хезмәтләре аны күренекле тел галиме һәм тюрколог итеп таныта. Җ. Вәлидинең милли әдәби телнең үзгәреш тенденцияләре, үсеш баскычлары һәм юллары хакындагы гыйльми күзаллаулары бүген дә кыйммәтен югалтмаган. Мәсәлән, ул «Татар телен эшләү мәсьәләсе» дигән мәкаләсендә 1905 елгы инкыйлаб XIX – XX гасыр чикләрендә көчәеп киткән төрекчелек фикере аркасында «гомуми төрекчә» шәкелен алган

телне татарчалашырга мәҗбүр итә, «әдәби тел биреп», «татарчаның нигезен, беренче катын салып, мөстәкыйль бер әдәби тел хәлендә тәбәлли иттерә» [Вәлиди, 2007: 154] дигән караштa тора.Телнең формалашу юлын конкретрак аңлату максатыннан ул «күңел теле»н (әдәби тел. - Т.Г.) һәм «гакыл теле»н (фәнни тел. - Т.Г.) аерып чыгара. Татар теле үсешенең беренче баскычы булган «күңел теле»нең халык һәм алар арасыннан чыккан язучылар һәм шагыйрьләр тарафыннан эшләнүен ассызыклый. Ә «гакыл теле» «үзеннән-үзе генә эшләнми», ул акыл көче сорый: «Гыйлем һәм фән кәсеп белән табылган кебек, аның теле дә уйланып, тикшеренеп, эзләнеп ясала» [Вәлиди, 2007: 153]. Фәнни телне эшләүдә максатлы рәвештә алып барылган гыйльми эшчәнлек этабын Җ. Вәлиди милли тел формалашуның икенче баскычы буларак карый.

Галим кешелек җәмгыятендә тел һәм аның фәненең барлыкка килү һәм үсеш тарихына иҗтимагый-мәдәни яссылыкта кыскача күзәтү ясаган кереш өлешендә «Татар теленең грамматикасы» (1919) китабының «татар телен фәнни тикшерүгә, фәнни сарыф һәм нәхүләр төзүгә нәүбәт килеп җитү» [Вәлиди, 2007: 22] ихтыяҗы белән язылуын билгели. Гарәп филологиясе, тюркология һәм рус тел гыйлеме өлкәсендәге тәҗрибәләргә нигезләнеп язылган хезмәттә татар теленең фонетик системасы, морфологиясе һәм синтаксисы каралып, тел фәненең гыйльми концепциясен эшләү омтылыш ясала. Җ. Вәлиди татар телендәге сүз төркемнәрен исем, фигыль, хәреф дигән өч төркемгәбүлеп, исемгә зат, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлыкларны кертеп карый. Фигыльне мөстәкыйль сүз төркеме дип аерып чыгарып, аның масдар (исем), боерык фигыль, хәбәр (хикәя) фигыль, иярчен фигыльләр (шарт, хәл) ярдәм фигылләре кебек төрләрен күрсәтә. Гарәп грамматикасындагы хәреф төшенчәсен элемтәгә алыштырып, аның эчендә тагылмалар, ярдәмлекләр, бәйлекләр кебек ярдәмче сүз төркемнәрен билгели. Тагылмалар эчендә килеш кушымчалары, сыйфат һәм рәвеш ясагыч кушымчалары каралса, бәйлекләр төрендә бүгенге грамматикадагы теркәгечләр, ярдәмлекләрдә башлыча кисәкчәләр өйрәнелә. Сүз төркемнәренең морфологик үзечәлекләре шактый тулы яктыртылса да, гарәп грамматикасы белән рус грамматикаларына турыдан-туры нигезләнү хезмәттә шактый буталчыклар китереп чыгарган.

Җ. Вәлиди татар телендә бәйләнеш үзенчәлекләрен билгеләүдә сүзтезмәләр нигез итеп ала һәм аларның төрләрен: аеру тәркибе, теркәү тәркибе, хөкем тәркибләрен күрсәтә. Җөмләнең баш кисәкләреннән ия һәм хөкемне (хәбәрне. – Т.Г.), тәмамлыклар (төшем, кучем, юнәлеш, юлдаш), хәлләрне тәмамлык эчендә тикшереп, урын, вакыт, сәбәп, максат, рәвеш тәмамлыкларын аерып чыгара. Галимнең татар телендә кушма җөмләләрнең тезүле һәм ияртүле бәйләнеш ярдәмендә оешуы, иярчен һәм баш җөмләләр танылып, аның баш җөмләгә ияру чаралары ассыклану хакындагы карашлары тел гыйлемен үстерүдә зур роль уйныйлар. Әмма кушма җөмләләр һәм аларны классификацияләүдә системалылык күзәтелми. Мәсәлән, ул кушма җөмләдәге иярчен җөмләләрнең функциясенә карап төрләрен билгеләмичә, аларның барысын бергә өйрәнә һәм

уналты төрен күрсәтә. Җөмләләре үзара бәйләү (тезүле. – Т.Г.) юлы белән ясалган кушма җөмләләрнең егерме өч төре аерып чыгарыла. Җ. Вәлиди фикерләрендәге каршылык, беренчедән, телнең сүз төркемнәре һәм җөмлә кисәкләре бүленешендә төгәллек булмау һәм, икенчедән, иярчен җөмләләрнең бары тик синтетик төрен генә тану белән бәйләнгән. «Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди һәм Г. Алпаров бары тик менә без шушы синтетик дип атаган җөмләләрне генә иярчен җөмлә дип тикшергәннәр. Бу галимнәр аналитик иярчен җөмләләрне башта аера алмаганнар, кайберләрен тезмә кушма җөмлә эченә кертеп караганнар» [Зәкиев, 2005: 227].

Җ. Вәлиди, татар теленең диалектларын өйрәнүнең иҗтимагый-гыйльми әһәмиятен тирән аңлап, җирле сөйләшләрне максатчан һәм системалы тикшерүне башлап җибәрә. Эзләнүләр һәм күзәтүләр нәтиҗәсендә язылган «Казан татар теленең диалектлары» (1927), «Нократ һәм Глазов татарлары арасында» (1929) һ.б. хезмәтләре «диалектларны өйрәнү тарихында аерым бер этапны чагылдыралар, шул чорның актуаль ихтыяҗын канәгатьләндерәләр, башлангыч фәнни ачышларны теркиләр» [Баязитва, 2005: 105]. Җ. Вәлиди диалектологлар тарафыннан танылып, алга таба үстерелгән «казан татары» (урта диалект), «мишәр» (көнбатыш диалект), «Уфа-Урал» (көнчыгыш диалект) шиваләрен, аерым диалект эчендәге сөйләшләрне аерып чыгара һәм аларга «фонетика, морфология һәм лөгать җәһәтеннән характеристика» бирә. Лингвист галим озак еллар дәвамында фидакарьләрчә тырышлык белән татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзи. Әмма татар лексикография фәненең казанышларыннан саналырга хаклы булган әлеге күп томлы хезмәтнең, мәгълүм сәбәпләр аркасында, «Татар теленең тулы сүзлеге» (1927, 1929) исеме белән ике китаптан торган кечерәк бер өлеше генә чыгып кала.

Татар тел гыйлеме үткән юлны барлап, аны үстерүгә зур өлеш керткән галимнәрнең хезмәтләрен бәяләү Җ. Вәлидинең лингвистик эшчәнлегенең бер тармагы булып тора. Аның «Галимҗан Ибраһимовның тел мәйданындагы хезмәтләре» дигән мәкаләсе Г. Ибраһимовның күптармаклы эшчәнлегенең 20 еллыгына нисбәт итеп языла. Җ. Вәлиди элгәрге грамматикаларга кыскача күзәтү ясап, Ибраһимов төзегән татар теле грамматикасының үзенчәлекләрен аерып күрсәтә. «Татар сарыфы»ның гамәли кыйммәте татар мәктәбе өчен язылып, «чын татарча грамматика» булуда билгеләнә. Гарәп һәм урыс граммтикаларына нигезләнеп эшләнгәндәреслекләрдән аермалы буларак, анда авазлар хакындагы өлешнең төшерелеп калдырылуы, морфологик үзенчәлекләргә нигезләнеп сүз төркемнәре саны һәм аларның атамалары яңача тәкъдим ителү югары бәяләнә. «... мин Галимҗанга монда грамматика дәреслеге язучылардан берсе итеп тукталмыйм. Бәлки, бездә бу мәйданда зур реформа кертүчеләрнең берсе, безнең бу юлдагы зур маякларның берсе итеп тукталам. Бу яктан караганда, Галимҗанның беренче хезмәтләре бигрәк әһәмиятле. Моннан соң бу турыда нинди генә шәп әсәрләр язылмасын, нинди генә яңалыклар кертелмәсен, Галимҗанның сарыф һәм нәхүләре үзләренең тарихи әһәмиятен югалтачак

түгелләр» [Вәлиди, 2007: 171]. Җ. Вәлиди Г. Ибраһимовның лингвистик хезмәтләренә, фәннилек белән объектив якын килеп, югары бәя бирә.

Казан тюркологик мәктәбенең күренекле вәкиле Җамал Вәлиди гыйльми хезмәтләренең бер шәлкеме татар тел белеменең актуаль мәсьәләләрен тикшерүгә багышланган. Галимнең милли тел, аның баскычлары һәм үсеш үзенчәлекләре, хакындагы гыйльми карашлары бүген дә үз фәнни кыйммәтләрен югалтмаган. Җ. Вәлиди татар тел гыйлеменең морфология, синтаксис, диалектология кебек тармакларын формалаштыруга һәм аларның үсешенә зур өлеш кертә. Шулай ук тел гыйлеме өлкәсендә актив эшләгән аерым галимнәрнең, мәсәлән, Г. Ибраһимов фәнни эшчәнлеге хакындагы бәя һәм хөкемнәре игътибарга лаек.

**Әдәбият**


1. Баязитова Ф.С. Җ.Вәлидинең диалектология фәненә караган эшчәнлеге // Җамал Вәлиди – энциклопедист галим: республика фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2007. – 104–112 б.
2. Вәлиди Җ. Сайланма хезмәтләр. – Казан: Мәгариф, 2007. – 271 б.
3. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен д-лек. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.



*Денмөхәммәтова Эльвира Николаевна*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Denmukhametova Elvira Nikolayevna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia


## ТАТАР ТЕЛЕННӘН РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘДӘ ТРОПЛАРНЫҢ БИРЕЛЕШЕ
## WAYS TO TRANSFER TROPES IN TRANSLATIONS FROM TATAR INTO RUSSIAN


Аннотация. *В работе рассматриваются вопросы переводатроповв художественных текстах с татарского языка на русский. Дается информация овариативности в переводном материале, приводятся разные способы перевода.*

Annotation. *The article deals with the translation of tropes in literary texts from Tatar into Russian. Information about the variability in the translated material is given, different methods of translation are given.*



Ключевые слова. *Перевод, татарский язык, русский язык, троп, способы перевода.*

Keywords. *Translation, the Tatar language, the Russian language, language, methods of translation.*


Элек-электән матур әдәбият тәрҗемәсен аерым сәнгать төре буларак кабул иткәннәр. Хәзер дә тәрҗемә белемендә матур әдәбият тәрҗемәсе башка тәрҗемә төрләренә каршы куелып өйрәнелә. В.Н. Комиссаров фикеренчә, матур әдәбият

тәрҗемәсен башкарганда тәрҗемәченең төп максаты – ул сәнгать образын булдырганда, билгеле эстетик йогынтыга ирешергә [Комиссаров 1990: 95]. Матур әдәбиятның үзенчәлеге моның белән генә чикләнми. Моннан тыш әдәби әсәрләр һәрбер язучының үзенә генә хас булган стилен чагылдыралар. Ул җөмлә төзелешендә дә, сүзләр һәм сурәтләү чаралары кулланышында да күренә. Матур әдәбият тәрҗемәсенең беренче шарты буенча, тәрҗемәче бер телдән икенче телгә текстның тел билгеләрен генә түгел, ә аларның аерым һәм икенче сүзләр белән бергә тудырган художестволы функцияләренкүчерергә тиеш – дип әйтә Т.А. Казакова үзенең «Художественный перевод» хезмәтендә [Казакова 2002: 13]. Моннан тыш аларны укучыга дөрес итеп, адекват рәвештә тапшыра белергә дә кирәк.

Халыкның төп үзенчәлекләрен чагылдырган лексик сурәтләү чараларын – тропларны тәрҗемә иткәндә 4 төрле ысул кулланыла:

1) Эквивалент тәрҗемә – тропның икенче телдәге тулы эквивалентын табып тәрҗемә итү. Күпчелек телләрдә бер үк мәгънәгә ия булган, ләкин икенче образлар ярдәмендә бирелә торган троплар очрый. «***Ишекләр ачык»*** (В.Җ.Д.: 107) – «***Открыты двери»*** (С.В.Т.: 171); «***Тормышның авыр, каты мәктәбен үткән»*** (В.Җ.Д.: 112) – ***«на своем горбу испытал нелегкую участь»*** (С.В.Т.: 178). «*белгечләр арасында **кайнаган»*** (В.Җ.Д.: 114) – «***вращавшийся** в избранном обществе»* (С.В.Т.: 181) сүзгә-сүз тәрҗемә иткәндә кайнаган – кипеть сүзе белән тәңгәл килә. Ләкин бу очракта «вращатся в обществе» – ул рус теленең, татар гыйбәрәсенә эквивалент тотрыклы сүзтезмә буларак кулланыла.

2) Калькалаштыру – бер телдәге тропны сүзгә сүз итеп икенче телгә күчерү. Мондый тәрҗемә барышында шуны истә тотарга кирәк, троплар тәрҗемә телендә табигый итеп яңгырарга тиеш. «***башыңа төшкәч, башмакчы буласың»”*** (В.Җ.Д.: 112) Бу татар халык мәкале чарасыз, котылгысыз хәлдә калаган кешенең тормышка яраклашуын белдерә. Рус телендә аңа эквивалент тәрҗемә итеп «Поклонишься и кошке в ножки» – дигән мәкаль бар. Әмма Р. Кутуй әсәрдә татар мәкален болай итеп бирә: «***ежели подопрет – и сапожником станешь, поднажмет – и соловьем засвистишь!»*** (С.В.Т.: 178); «***ни аллага ни муллага»*** (Г.Т.Х.: 238) – ***«ни мулле ни аллаху»*** (Г.Л.Д.: 22).

3) Бер компонентын алмаштырып тәрҗемә итү. Икенче телдә лексик сурәтләү чаралары аңлаешлы булсын өчен аларны тулыландырып, яисә артык элементларын төшереп калдырып тәрҗемә итү. Мәсәлән: «*Шактый биек тауга **менеп җиткәндәй»*** (В.Җ.Д.: 106) чагыштыруы тәрҗемәдә болай дип бирелә *«как будто **одолел** высокую гору»* (С.В.Т.: 170). «*Туташны **Әлдермеш** егетләре урлап киткәннәр»* (Г.Т.Х.: 301) *«Туташ украли неизвестные джигиты»* (Г.Л.Д.: 85) әлеге гыйбәрәне трҗемә иткәндә Р. Кутуй Әлдермеш сүзен төшереп калдыра, чөнки рус укучысы өчен ул бернинди дә аерым мәгънә төсмере белдерми. Бары тик татар укычысы гына Әлдермеш авылында чая холыклы кешеләр яшәгәнен белә. Икенче мисал: «*...Җан теләсә дә, язык җибәрми»* (Г.Т.Х.: 323) – *«Рад бы в рай, да грехи не пускают»* (Г.Л.Д.: 104). «*Мин – бүре, ә сез – **бәрән»*** (Г.Т.Х.: 249) – *«я – волк, вы - **зайчишка»*** (Г.Л.Д.: 34).

4) Компенсация алымын кулланып тәрҗемә итү. Әлеге ысул буенча авырлык тудырган яки бөтенләй тәрҗемә итеп булмый торган тропларны төшереп калдыру һәм текстның икенче (лексик сурәтләү чаралары булмаган) өлешендә өстәү. *«**караңгы чырайлы**, сөмсер кеше»* (В.Ж.Д.: 112) тәрҗемә барышында әлеге троп югалып кала, һәм бу гыйбарәне ачыклап килгән бер сүз белән тәрҗемә ителә – *«унылым и **неприветливым** человеком»* (С.В.Т.: 177), ләкин шул ук абзац ахырында тәрҗемәче оригинал текстта булмаган гыйбарә кертә: *«его лихорадочный огонь в глазах – от **пожирающей его болезни**»* (С.В.Т.: 177). *«**Башлы** кеше»* (В.Ж.Д.: 114) – *«**Очень умный**»* әлеге эпитет төшеп кала. Әмма шул ук җөмләдә тәрҗемәче башка сүзтезмәне фразеологизм белән алмаштыра: *«дәрәҗәгә ирешкән» – «сумел “сделать имя”* (С.В.Т.: 181). *«**Ялан кадәр** сәхнә»* (Г.Т.Х.: 300) бу чагыштыру шулай ук югалып кала, һәм икенче җөмләдә фразеологизм кулланыла: *«Для них сцена **как свои пять пальцев**»* (Г.Л.Д.: 83).

Гомумиләштереп әйткәндә, матур әдәбият әсәрләрен рус теленә тәрҗемә иткәндә лексик сурәтләү чараларын тәрҗемә итүнең барлык ысулларын да куллана. Әмма калькалаштыру һәм тропның бер компонентын алмаштырып тәрҗемә итү калган ысулларга караганда ешрак очрый.

Матур әдәбият тәрҗемәсе турында сүз алып барганда, тәрҗемә ысуллары буларак трансформацияләр турында да онытырга ярамый. Тәрҗемә теориясендә күптөрле тәрҗемә трансформацияләре аерылып күрсәтелә. Һәрбер галим үз калссификацясен тәкъдим итә. Әмма тәрҗемә теориясендә В.Н. Комиссаровның классификациясе иң кулай санала торганнардан берсе. Аның фикеренчә,лексик трансформация транскрипция, транслитерация, калькалаштыру һәм лексик-семантик алмаштырулар (конкретлаштыру, генерализация, модуляция) кебек алымнарныүз эченә кертеп карый.

Транскрипция һәм транслитерация– лексик берәмлекнең формасын чыганак телдәге хәрефләр ярдәмендә тәрҗемә итү ысулы. Транскрипция вакытында – тәрҗемәдә чыганак тел сүзенең аваз формасы, ә транслитерация күренешендәаның график формасын (хәрефләр төзелеше) саклау аша булдырыла [Комиссаров 1990: 173]. Мәсәлән, татар әдәбияты әсәрләренең тәрҗемәләреннән транскрипция күренешенә берничә мисал: *Гөләндәм – Гуляндам, мирза – мурза, “Дим буенда” – “У Дёмы”, егет – джигит, әфәнде – эфэнди.* Повестьларның тәрҗемәләрендә транслитерация ысулы да күзәтелә: *туташ, абый, Исхак,Салих, Сабира.* Мисаллардан күренгәнчә транслитерация һәм транкрипция ысуллары ярдәмендә күбесенчә ялгызлык исемнәре һәм атау сүзләре тәрҗемә ителә.

Калькалаштыру – ул лексик берәмлекләрнең состав өлешләрентәрҗемә теленедәге лексик эквивалентлары белән алмаштыру: *«каракүл **бизәкләрен “укырга** өйрәндем»* (В.Ж.Д.: 210) – *«научился...**читать узоры** каракуля»* (С.В.Т.: 300). *«хыял күге»* (В.Ж.Д.: 131) – *«небо мечтаний»* (С.В.Т.: 203). *«Басыйр шикелле **бөҗәк**»* (В.Ж.Д.: 181) – *«это недоступно пониманию такого **насекомого**, как Басыйр»* (С.В.Т.: 256).

Лексик-семантик алмаштырулар – оригиналдагы лексик берәмлекләрне тәрҗемә телендәге берәмлекләр белән алмаштыру. Бу очракта тәрҗемә беремләкләре чыганак тел берәмлекләренә туры килми. Мәсәлән: *«...ул кызый **күңелнең** әллә кайсы гына төшендә һаман **яшеренеп ята бирде»*** (В.Ж.Д.: 213) тәрҗемәдә *«...она никогда **не покидала моего сердца»*** (С.В.Т.: 303). Китерелгән мисал җөмләдә тәрҗемәче ике тапкыр лексик алмаштыру ысулын кулланган. *Күңел* сүзе рус теленә турыдан-туры *душа* дип тәрҗемә ителә, ә бу өзектә ул *сердце* сүзе аша бирелә. *Яшеренеп ята бирде* сүзгә-сүз бу төзелмәне *все еще скрывалась/ пряталась* дип тәрҗемә итеп була.

Конкретлаштыру – киң логик мәгънәгә ия булган чыганак телдәге лексик берәмлекне тәрҗемәдә мәгънәсе таррак булган сүз яки сүзтезмә белән алмаштыру. *«Башта язганымча, максатым бер ел эшләп, **кая да булса** укырга китү иде»* (В.Ж.Д.: 211) – *«Как я писал вначале, цель моя, была, проработав год, поступить учиться **в вуз**»* (С.В.Т.: 300). Мисалдан күренгәнчә тәрҗемәдә кая да булсаукырга керегә дигән гыйбәрә рус теленә конкретлаштырып, ВУЗга укырга керегә дип күрсәтелә. Икенче бер мисал: *«Әмин әкә **таза гәүдәле, кызыл чырайлы**, аю сыман алпан-тилпән атлап, ашыкмыйча йөри торган бер кеше иде»* (В.Ж.Д.: 116) – *«**Богатырского сложения**, с **кирпично-красным лицом,** крепкой воловьей шеей, огромными ручищами с короткими толстыми пальцами и медвежьей походкой в развалку – ну прямо батыр* из сказки. *богатырь»* (С.В.Т.: 184). Конкретлаштыру мисалыннан тыш әлеге җөмләдә авторның үзеннән өстәгән чагыштырулар һәм эпитетлар күренә.

Генерализация – конкретлаштыру алымының капма-каршы күренеше, монда сүз яки сүзтезмәне тәрҗемәдә логик мәгънәсе киңрәк булган сүз яки сүзтезмә белән алмаштыру [Комиссаров 1990: 176]. *«...иягенә кадәр кызарды...»* (Г.Т.Х.: 291) – *« покраснев до невозможности»* (Г.Л.Д.: 75). *«Салих **кул буена** килеп җиткәндер яки җитә торгандыр»* (Г.Т.Х.: 382) – *«Наверное, Салих подошел или уже подходит **к условленному месту**»* (Г.Л.Д.: 164).

Антонимик тәрҗемә – ул лексик-грамматик трансформация төрләренең берсе, аны кулланганда оригиналдагы раслау җөмлә тәрҗемәдә инкарь итү җөмләсе белән бирелә, яки киресенчә инкарь итү җөмләсе раслау җөмләсе ярдәмендә тәрҗемә ителергә мөмкин [Комиссаров: 1990, 183]. «***Әнә шулай уйлап**, мин, әйткәнемчә, ВУЗга китүне бер елга кичектереп торырга һәм эшкә керергә булдым»* (В.Ж.Д.: 108). *«**И потому не стал долго раздумывать**, а принял окончательное решение – отложить вуз на год и искать подходящую работу»* (С.В.Т.: 172).*«**Ә көлмичә генә әйткәндә...**»* (Г.Т.Х.: 290) – *«**А если говорить всерьез...**»* (Г.Л.Д.: 73).

Экспликация яки тасвирлап тәрҗемә итү күренешендә чыганак телнең лексик берәмлеге тәрҗемә телдә аны ачыклап яки тасвирлап килә торган сүзтезмә ярдәмендә бирелә. Күпчелек очракларда бу ысул белән эквивалентсыз лексика тәрҗемә ителә [Комиссаров: 1990, 185]. *«**Лаеш шулпасын**» шактый эчәргә туры килде»* (В.Ж.Д.: 212) – *«Досыта пришлось наглотаться “**лаишевской***

***похлебки****”* **то есть испытать нужду (местная поговорка)* (С.В.Т.: 302).*«...вспоминаю...старичков в черных* ***каляпушах*...*национальный головной убор мужчин-татар****»* (С.В.Т.: 168).

Компенсация күренеше вакытында тәрҗемә барышында югалып калаган мәгънә элементлары, текстта икенче төрле чаралар ярдәмендә чагылдырыла, ягъни компенсацияләнә [Комиссаров: 1990, 185]. Мәсәлән, «Вөждан» әсәрендә *«кулга иялəшеп беткəн күгəрчендəй»* (В.Ж.Д.: 184) дигән чагыштыру тәрҗемәдә югалып кала, аның урынына кызны тасвирлаганда чыганакта булмаган мондый эпитет һәм чагыштырулар очрый: *«она, моя* ***черноокая газель****, моя* ***Зухра*** *»* (С.В.Т.: 269).

Гомумиләштереп әйткәндә, әдәби әсәрнең стилистик алымнарын, тропларын, сурәтлләү чараларын икенче телгә күчерү тәрҗемә теориясенең мөһим бер аспекты булып тора. Лексик сурәтләү чаралары барлык телләргә дә хас. Һәрбер телдә дә сүзләрне туры һәм күчерелмә мәгънәдә кулланырга мөмкин, экин төрле телләрдә әлеге сурәтләү чаралары төрле сүзләр ярдәмендә бирелергә һәм төрле мәгънәләргә ия булырга мөмкин.Татар теленең образлык системасы рус теленә кызыклы ысуллар ярдәмендә тәрҗемә ителә.Алар һәрвакыт төп тексттагы тулы эчтәлекне биреп бетермәсәләр дә, төп моментларны яктыртырга тырышалар.

**Әдәбият**

Казакова Т.А. Художественный перевод. – СПб.: Изд-во Санкт-Петербургский институт внешнеэкономических связей, экономики и права, 2002. – 113 с.

Комиссаров В. Н. Современное переводоведение. – М.: Изд-во Валент, 2014. – 480 с.

Комиссаров В.Н. Теория перевода (Лингвистические аспекты). – М.: Изд-во «Высшая школа», 1990. – 253 с.

Юсупов Р.А. Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 240 б.

*Дубровина Маргарита Эмильевна*
Санкт-Петербургский государственный университет
Санкт-Петербург, Россия
*Dubrovina Margarita Emilievna*
St. Petersburg State University
Saint Petersburg, Russia

## ОБ ОСОБЕННОСТЯХ ФУНКЦИОНИРОВАНИЯ ФОРМЫ –ГАН В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ
## A FEW WORDS ABOUT THE SPECIFIC FUNCTIONS OF THE FORM -GAN IN THE TATAR LANGUAGE

Аннотация. *Глагольная форма –ган является одной и интереснейших форм тюркских языков, в основном, она распространена в кыпчакских языка, но можно с большой уверенностью утверждать, что ее морфологическим аналогом в огузских*

*языках является форма -dık, а в якутском -форма –быт. Автор выдвигает гипотезу о том, что называть эти формы причастиями не совсем верно, так как их функционирование отличается от того, что регистрируется у причастий европейского типа.*

Annotation. *The verbal form-gan is one of the most interesting forms of the Turkic languages. Basically, it is common in the Kipchak languages, but it is possible to say with great confidence that its morphological analogue in the Oguz languages is the form-dık, and in the Yakut - the form-быт. The author hypothesizes that it is not entirely correct to call these forms participles, since their functioning differs from that recorded in European-type participles.*

Ключевые слова. *Причастия, глагол в тюркских языках, тюркские языки, форма –ган, татарский язык, грамматика тюркских языков*

Keywords. *Participles, verb in the Turkic languages, the Turkic languages, form-Gan, the Tatar language, gramm ar of the Turkic languages*

Как известно, форма -ган присутствует практически во всех тюркских языках кыпчакской и карлукской групп. Ее повсеместная распространённость и многофункциональность привели к тому, что она редко стала становиться предметом детального изучения среди специалистов по конкретным тюркским языкам. Тем не менее, едва ли можно утверждать, что на все вопросы, связанные с употреблением и значением этой формы в системе языка, уже удалось получить однозначные ответы.

Традиционно в татарском языкознании выделяют две формы с таким показателем: форму причастия прошедшего времении форму прошедшего неопределенного времени [Грамматика татарского языка]. В сферу интереса нашего исследования входит причастная форма -ган.

1. Өч улының кайсысы булса да кайчан да булса бер **килгән** поездан төшеп авыл юлына чыган бит (ӘЕ, X, 6) «Ведь хоть кто-нибудь из его трех сыновей хоть когда-нибудь сойдет с прибывшего поезда и направится к деревне»

2. …рәхимсез нужада торып **укыган** ярлы шәкерт гадәттә бик сәләтле булып чыга. (ӘЕ, М, 1) «Бедный ученик, **который учился**, находясь в жестокий нужде, обычно становится очень талантливым».

Однако существует мнение, что эта форма не только в татарском, но и в других тюркских языках, ведет себя не как чистое причастие. [Дубровина, 2016 (А)]. Автор данной статьи вслед за многими другими тюркологами принимает следующую позицию: форма -ган не представляет собой причастия. Она, обладая специфическими чертами, не свойственными европейским причастиям, должна получить самостоятельный статус и самостоятельное название. Во-первых, как писал С.Н. Иванов о турецких формах, что соответствует и татарской форме –ган, определяемое при форме -ган может обозначать не только субъект или объект действия, (как это имеет место у причастий русского языка), но также место и время действия. [Иванов, 1977].

3. Ә монда, колхозның атаклы кешеләре **җыелган_**бу йортта зур җәмәгать эшләре хәл ителә. (АШ, СӘ, 6). «А здесь, в этом доме, **где собирались** видные деятели колхоза, решаются важные общественные проблемы».

Кроме того важной особенностью это формы является то, что она индифферентна к «агентивному» значению, т.е. отношения между действием и определяемым предметом могут быть различными, а зачастую они становятся известными только на основании всего контекста:

4. Һәм аның тавышында **мин көткән_**уңайсызлану яки оялу ник кенә бер ишетелсә иде! (http://kitap.net.ru/eniki/6.php). Ах, если бы в ее голосе было слышно то, что я ожидал услышать: чувство неловкости и стыда.

Текстовой материал и теоретические изыскания подводят нас к выводу о том, что форма -ган и аналогичные ей формы в других тюркских языках представляют собой не аналоги европейских причастий, а особые **двуфункциональные** морфологические средства, в задачу которых входит выступать не только в роли глагольных атрибутивов, но и в роли глагольных субстантивов.

5. Җир шарында бер хатын да Гөлчирә **күргәнне** күрмәсен! Пусть не увидит ни одна женщина **того, что увидела** Гульчира. (https://cyberleninka.ru/article/n/pridatochnye-predlozheniya-podchinennye-glavnomu-pri-pomoschi-padezhnyh-affiksov-na-materiale-tatarskogo-yazyka).

В представленном примере словоформа **күргәнне** включает в себя аффикс -гән. По традиции подобные случаи в татарском языкознании рассматриваются как формы придаточных предложений, осложненных падежными окончаниями. Однако в теоретических исследованиях по тюркской грамматике уже были озвучены идеи, согласно которымподобные формы не следует воспринимать как финитные формы. Задачей таких средств является передать не предикат высказывания, а глагольное дополнение, т.е. в сущности в данном случае форма -ган выражает не предикативные отношения, а подчинительные (отношения дополнения). Таким образом, в случае если после аффикса -ган следует аффикс одного из падежей, необходимо воспринимать эту форму как инфинитную, выступающую в качестве глагольного субстантива.

Две выше перечисленные функции: атрибутивная и субстантивная относятся к одной и той же форме, которую едва ли оправданно именовать причастием. Следовательно, предлагается ввести в научный оборот новый термин **«субстантивно-адъективная форма»**, сокращением которой является аббревиатура САФ, который активно используется учеными петербургской научной школы. [Гузев, 1976; Дениз-Йылмаз, 2006; Дубровина, 2016 (Б)] В результате чего в качестве добавленного глосса для обозначения данных форм был введен знак SAF (substantive-adjectiveform/субстантивно-адъективная форма).

В высказываниях форма -ган в подобной дистрибуции может выступатьне только в функции второстепенных членов предложения, как это было показано выше, но и в роли подлежащего.

6. Кайдадыр балаларның шатлыклы шаулашып ***уйнаганнары*** ишетелә. (Шамов, 1954 : 188). 'Слышно, **как** где-то радостно крича,**играют** дети'.

7.Ниләр ***уйлаганым***, башыма нинди «этлекләр» ***килгәнен*** һич кенә дә искә төшерә алмыйм. Ә инде мич алдыннан шырпы алып кесәгә ***яшергәнемне*** яхшы хәтерлим. (http://kitap.net.ru/minnullin2.php). 'Я никак не могу вспомнить, **о чем я думал**, какие «проделки» пришли мне в голову. Зато я прекрасно помню, **как я взял** из-за печи спички и спрятал их в карман'.

**Литература**


Грамматика татарского языка // http://tatar.com.ru/grammatika9.php

Гузев В.Г. Система именных форм тюркского глагола как морфологическая категория (на материале староанатолийского и турецкого языков) // Turcologica. Ксемидесятилетию академика А.Н. Кононова. – Л.: Издательство Наук а. 1976. – С. 56-61.

Дениз-Йылмаз О.Категория номинализации действия в турецком языке.– СПб.: Издательство С.-Петербургского ун.-та. 2006. – 227 с.

Дубровина М.Э. (А). Об отличительных особенностях глагольно-именной формы с показателем –gan в узбекском языке // Вестник Санкт-Петербургского университета. Серия 13. Востоковедение, африканистика. Вып.3. Сентябрь. 2016.– СПб.: Издательство СПбГУ. 2016.– С. 4-15.

Дубровина М.Э. (Б). О термине «субстантивно-адъективная форма» (САФ) применительно к некоторым глагольно-именным формам тюркских языков // Актуальные вопросы тюркологических исследований / под ред. Н.Н. Телицина, Й.Н. Шена. – СПб.: СПбГУ. 2016. – С. 49- 55.

Иванов С.Н. Курс турецкой грамматики. Ч. 2: Грамматические категории глагола. – Л: Издательство ЛГУ. 1977. – 88 с.

Афзал Шамов. Сайланма әсәрләр. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 469 б.



*Җамалиева Луиза Фирдүсовна*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Zamalieva Luiza Firdusovna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia


## ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА КҮК ҖИСЕМНӘРЕ АТАМАЛАРЫ
## NAMES OF CELESTIAL BODIES IN FOLK SONGS


Аннотация. *В текстах народных песен активно употребляются названия небесных светил, как луна, солнце, звезда. Они часто привлекаются для описания природы в качестве поэтического рисунка. Также эти символы способствуют углубленному выражению мотивов тоски и печали, передаче душевного состояния человека.*

Annotation. *In the texts of folk songs, the names of heavenly bodies such as the moon, the sun, and the star are actively used. They are often drawn to describe nature as a poetic*

*drawing. Also, these symbols contribute to the in-depth expression of the motives of longing and sadness, the transfer of the mental state of a person.*

Ключевые слова: *народная песня, татарский фольклор, образ, сравнение, метафора.*

Keywords: *folk song, Tatar folklore, image, comparison, metaphor.*

Халык җырларындагы образларның бер зур төркеме *күк җисемнәре* белән бәйле. Ф. Урманчеев «Дастаннарга лаек замана» китабында бүгенге *ай, кояш, җир, күк, йолдыз* кебек образларның халык авыз иҗатыннан ук килүенә һәм ыруглык җәмгыяте мифологиясенә барып тоташуына игътибар итә [Урманчеев, 1990: 109-150]. Әлеге хезмәттә автор төрле халыкларда киң таралган Кояшка табыну, Кояшны изгеләштерү, кешенең Айдан, Кояштан яки аларның нурларыннан яратылуы, йолдызлар атылу белән бәйле ышанулар, аларның халык авыз иҗатында һәм әдәбиятта чагылышы хакында сөйли.

Халык авыз иҗатында Ай, Кояш, Йолдыз – аеруча киң чагылыш тапкан образлар. Җырларда аларның еш кына җанлы итеп сурәтләнүе (антропоморфизм) күзгә ташлана. Кояш чыга, калка, биткә төшә, йөзне иркәли, өйгә керә һ.б. ; Ай белән йолдызлар да калка, бата, күктә йөзә:

Зәңгәр һаваларда йөзгән<br>
Айлардан эзлим сезне [тат. 1: № 3226],<br>
Зәңгәр һаваларда йөзгән<br>
Йолдызлардим мин сине [тат. 1: №3227].

*Бату, калку, йөзү* — татар телендә нигездә *су* сүзе белән кулланылучы фигыльләр. К. Гафиуллина саналган образларның әлеге үзенчәлекләрен борынгы бабаларыбызның күк җисемнәре судан чыга һәм кире шунда кереп китә дип ышанулары белән бәйләп аңлата [Гафиуллина, 2002: 204].

Халык җырларында *ай* сүз-сурәте бик актив. Беренче чиратта, ул яраткан кешенең матурлыгын, аеруча аның йөзен тасвирлаганда кулланыла. Бу мотив татар халкының борынгы лирик җырларында ук күзәтелә: Аять-хәдис – әйткән сүзе, *Ай кеби нурлы йөзе*[тат. 3: № 74]; Йөзләремнең ниндилеген белмисеңме, Аяз төнне *тулган айны* күрмисеңме [тат. 3: № 272]. Сөйгән ярның йөзе-бите сурәтләнгән җырларында ай сүзе янәшәсендә түбәндәге эпитетларны очрата алабыз: *тулган ай, нурлы ай, урак ай, кичке ай, ай нуры бар* һ.б.: Буең зифа яшь тал кебек, *Йөзең тулган ай кебек*[тат. 1: № 3201].

Тулган ай образының хатын-кыз матурлыгын сурәтләү өчен бирелүе борынгы язма ядкәрләрдә үк очрый. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә түбәндәге юллар бар: Тулун ай дик балкыр иде аның йөзе, Бал-шәкәрдән датлы иде аның сүзе. Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасында да ай образы шундый ук мәгънәгә ия: Йөзе аның кичә туган ай дик.

Татар җыр текстларын тикшерү *ярым ай* белән чагыштырганда *тулган ай* тезмәсенең активрак булуын күрсәтә: Кеше күзләренә *сулган ай* күк, Әй, җаный гынам сылуым, Үз күзләремә *тулган ай* кебек [тат. 3: № 276].

Тулган ай тезмәсе кызларга гына түгел, егетләргә карата да кулланыла:

Биек тау башында

Түгәрәк ай калка;

*Тулганаем Али,*

Йөрисең син кайда? [тат. 3: № 499].

Йола җырларында яшь килен дә *тулган ай* белән чагыштырыла [тат. 2: № 76]. Туй җырларында кодаларның да йөзләре тулган айга тиңләнә: Йөзләрегез *тулган ай кебек,* Акылыгыз сары май кебек [тат. 2: № 60]. Дусларның, туганнарның да тулган айга тиңләнүе бу тәгъбирнең аеруча якын кешеләр турында сөйләгәндә файдаланылуын тагын бер кат раслый: Карачы безнең дусларга *Яңа туган ай кебек* [тат. 1: № 1578].

Бер үк вакытта Ай татар халык лирикасында ялгызлык символы да булып тора: *Бик сагынсам айга карыйм, Ай да ялгыз минем күк* [тат. 1:№ 3654].

Алда әйтелгәнчә, Ай җырларда җанлы образ итеп бирелә. Ул елмая, көлә ала: Ай югары*, ай елмая,* Нинди якты нур айда?! [тат. 1: № 2413], *Тулган айлар көлеп баккач* Эзләшермен башмагыңны [тат. 3: № 495].

Йола җырларында ирексезләп киүягә бирелүче яшь кыз хәсрәте ай тотылу белән чагыштырыла:

Урам ашалый узганда,

*Тулы айны болыт каплады;*

Җан гынам минем тартмады,

Абзыкай шул утка ташлады [тат. 2: № 5].

Галим Г. Саттаров татарларның Ай туганда яки тулган вакытта туган балаларга Ай компоненты кергән исем кушу гадәте турында яза [Саттаров, 1981: 26].

Еш кына җырларда *ай* белән *кояш* образларын бергә дә күрергә мөмкин. Кайбер җырларда *ай* белән *кояш* бер-берсен сөйгән ярлар булып күзаллана. Пары белән кавыша алмаган лирик герой үзләрен ай-кояшка тиңли:

Ай белән кояш аерым,

Кушылмый гомергә дә;

Без дә шулай булырбыз дип,

Уй килә күңелләргә [тат. 1: № 2388].

Әлеге чагыштыру татар халкының кыска җырларында аеруча еш күзәтелә: Безнең кебек *аерым яши Ай* белән *кояш* кына [тат. 1: №3133, 1915, 2474, 3514 һ.б]. Ә менә славян халыкларында, әйтик украиннарның туй җырларында, ай һәм кояш янәшәлеге, киресенчә, яшь парларның кавышуын символлаштыра икән [Колесницкая, 1981: 60].

Халык җырларда ай белән кояшның һәр көнне чыгуы һәм батуына, ягъни кабатланып торучы күренешләр булуына да игътибар итә. Чит җирдәге лирик герой кайчан да булса туган илгә әйләнеп кайту өметен җуймый, үзен ай-кояшка тиңли:

Халык җырларында *Кояш* образының да сурәтләнеше шактый киң һәм төрле мәгънә төсмерләренә ия. Ул да, ай шикелле үк, төрле эпитетлар белән килеп, лирик геройның якын кешеләрен сурәтләгәндә файдаланыла: Сез кодаларым

килеп кергәч, *Чыккан кояш* белән тиң күрдем [татт. 3: № 461]; Буе озын камыштай, Үзе *балкыр кояштай* [тат. 2: № 81].

Яраткан кешенең йөзен кояшка тиңләү аеруча еш күзәтелә: Бармагың – камыш, *йөзең – кояш*, Акылларың камил, үзең яшь [тат. 1: № 1893].

Еш кына туган иленнән аерылган бәхетсез лирик герой кояш чыгуын ямансулап каршылый. Яңа көн туу лирик геройның аеруча моңаюына, иң тирән хисләренең, кайгыларының яңаруына китерә: Кызарып ла *кояш чыккан* чакта, Ямансу ла була ят җирдә [тат. 3: № 36]; Илем *кояш чыгышында,* Үзем баешларында [тат. 1: № 1315], Кайда барсаң *шул бер кояш,* Күбәләктәй җанга көч [тат. 3: № 64].

Сөйгән ярларның аерылышу газабы, сагышы да *кояш,* аның белән бәйле күренешләр аша үтемлерәк итеп бирелә: *Нурлы кояш* нурын чәчәр иде, Син яшәсәң туган илләрдә [тат. 3: № 127], И дускаем, бик сагынам *Кичке кояш батканда*[тат. 1: № 2411]. Лирик герой сөйгәненең еракта булуына өзгәләнә: *Син кояш чыгыш ягында, Мин кояш баешында*[тат. 1: № 3548]; кояш чыгуны үзеннән сәлам дип кабул итүләрен тели: *Чыгар кояш*, чәчәр нурын, Миннән *сәлам шул булыр* [тат. 1: № 3019].

*Йолдыз* образы җырларда ай һәм кояш белән чагыштырганда азрак: кулланыла. Бер очракта *йолдыз* төнге күктәге *айны* алыштырып килергә мөмкин, ягъни яшь парлар, *ай* булмаганда, *йолдыз* яктысында да очрашып серләшә алалар. «Кич караңгы диеп килми калма, *Ай* булмаса, якты ла *йолдыз* бар» [тат. 3: № 350] дигән юллар инде татар халкының борынгы җырларында ук теркәлгән. Гадәттә җырларда йолдызларның исемнәре дә күрсәтелә: Җидегән йолдыз, Зөһрә йолдыз, Казык йолдыз, Чулпан йолдыз, Венера йолдызы һ.б. телгә алына.

*Йолдыз* сүзе дә күп очракта, башка күк җисемнәре кебек, сөйгән ярны, аның матурлыгын сыйфатлау өчен кулланыла. Лирик герой үзенең сөйгәнен йолдызга тиңли: *Зөһрә йолдызыдай балкып,* Күренәсең күземә [тат. 3: № 434]; *Венера йолдызы* кебек Яшә ялтырап кына [тат. 1: № 2868], Җидегән йолдыз нурлары бар *Ике бит уртасында* [тат. 1: № 4145].

Җырларда гүзәл кызның күзләрен йолдызга охшату еш очрый: *Күзләреңнең ниндилеген белмисеңме, Ай янында кунган йолдыз күрмисеңме*[тат. 3: № 272]. Чагыштырулар еш кына метафорага әйләнеп китәләр: Кара кашым, *йолдызым,* Энҗе тешем, гөл йөзем [тат. 3: № 313]; Кашың Казан кондызы, Күзең *Чулпан йолдызы* [тат. 1: №3447], Аузың уймак, тешең энҗе, *Күзең йолдыз,* йөзең ай [тат. 1: № 3514].

Татар халык җырларында лирик геройның сагышлы чакларында йолдызга карап юануы да еш урын ала: Бик сагынсам чыгып карыйм *Зөһрә йолдызларына*[тат. 1: № 4083], *Якты йолдызларга карыйм* Сине сагынган чакта [тат. 1: № 4119].

Җырларда *йолдыз* юл күрсәтүче буларак та телгә алына: Төннәр [тат. 3: № 19], Унөч мең чакрымнан кайтып киләм, *Казыкйолдыз* минем юлдашым [тат. 3: № 22].

Гомумән җырларда күк җисемнәре атамалары еш очрый. Җыр текстларындагы *ай, кояш, йолдыз,* беренче чиратта, сөйгән ярның яки якын кешенең матурлыгын тасвирлаганда кулланыла. Ай һәм кояш парлы предметларны белдергәндә, еш кына бергә биреләләр. Шул ук вакытта аларның янәшәлеге аерылуны белдергәндә дә файдаланыла. Җырларда лирик геройның кайгы-хәсрәтен күрсәткән вакытта да бу образларның актив кулланылуын әйтеп үтәргә кирәк.

**Әдәбият**

Гафиуллина К.Н. Халык җырларында Ай, Кояш, Йолдыз образларын сурәтләүдә кулланыла торган тел берәмлекләре // Тел, әдәбият һәм халык иҗаты мәсьәләләре: мәкал. җыент. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 203-220.

Колесницкая И.М. Символика в хороводных и свадебных песнях русских, украинских, белорусских // Фольклор народов РСФСР. – Уфа: БГУ, 1981. – С. 52-62.

Татар халык иҗаты. Кыска җырлар / И.Надиров. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. – 392 б.

Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар / И. Надиров. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. – 488 б.

Урманчеев Ф.И. Дастаннарга лаек замана. – Казан: Тат.кит. нәшр., 1990. – 220 б.

*Завгарова Фанзиля Хакимовна*
Казань, Россия
*Zavgarova Fanzilya Hakimovna*
Kazan, Russia
*Гилемшин Флер Фоатович*
Академия наук Республики Татарстан
Казань, Россия
*Gilemshin Fler Foatovich*
Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan
Kazan, Russia

## ЧОРМА/ ЧАРДАК (ЧЕРДАК) КАК СЕМАНТИЧЕСКИ НАГРУЖЕННЫЙ ЭЛЕМЕНТ ТАТАРСКОГО ДОМА

## CHORMA/CHARDAK (ATTIC) AS A SEMANTICALLY LOADED ELEMENT OF THE TATAR HOUSE

*Работа выполнена при финансовой поддержке РФФИ и Правительства РТ в рамках проекта «Татарский дом: семиотика пространства» № 18-412-160019*

Аннотация. *В статье рассматривается элемент пространства татарского дома чорма (чердак), наделенный символическими значениями, которые могут интерпретироваться.*

Annotation. *The article considers the element of the Tatar house area - chorma (attic - tat.) that endowed with symbolic meanings that can be interpreted.*

Ключевые слова. *Дом, семиотика, миф, обряд, символ, знак.*

Keywords. *House, semiotics, myth, rite, symbol, sign.*

Как нам известно, в современной отечественной этнографии и фольклористике большое внимание стали уделять изучению глубинных аспектов функционирования вещей в разные периоды истории общества и в различных этнических контекстах. В рамках этой научной концепции материальную и духовную культуру стали рассматривать в неразрывном единстве с мировоззрением народа. Основоположником изучения символических функций вещей принято считать П.Г. Богатырева, который считал, что любая вещь обладает не одной функцией, среди которых есть и практические, и символические (эстетическая, магическая, функция обозначения сословной или региональной принадлежности) [Богатырев, 1971]. В дальнейшим идеи П.Г. Богатырева были подхвачены и развиты известным фольклористом А.К. Байбуриным, который смог подвести теоретическую основу изучения знаковых аспектов функционирования утилитарных предметов. В контексте данной статьи нам особенно интересна его работа под названием «Жилище в обрядах и представлениях восточных славян», где он смог выявить символические аспекты традиционного восточнославянского жилища и основные принципы освоения пространства [Байбурин, 1983]. Относительно изучения семантических основ элементов татарского жилища, мы можем обратить наше внимание на некоторые статьи, подготовленные учеными Республиканского центра развития традиционной культуры (А.Д. Батталовой [Батталова, 2018], Ф.Х. Завгаровой [Завгарова, 2018]), а также указать на труды известных ученых этнографов Р.Г. Мухамедовой [Мухамедова, 2008], Н.А. Халикова [Халиков, 2017] и др., которые, несомненно, стали существенной основой для дальнейшего изучения татарского жилища, как семиотического объекта традиционной культуры и сакрального центра обжитого человеком.

Чорма / чардак (чердак) – это пространство между кровлей и потолком татарского дома или бани. Данное пространство у хозяйственных построек называется не чорма, а түбәасты – место под крышей. В данной же статьи мы рассмотрим только чорма/чардак и попытаемся выявить его функциональную семантику в контексте обрядовой культуры. В татарской этнографической науке чорма, как важное инженерное составляющее татарского жилища рассмотрена мало, до сих пор остается не исследованным и ее функциональная семантика, выраженная в бытовой и обрядовой культуре татар. В связи с этим данную статью можно считать первым опытом, посвященным выявлению символической функции чорма/чардака/чарлака в мировоззренческой системе татар.

Чорма в контексте бытовой культуры татар является не освоенным пространством дома. В нем не живут. Он также не является активным местом хранения домашней утвари. «*Чормада кирәкле әйбер аз була» (На чердаке нужных вещей бывает мало),* так говорится в татарской пословице [Исанбет, 2010: 353]. В тоже время чорма, как и түбә (крыша) татарами, как и многими народами, воспринимается как верхняя часть строения, которая защищает обитателей жилища от воздействия внешнего мира. В мифологическом сознании

татар он воспринимается, как часть неба – верхушки/түбә. Идея соотнесенности верхнего яруса дома с небосводом закодирована в декоративном оформлении фасадного фронтона. Вероятно поэтому, фронтоны татарских домов часто имеют форму луковицы – небесного свода. Солярные (солнечные) знаки-символы часто обнаруживаются на концах причелин– резных досок, идущих по краям обоих скатов кровли. Аналогичные знаки выявляются и на полотенце - короткой резной доске, закрывающей стык причелин, а также иногда и торцы верхних венцов сруба. В локализованных здесь символах находит свое выражение идеограмма космологического верха. Архетип небес, вышнего уровня, высоты, связанный с представлениями о крыше, имеет универсальное применение. Об этом гласит татарская пословица «*Нигезен кыек салсаң, түбәсен тимер казык йолдызына кадәр меңгерсәң дә кыек булыр» (Если фундамент положишь криво, то крышу даже до большой медведицы возведешь, она все равно будет кривой)* [Исанбет, 2010: 351]. Обытовленным проявлением соотнесенности түбә/крыши дома с головой человека служит образное выражение, используемое в просторечии: түбәсе киткән (крыша поехала), плохо соображающий, түбәсе тишелгән (крыша продырявлена), плохо помнящий. Согласно народным представлениям татар, с түбә/крышой осмысляется и мужской головной убор – түбәтәй (тюбетейка). Эти же представления распространяются и на чорма /чердак.

Бытовой функционал у чормы не велик. Она в основном служит местом хранения вещей, необходимость в использовании которых, на данное время отпала или же не наступил сезон. Например, основным местом хранения валенок до сих пор является чорма, который дает возможность хранить их в подвешенном состоянии, что способствует защите от моли. Также чорма служит удобным местом для сушки пастилы, лука, веточного корма для молодняка, шерсти. Все это дает воспринимать чорма/чердак захламленным местом – местом, где нет порядка. Вероятно поэтому у части татар Заказанья, в частности у проживающих в Лаишевском районе Республики Татарстан чорма представляется обиталищем мифологического персонажа Бичуры, который согласно, своей семантике обитает в заброшенных домах, в захламленных местах рядом с человеком. В обряде задобривания пресные лепешки, приготовленные Бичуре, хозяйки расставляют по углам чердака и приговаривают: *Менә сиңа ризык, тыныч тор, безне борчыма (вот тебе еда, будь спокойным и нас не тревожь).* По мнению наших информантов, если Бичуру не задобрить, то она начинает ходить по чердаку и топать ногами, нарушая покой обитателей дома (*Ашатабыз инде, ничек ашатмыйсың. Төче күмәч пешерәбез дә чорманың дүрт почмагына куябыз. Менә сиңа ризык, тыныч тор, безне борчыма, дибез. Төче күмәчне вакытында бирмәсәң, хәзер лап-лоп йөри башлый, аяклары белән каты итеп тибә. Күренми ул, хәрәкәтеннән аңлыйсың инде Бичура икәнен (Кормим, а как не кормить. Печем пресные лепешки и расставляем по углам чердака. Говорим, вот тебе еда, будь спокойным и нас не тревожь. Если не дать вовремя, то начинает топать ногами, ходить по чердаку. Ее не видно, о ее присутствии понимаешь по тому, как она ходит))* [Прим.1]

Таким образом, символическая функция чормы (чардака) в мировоззренческой системе татар воспринимается как космогонический и антропоморфный коды, воспринятые архетипом небес, вышнего уровня, высоты. В некоторых локальных традициях чорма может восприниматься и как обиталище мифологических существ.

**Литература**


1. Байбурин А.К. Семиотический статус вещей и мифология // Материальная культура и мифология. – Л., 1981. – С. 215-226 (Сборник Музея антропологии и этнографии. Т.37).
2. Байбурин А.К. Жилище в обрядах и представлениях восточных славян. – Л., 1983. – С. 192.
3. Батталова А.Д. Татар халкының мал тотутрадицияләрендәмифотонимнар // Тюркская ономастика от истоков до современности: материалы Международной научно-практической конференции (Казань, 11-14 октября 2018г.) под ред. Г.Р. Галиуллиной. – Казань: Изд-во Казан.ун-та, 2018. – С. 31-34.
4. Богатырев П.Г. Вопросы теории народного искусства. – М., 1971. – С.363.
5. Завгарова Ф.Х. Семантически нагруженный элемент татарского дома как хрематоним // Тюркская ономастика от истоков до современности: материалы Международной научно-практической конференции (Казань, 11-14 октября 2018г.) под ред. Г.Р. Галиуллиной. – Казань: Изд-во Казан.ун-та, 2018. – С.79-82.
6. Мухамедова Р.Г. Татары-мишари. – Казань: Изд -во «Магариф», 2008. – 368 с.
7. Татар халыкмәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. – 2-нче басма. Т.II. – Казан: Татар кит. нәшр., 2010. – 750 б.
8. Халиков Н.А. Сельские поселения и жилища // Татары. – М: Наука, 2017. – С. 346-385.


**Примечания**

1. Записано автором в д. АтабаевоЛаишевского района РТ у Галиуллиной Р.С. (1961г.р.) в 2005 г.


*Замалетдинова Гульнара Фандасовна*
Казанский федеральный университет
Казань, Россия
*Zamaletdinova Gulnara Fandasovna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia


## ОБЩИЕ ВОПРОСЫ ТАТАРСКОЙ ЛЕКСИКОГРАФИИ В НАСЛЕДИИ Р.С. ГАЗИЗОВА
## GENERAL ISSUES OF TATAR LEXICOGRAPHY IN THE HERITAGE OF R.S. GAZIZOVA


Аннотация. *Р.С. Газизов – известный татарский языковед, лексикограф, автор многочисленных учебников и методических пособий по русскому и татарскому*

*языкам. В статье анализируется деятельность ученого в области теории двуязычной или переводной лексикографии.*

Annotation**.** *R.S. Gazizov is a well-known Tatar linguist, lexicographer, author of numerous textbooks and teaching aids in the Russian and Tatar languages. The article analyzes the activitiyof the scientist in the theory of bilingual or translated lexicography.*

Ключевые слова: *Р.С. Газизов, двуязычная лексикография*

Нәҗия апа Борһанованың тарихчы, этнограф, фольклорчы, телче галимнәр өчен кызыклы булган «О системе народного праздника джиен у казанских татар» хезмәтендә [Борһанова, 1982] татарның, теле, гореф-гадәтләре, фольклоры белән беррәттән, чын милли үзенчәлеген тәшкил иткән җыеннар турында сүз бара. Җыеннарның татарлар тормышында әһәмияте зур булган, шунлыктан аларның атамалары, эчтәлеге тарихыбызны ачуда күп серләр саклыйлар. Н. Борһанова беренче чиратта, Казан тирәсендәге үз территориясе, үз атамасы булган йөзгә якын җыенны барлый. Үзенең «Татар топонимиясе» китабында күп тапкырлар андагы фактларны искә алган күренекле галимә Ф.Г. Гарипова Нәҗия апаны һәм аның бу хезмәтен югары бәяли: «Фикерле диалектолог, һәр язган хезмәтен тәфсилле анализ нәтиҗәсендә генә басмага чыгарган галимә Нәҗия Борһанова инде онытылып бетеп барган, халык элек-электән яратып бәйрәм иткән җыеннарның халык-гавәм хәтерендә сакланып калган бер өлешен тырышып җыеп, өйрәнеп, “энә күзеннән үткәреп” тикшерү нәтиҗәсендә бастырып чыгара һәм шушы гамәле белән ул безгә зур бүләк калдыра» [Гарипова, 2018].

Нәҗия апа Борһанова лексикография өлкәсендә дә зур хезмәт куйган галимә. Ул – телебезнең күпсанлы фразеологик байлыгы, мәкаль-әйтемнәре тупланган «Татар теленең фразеологиясе, мәкальләре һәм әйтемнәре» (Казан, 1957), «Русча-татарча фразеологик сүзлек»не (Казань, 1959) төзүчеләрнең берсе. Галимәнең татар сөйләшләренең лексик байлыгын туплаган диалектологик сүзлекләрне төзүдә дә өлеше зур. XX йөзнең утызынчы елларында татарлар яшәгән төбәкләргә фәнни экспедицияләр оештырыла, татар сөйләшләре буенча материал туплана башлый. Шулар нигезендә 1948 нче елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты «Диалектологик сүзлек» бастырып чыгара [Диалектологик сүзлек, 1948]. Шул ук сүзлекнең тулыландырылган икенче чыгарылышы Н. Борһанова, Г. Якупова тарафыннан төзелә һәм профессор Л. Җәләй редакциясендә 1953 нче елда басылып чыга [Диалектологик сүзлек, 1953]. Өченче чыгарылышы Н.Б. Борһанова, Л.Т. Мәхмүтовалар авторлыгында 1959 елда дөнья күрә [Диалектологик сүзлек, 1959]. Еллар дәвамында бай лексик материал да туплана бара, һәм 1969 елда урта һәм көнбатыш диалектларга караган сүзләр тупланган «Татар теленең диалектологик сүзлеге» дөнья күрә. Җаваплы мөхәррире Л. Мәхмүтова булган бу сүзлекне төзүчеләр арасында Н. Борһанова да бар. Ул шулай ук бу хезмәткә кушымта итеп, үсемлекләрнең халык телендәге һәм латин телендәге атамаларын бирә, татар диалектлары буенча кыскача белешмәнең авторы, библиография һәм схематик картаны төзүче дә булып тора. Ботаникага бәйле лексика галимәнең «О татарских народных названиях растений» (1976) мәкаләсендә семантик, аерым лексик берәмлекләрнең килеп чыгышы, номинацияләү мәсьәләсе, сүзьясалыш структурасы ягыннан анализлана. Н. Борһанованың авыл төзелешенә, игенчелеккә караган лексик-

семантик төркемнәрне тикшергән фәнни мәкаләләре дә бар. Алар да зур фактик материалга нигезләнеп, башка төрки телләр, тарихи чыганаклардагы мәгълүматлар белән чагыштырылып бирелә.

1993 елда «Татар теленең диалектологик сүзлеге»нең икенче китабы басыла. Бу сүзлек өчен дә материаллар туплауда төзүчеләрдән тыш әлеге интитут хезмәткәрләре, шул исәптән, Н.Б. Борһанованың материаллары да файдаланыла.

Төзүчеләре бер төркем диалектолог галимнәребез булган «Урта Иделбуе һәм Урал төбәге татар сөйләшләренең атласы» ның (1989) Нәҗия апа җаваплы редакторы була. Бу фундаменталь хезмәтне төзү өчен программаны да Н.Б. Борһанова эшли.

Фәндә «Төхфә-и мәрдән», «Нур-ы содур» поэмалары һәм «Нәсыйхәт» исемле бер шигыре белән билгеле XVI йөз шагыйре Мөхәммәдьяр Казан ханлыгы чоры язма әдәби телен күзаллау өчен иң әһәмиятле чыганаклардан исәпләнә. Олуг шагыйрь Мөхәммәдьяр иҗаты Н.Б. Борһанованың да күз уңыннан читтә калмый. Ул «Төхфәи мәрдан» поэмасындагы фигыль формаларын хәзерге татар теле һәм диалектлары белән чагыштырып өйрәнгәннән соң, поэманың телендә урта төрки һәм тагын да борынгы чор язма истәлекләренә хас фигыльләрнең гадәти китапча төрләре, халык сөйләм теле элементларының күп кулланылуын; поэманың теле урта диалект сөйләшенә якын булуын әйтә [Борһанова, 1980, б. 95]. Галимә татар сөйләшләрендәге үзенчәлекләрне борынгы татар язма әдәби теле ядкарьләре белән дә чагыштырып өйрәнә. «Диалекты татарского языка и памятники древней письменности» (1969), «О некоторых архаичных формах глагола в заказанских говорах» (1971), «Из истории формирования фонетических особенностей татарских говоров Заказанья» (1978) һәм башка мәкаләләрендә диалектлар һәм тел тарихы, диалектлар һәм әдәби тел, диалектлар һәм язма истәлекләр бәйләнеше карала.

Галимәнең тагын бик күп тирән эчтәлекле фәнни мәкаләләрен санап булыр иде. Аның мәшһүр галимебез, Нәҗия апаның фәнни җитәкчесе Латыйф Җәләй турындагы мәкаләсе аңа хөрмәт белән, гаять җылы язылган (1984).

Н.Б. Борһанова «Татар грамматикасы»н (1989) язуда автордаш буларак катнаша һәм авторлар составында Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләгенә ия була. Аның бу хезмәттәге «Сан» бүлеге проблеманың эченә кереп тиешле фәнни-теоретик югарылыкта тәфсилләп язылган [Гарипова, 2003: 4].

Галимә озак еллар Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли һәм лаеклы ялга да әлеге институттан китә.

Нәҗия Борһановна Борһанованың хезмәтләре фәндә югары бәя алып килделәр. Ул эшенә һәрвакыт җаваплы, җитди карады, сыйфатлы итеп башкарды. Н.Б. Борһанова бүгенге көндә филология фәннәре докторы профессор Ф.Й. Йосыповның һәм филология фәннәре кандидаты З.Р. Садыковаларның кандидатлык диссертацияләренең фәнни җитәкчесе булды. Ул «Татар теле һәм әдәбияты» (1965), «Татар теле һәм әдәбияты» (1967)

җыентыкларынредколлегияәгъзасысыйфатында, басмага әзерләүдә катнаша, З.Р. Садыкованың «Оренбург татарлары сөйләше» китабының, бүлектә җыелган җыентыкларның җаваплы мөхәррире булды. Галимә хезмәттәшләре, укучылары, яшьләр белән уртак тел табып эшләде.

Н.Б. Борһанова – татар тел белеменә лаеклы өлеш керткән галимәләребезнең берсе.

**Әдәбият**


Баязитова Ф.С., Бурганова Н.Б. Новые данные о говоре причепецких татар // Исследования по лексике и граматике татарского языка. – Казань, 1986. – С. 91-108

Бәширова И.Б., Хәйретдинова Т.Х. Фәнне галимнәр үстерә // Мәдәни Җомга. – 2004. – 24 ноябрь.

Бурганова Н.Б., Махмутова Л.Т. К вопросу об истории образования и изучения татарских диалектов и говоров // Материалы по татарской диалектологии. Вып 2. – Казань, 1962. – С. 7-18.

Гарипова Ф.Г. Асылташлар тапкан галимә // Актуальные вопросы татарского языкознания. Вып. 2. – Казань: Фикер, 2003. – Б.3-6

Гарипова Ф.Г. Бурганова Нажия Бургановна //Казанская лингвистическая школа:Книга первая:Казанская тюркская лингвистическая школа/ Сост. М.З. Закиев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. – С. 349-350

Гарипова Ф.Г. Татар топонимиясе: халкыбызның географик атамаларында – терминнар. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 456 б.

Бурганова Н.Б. Говор каринских и глазовских татар // Материалы по татарской диалектологии. – Казань, 1962. Вып. 2. – С. 1-5.

Бурганова Н.Б. О татарских народных названиях растений // Вопросы лексикологии и лексикографии татарского языка. – Казань, 1976. – С. 125-142.

Бурганова Н.Б. Из истории формирования фонетических особенностей татарских говоров Заказанья // Источниковедение и история тюркских языков. – Казань, 1978. – С. 76-95

Бурганова Н.Б. О системе народного праздника джиен у казанских татар // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. – Казань, 1982. – С. 20-67

Бурганова Н.Б. Особенности говора татар Нагорной стороны ТАССР // Материалы по диалектологии. – Казань, 1955. – С.28-29.

Бурганова Н.Б. Система глагола поэмы Мухамедьяра «Төхфәи Мәрдан» (XVI в.) // Исследование языка древнеписьменных памятников. – Казань, 1980. – С.66-97

*Камаева Рима Бизяновна*
Казан федераль университетының Алабуга институты
Алабуга, Россия
*Kamaeva Rima Bizyanovna*
Elabuga Institute of the KazanFederalUniversity
Elabuga, Russia

# ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ДИАЛЕКТИЗМНАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ
# THE FUNCTIONING OF DIALECTICISMS IN THE WORKS OF TATAR WRITERS

Аннотация. *В данной статье исследуется употребление диалектизмов в текстах художественной прозы татарских писателей. Автор наглядно представляет фонетические, морфологические и лексические особенности диалектных лексем, использованных в художественных текстах. Определяются способы перевода татарских диалектизмов на русский язык.*

Annotation. *This article examines the use of dialectics in the texts of Tatar writers' prose. The author clearly presents phonetic, morphological and lexical features of dialect lexemes used in literary texts. The ways of translation of the Tatar dialectsinto the Russian language are determined.*

Ключевые слова. *Диалектизм, художественная литература, местный колорит, фонетические диалектизмы, морфологические диалектизмы, лексические диалектизмы.*

Keywords. *Dialectism, fiction, local color, phonetic dialectisms, morphological dialectisms, lexical dialectisms.*

Татар халкы тарихына караган әсәрләрдә аның тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре, гореф-гадәтләре, кешеләрнең эш-гамәлләре һәм хис-тойгылары сурәтләнә. Шул уңайдан, язучылар еш кына халык рухын чагылдырган җирле сөйләш үзенчәлекләрен дә әсәр тукымасына кертеп җибәрәләр. Алар нигездә персонажлар сөйләменә хас булалар һәм теге яки бу образның шәхси сыйфатларын – аның белем дәрәҗәсен, фикерләү үзенчәлеген, характерын күрсәтү өчен дә хезмәт итәләр. Җирле сөйләм үзенчәлекләрен җыйнап атау өчен диалектизм терминын кулланалар. Диалектизмнарны түбәндәге төркемнәргә аерып йөртәләр: лексик диалектизмнар – әдәби телдә булмаган яки башка мәгънәдә кулланылучы сүзләр; фонетик диалектизмнар – әдәби телдәге сүзләрдән аваз төзелеше белән аерыла торган сүзләр; грамматик диалектизмнар – сүз төзелешенә һәм сөйләм оешуга караган очраклар [Әхәтов, 1995: 80].

Без бу эшебездә әдәби әсәрләрдә диалектизмнарның кулланылыш үзенчәлеләрен һәм рустеленә тәрҗемә итү үзенчәлекләрен ачыклауны максат итеп куйдык. Лексик материал буларак татар язучылары Ә. Еники, М. Хәбибуллин, Р. Мөхәммәдиев, Т. Галиуллин, Ф. Сафин әсәрләреннән алынган диалект сүзләре файдаланылды. Диалектизмнар әдәби әсәрләрдә язучылар

тарафыннан махсус кулланыла, алар сөйләмгә билгеле берстилистик төсмер бирә, җирле колоритны тасвирлый. Әдәби әсәрләрдән алынган диалектизмнарны без берничә төркемгә бүлеп тикшердек.

I. *Фонетик диалектизмнар.* Фонетик диалектизмнар әдәби сүзләрдән үзләренең аваз составындагы үзгәрешләр белән аерылып торалар.

1. Тикшерелгән фонетик диалектизмнарның күбесе *җ*- лаштыру белән бәйле. Мәсәлән: *җегет* – егет, *җегетлек* – егетлек,*җыгылу* – егылу, *жылау* – елау, *җырактан*– ерактан, *җурган* – юрган, *җүләр* – юләр, *җүнле* – юньле.*җә* – я, *җәме* – яме, *җәтрәк* – ятьрәк, *җал итә* – ял итә, *җарар*– ярар, *җанмыйдыр* – янмыйдыр,

Бәләкәй буйлы *җегетләрне* кызлар никтер ярата бит [Ф.С. «Саташып аткан таң», 2014: 91].– *Җәтрәк, җәтрәк,* өтек-әлән, ятим бәрән кузгалдык [М.Х. «Шайтан каласы», 1993: 89].

2. Әдәби телдәге **з** урынына интердентальˌ ***ʒ(д)*** кулланыла:*беʒнең* – безнең, *хәʒер* – хәзер, *Аʒат* – Азат.

Менә *бед* монда карап торадырыек әле… Иеме, *Адат*!..[Р.Мөхәмәдиев «Ак кыялар...», 79]. –Адатның атасы белән беднең әтидән качкан кәҗә ул, бик беләсегед килсә…[Р.Мөхәмәдиев «Ак кыялар...», 69].

3. Сүз яки иҗек башында ***з*** яңгырау тартыгы ***р*** тартыгы белән тәңгәлләнә: үткәзеп – *үткәреп*.

Мәсәлән: Күрәсең, авыруы аның болай бер-ике көн генә ятып *үткәзеп* җибәрерлек түгел иде [М.Х. «Кубрат хан»,1983: 271].

4. Сүз яки иҗек башында ***у*** сузыгы ***ы*** сузыгы белән тәңгәлләнә: булды – *былды, шыл* – шул.

– Су эчкәч тә моңа әллә нәстә *былды,* мәтәлеп ята [М.Х. «Шайтан каласы», 1993: 42].

5. Сүз яки иҗек ахырында ***ү*** сузыгы ***ө*** сузыгы ***өй*** дифтонгының таралышы чагылыш таба: *сүләшә* – сөйләшә, *күләп ал* – көйләп ал.

Мәсәлән: – Урысча *сүләшәсеңме*? – дип сорады Всеволод, ниһаять. – *Сүләшәм,* кенәз, – диде Илһам [М.Х. «Шайтан каласы» 1993: 31]. «– Мин синең турыда әтигә, әнигә *сүләдем*» [Т.Г. «Төнге юллар», 2005: 78].

6. *ый-и* дифтоглары урынына -*ай-әй* кулланыла*: әпәй* – ипи, *дулай* – дулый, *кирәкмәй* – кирәкми*, мондай* – мондый, *түтәй* – түти.

«– Акыл бирү җиңел лә ул, тамак ачыкса, күзгә *әпәйдән* башка бер әйбер дә күренми, – диде Фатыйх» [Ф.С. «Саташып аткан таң», 2014: 134].

7. *иде* ярдәмче фигыльдә *д* авазының төшеп калуы күзәтелә: *алганые* –алган иде, *андае* – анда иде, *барганые* – барган иде, *бетәрие* – бетәр иде, *торганые*– торган иде, *уйлаганые* – уйлаган иде, *якынаергае*– якынаерга иде, *югые* – юк иде.

«– Миңа сеңлем Әлфия *кирәгие*» [Т.Г. «Төнге юллар», 2005: 583].»– Мин бернәрсә *уйлаганыем*, бикә» [Н.Ф. «Ител...», 1980: 55].

8. Рус алынмаларын диалект сөйләменә яраклаштырып кулланыла: *персидәтел* – председатель, *нәчәлник* – начальник, *бәбүсә* – бабуся, *әткрет* –

открытка, *Кимероу*–Кемерово, *пәрәхуд*–пароход, *бүчкә* – бочка, *яшнек* – ящик, *закун* – закон, *хет*–хоть, *тач*–точно.

*–Персидәтелнеке – персидәтелчә***,** бригадирныкы бригадирча булырга тиеш [Р.М. «Истәлек өчен – Гыйлемханга»,1995: 12]. – Койган да куйган дим, *тач* атаң икәнсең...[Р.М. «Истәлек өчен – Гыйлемханга»,1995: 22].

«–Мәйтәм, сеңлем янында яшәп, бергә *тиәтерләргә* йөреп, җилләнеп кайтыйм әле, дип килдем» [Т.Г. «Төнге юллар», 2005: 584].

2. Лексик диалектизмнар. Тикшерү өчен алынган лексик диалектизмнарны мәгънәләре буенча берничә төркемгә берләштердек: 1) туганлыкны белдергән диалекталь сүзләр: ага, аба– *абый*, бичә – хатын, инәй – *әни,* олан – *ир бала,* наный – *кечкенә.*

Аба (й)1. *т.кам.- крш. кргл. абый (старший брат*) [ТТДС 1993: 15].

Бичә трбс., стрл. хатын (жена) [ТТДС 1993: 56].

Олан *кас. бала* (ребенок, младенец) [ТТДС 1993: 239].

Наный *каз.ар.-лш.* к. апайым, шрл. 1)эне яки сеңел һәм аларга эндәшү; 2) үзеннән яшьрәкләргә иркәләп эндәшү сүзе [ТТДС, 1993: 29].

– Баһадирым, балам, *оланым,* – дип бертуктаусыз тәкрарлады төп тәңре [М.Х. «Кубрат хан», 1985: 175]. Назыйм, билгеле, кызны танымаган, Миңлегалинең яшь *бичәсе* шулдыр дип башына да китермәгән [Р.М. «Истәлек өчен – Гыйлемханга», 1995: 62].

2) кешеләргә, әйберләргә характерлы сыйфатларны белдерүче диалекталь сүзләр: иләс – *акылсыз***,** сырхау – *чирле кеше,* тымызык – *тыныч,* кәшәлеп бетү – *ярылып бетү*, белекле – *белемле*, үзгә – *гадәттәгечә түгел, башкача*, карусыз – *буйсынучан.*

– Миңа халкымның *карусыз* буйсынуы кирәк [М.Х. «Кубрат хан», 1985: 44]. Сакчыларның кулларында капкада торган сакчыларны кебек айбалталы сөңге түгел, ятаган, киемнәре дә кыска, *үзгә* иде [М.Х. «Кубрат хан», 1985: 172].

3) хәрәкәтнең билгесен белдерүче сүзләр**:** җәтрәк – *тизрәк*, гелән – *гел.*

Җәт *чст.крш.* тиз [ТТДС, 1993: 419]. Гелән *минз. стрл. карс.* к. бер буйдан *т.я.- трх. мәл., чст.* һаман, бертуктаусыз, өзлексез [ТТДС, 1993: 50].

– *Җәтрәк, җәтрәк,* өтек-әлән, ятим бәрән кузгалдык [М.Х. «Шайтан каласы», 1993: 89]. Кыз матур иде*, гелән* үзенә тартып тора иде [М.Х. «Кубрат хан», 1985: 103].

4) хәрәкәтне белдерүче сүзләр: кинәнү – *рәхәтләнү,* багу – *тәрбияләү, карау,* иләсләнү- *акылсызлану,* чыгымчалау – *түзеп тора алмау,* дәшү – *эндәшү,* тымызу – *тынычландыру*, талку – *кат-кат сорау.*

Кинәнү *мәл. стр.* к. киңәнү, бик нык шатлану, куану [ТТДС, 1993: 176].

Багу 1. *нокр., бәр., кргл.* карау. 2 *нокр., глз, бәр, каз.ар.* - *әтн.,кргл.* карау, тәрбияләү, асрау. 3. *кргл.* көтү [ТТДС, 1993: 42]. Чыгымчалау *каз. ар.-дөб. киреләнү* [ТТДС, 1993: 359]. Дәшү *злт., трбс.* к. йәшү 1. *каз.ар.-блт, каз.ар.-ләш, каз. ар.-дөб, т.-я.-трх.* эндәшү, сүз кушу. 2. *т.-я.-трх.* чакыру [ТТДС 1993: 121].Тымызу *кргл.* тынычландыру [ТТДС, 1993: 310]. Талку *каз.ар.-дөб.* тинтерәтү, кат-кат сорау (докучать) [ТТДС, 1993: 286].

– Ул миңа ата булган кеше, ул мине *бакты,* сараенда белем бирде [М.Х. «Шайтан каласы», 1993: 155].

5) көнкүрештә кулланыла торган предметлар, әйберләр: күләсә – *тәгәрмәч,* чокыр – *чынаяк.*

Куласа (*рус.* колесо) 1. *байк., стр.* к. йөгертмә *т.-я. крш.* тәгәрмәч [ТТДС 1993: 121]. Чокыр *т.-я.-трх.* к. дустыган,*стрл.* касә [ТТДС 1993: 87].

– Бүген кол, иртәгә никахлы кияү, дөнья *күләсә,* әйләнә дә бер баса, ди Ага-Базар халкы [М.Х. «Шайтан каласы», 1993: 10].

3.Морфологик дилектизмнар.

Диалектизмнарның морфологик үзенчәлекләре фигыль, сан, рәвеш, алмашлык сүз төркемнәрендә күзәтелә.Мәсәлән: килү кирәк иде – *килергә кирәк иде*, ала керермен – *кереп алырмын,* җиткерең – *җиткер*, ризамындыр – *риза,* сак булың – *сак бул,* берәвесе, берәүсе – *берәү,* әүвәлтен *–әүвәл,* андыен – *андый. ниямәрсә - нәрсә.*

– Мин сезне беразданала *керермен* [М.Х. «Кубрат хан», 1985: 277].– *Сак булың,* ул тарафта әллә кемнәрнең очрап куюы бар [М.Х. «Шайтан каласы» 1993: 40]. – *Ниямәрсәгә* соң ул? Микәй булмый бит инде ул…– Беләм, беләм… Ник *апчыкканнарын* беләм, – дип серле елмаеп куйды Вакыйф [Р.М. «Ак кыялар...», 1995: 77].

Диалектизмнарны тәрҗемә теленә күчерүдә билгеле бер авырлыклар бар. Кайбер тәрҗемә теоретиклары күрсәткәнчә, диалектизмнарны тәрҗемә теленә диалекталь сүз белән биреп булмый. Тәрҗемә теориясе һәм практикасы бу мәсьәләгә башкачарак карарга кирәклекне белдерә. Әдәби әсәрләрне тәрҗемә иткәндә диалекталь сүзләрне тәрҗемә теленә күчерүдә кыенлыклар туа. Бу мәсьәләдә тәрҗемәчедән ике телнең дә үзенчәлекләрен яхшы белү таләп ителә.

Әдәби әсәрләрне тәрҗемә вариантлары белән чагыштырып тикшерү нәтиҗәсендә, түбәндәге тәрҗемә ысуллары кулланылу ачыкланды:

1. *Диалекталь характерда булмаган гади сөйләм элементлары куллану.* Мондый чаралар һәр телдә дә була, һәм алар тәрҗемәне укучыларда оригиналны укучыларда кебек үк тәэсир тудыра алалар. Мәсәлән:»Башта *җүнле* уй юк» [Ф.С. «Саташып аткан таң», 2003: 70]. / «Да и в голове ни одной *путной* мысли нет» [Ф.С. «Заблудившийся рассвет», 2014: 60].

2. *Аңлатма бирү юлы белән тәрҗемә итү.*

Мунча нык итеп, иркен итеп таштан салынган иде. Башта ак бүреләр җыйнаулашып *чарачага* керделәр...[Н.Ф.»Ител...», 1980: 26]. Сначала вступили *в предбанник – чарача...*[Н.Ф. «Итил-река течет», 1982: 30].

3.*Тасвирлама тәрҗемә.*

«– Минем сүзем ул хакта түгел иде, Фирая *ахири*» [Т.Г. «Төнге юллар», 2005: 579]. / «–Я хочу открыть вам одну свою тайну, как своему *близкому другу*» [Т.Г. «Ночные дороги», 2008: 177].

3. *Транслитерация, транскрипция.*

«– *Атам,* мин сезнең алга баш иеп килдем» [М.Х. «Шайтан каласы», 1993: 11]. / «–*Атам,* я пришел к вам с повинной головой» [М.Х. «Чертово городище», 2005: 337].

Әдәби әсәрләрдә кулланылган диалектизмнар шул якның милли колоритын сурәтли. Язучылар күбесенчә үзләре яшәгән төбәкнең җирле сөйләм үзенчәлекләреннән файдаланалар. Диалект лексикасын куллану әсәрнең темасына, сурәтләү объектына, авторның максатына, эстетик идеалына, осталыгына бәйле. Диалектизмнарны тәрҗемә теленә күчерүдә билгеле ысуллар кулланыла. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, диалектизмнар рус теленә гади сөйләм элементлары, тасвирлама тәрҗемә, транслитерация һәм транскрипция ысуллары ярдәмендә күчерелә.

**Әдәбият**


1. Галиуллин Т.Н. Төнге юллар // Сәет Сакманов: Роман-трилогия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. –656 б.
2. Галиуллин Т.Н. Ночные дороги. Роман. Перевод Мухаметшиной Н.М. – М.: Голос-Пресс, 2008. – 256 с.
3. Камаева Р.Б. Национально-специфический корпус татарской лексики в современной прозе: лингвостилистические характеристики и способы перевода на русский язык: дис. …д-ра филол. наук. Уфа, 2017. – 346 с.
4. Мөхәммәдиев Р.С. Ак кыялар турында хыял. Повесть, хикәяләр. – Казан: Мәгариф, 1995. – 240 б.
5. Сафин Ф.М. Саташып аткан таң: роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 726 б.
6. Сафин, Ф.М. Заблудившийся рассвет: роман. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. – 664 с.
7. Татар теленең диалектологик сүзлеге / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 459 б.
8. Фәттахов Н.С. Ител суы ака торур:тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 398 б.
9. Фаттахов Н.С. Итиль-река течет. Роман. Переводчик Зарипов М. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1978. – 367 с.
10. Хәбибуллин М.М. Кубрат хан: Роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 376 б.
11. Хәбибуллин М.М. Шайтан каласы. Тарихи роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 303 б.
12. Хабибуллин М.М. Чертово городище: Роман. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – С. 330-607.
13. Kamaeva R.B. (2014). National cultural specifics of representing dialecticisms in the fiction work translation. Life Science Journal, 11(10), 95, 653-656.

*Каримов Салават Гайсич*
БРның Мәгарифне үстерү институты
Өфе, Россия
*KarimovSalavat Gaisich*
Institute of education development RB
Ufa, Russia

# ӨФЕ ГОДОНИМНАРЫНДА ТУГАНДАШ ТАТАР ХАЛКЫ МӘШҺҮР ШӘХЕСЛӘРЕНЕҢ ИСЕМ-ФАМИЛИЯЛӘРЕ
# NAMES AND SURNAMES OF PROMINENT PERSONALITIES THE TATAR PEOPLE IN THE GODONYMS OF UFA

Аннотация. *Среди годонимов города Уфы имеется ряд названий улиц, данных в честь выдающихся личностей татарского народа. Своей самоотверженной и благородной деятельностью они снискали у жителей Башкортостана безграничную любовь и славу в разные периоды жизни республики. По тематике годонимы Уфы можно подразделить на следующие виды: а) улицы и бульвары, носящие имена и фамилии видных государственных деятелей, б) улицы, носящие имена и фамилии поэтов и писателей, в) улицы, носящие имена и фамилии видных работников образования.*

Annotation. *There are a number of street names given in honor of outstanding personalities of the Tatar peopleamong the hodonyms of the city of Ufa.. With their selfless and noble activities they have won the people of Bashkortostan boundless love and fame in different periods of life of the Republic. On the subject of hodonimy Ufa can be divided into the following types: a) streets and boulevards bearing the names of prominent public figures, b) streets bearing the names of poets and writers) streets bearing the names of prominent educators.*

Ключевые слова. *Годонимы, выдающиеся личности, татарский народ, тематика, деление.*

Keywords. *Hodonimy, outstanding personalities, Tatar people, subjects, division.*

Уку йортларында туган як топонимиясен өйрәнү туган тел буенча алган белемнәрне системага салу, аны тагын да тирәнәйтү, үстерү, ныгыту һәм яшәеш белән тыгыз бәйләп тормышка ашыруны күздә тота. Топонимика фәне барлык географик объектларның атамаларын өйрәнә. Галимнәр топонимнарны, нигездә, гидронимнарга, оронимнарга, урбанонимнарга (шәһәр эчендәге географик объектларга) аерып тикшерәләр.

Урбанонимнарның зур катламын проспект, урам, бульвар, тыкрык, ара(лык), шоссе һәм мәйданнар тәшкил итә. Аларның атамаларында торак пунктының тарихы, анда яшәүчеләр арасында булган төрле хәл-вакыйгалар турында мәгълүматлар үзенчәлекле чагылыш таба. Мондый төр топонимнарны анализлау һәм тикшерү каланың һәм төбәкнең, илнең тарихы, мәдәният үсеше, илнең хәзерге чор тормышы турында мөһим һәм кирәкле фактларны бирә.

Башкортстанның башкаласы Өфе бүген республиканың, Рәсәйнең административ-сәяси, икътисади, фәнни һәм мәдәни үзәге булып тора. Агыйдел елгасына Караидел һәм Дим агымсулары кушылган җирдә урнашкан башкалабызның мәйданы 750 квадрат километр.

Бүген Өфедә 1400дән артык урам, проспект, тыкрык, ара(лык), бульвар, шоссе, тракт бар [Карта города Уфы, 2007]. Аларның 250се конкрет шәхесләр исеме белән бәйле. Күренекле революционерлар, сугыш һәм хезмәт ветераннары, фән эшлеклеләре һәм мәдәният хезмәткәрләре арасында күп милләтле әдәбиятыбызның абруйлы вәкилләре, язучы-шагыйрьләре дә бар. Өфенең беренче урамнары 1574 нче елда төзелә башланган крепость капкалары яныннан башланган юл буйлап барлыкка килгән. Шулардан Казан һәм Себер яклары юнәлешендә *Зур Каз*ан (хәзер Октябрь революциясе) һәм *Зур Себер* (Минһаҗев) урамнары барлыкка килүен билгеләргә кирәк. Үткән гасырларда шәһәрнең чикләре акрынлап киңәя барган. Тәүге урамнарга өстәлеп, төрле юнәлештә яңалары төзелә һәм озыная барган. Мәсәлән: *Зур Ильин* (хәзер Зәки Вәлиди), *Фролов* (хәзер Тукай урамы), *Сергеев* (Менделеев), *Успенский* (Сочи) урамнары.

18 нче гасыр азагында Өфе шәһәре чагыштырмача зур булмаган мәйданны биләгән. Анда барлыгы 32 урам, тыкрык һәм бистә исәпләнгән.

1802 нче елдан Өфе шәһәре губерна үзәгенә әйләнә. Патша Александр I имзасы куелган план буенча, Өфе урамнары билгеле тәртип һәм норма нигезендә төзелә башлый. Шәһәр хәзерге *Гафури* һәм *Революцион* урамнары чикләренә кадәр үсә, зурая. 1886 елгы җан исәп алу буенча Өфедә 59 урам теркәлгән.

Урамнарга исем-атама бирү шәһәр думасының карары нигезендә тормышка ашырылган. Дума әгъзалары урамнарга исем биргәндә яки аларны үзгәрткәндә җирле шартларда гына түгел, ә бөтен Рәсәй масштабыннан чыгып эш иткән. Мәсәлән, 1899нчы елда элекке *Голубиная урамы* бөек рус шагыйре А.С. Пушкинның 100 еллык юбилее уңаеннан, *Пушкин урамы* дип атала башлый. 1908 нчы елда Өфе шәһәрендә 200гә якын урам һәм тыкрык булган.

Урам атамалары барлыкка килүнең бер принцибы булып торак пунктларында яшәүчеләрнең конкрет кешегә, аның башкарган эш-гамәлләренә тирән ихтирам билгесе, уңай карашы тора. Өфе урамнарына башкалада, Башкортстанда туып-үскән һәм шуңа бәйле шәхесләрнең исемнәре генә түгел, ә бөтен илгә танылган күренекле дәүләт эшлеклеренең, шулай ук галимнәрнең, язучыларның, рәссамнарның, композиторларның, артистларның, полководецларның, сугыш каһарманнарының исемнәре бирелгән. Өфе урамнарының байтак өлеше рус, башкорт, татар һәм башка халыкларның атаклы әдипләре исемен йөртә.

Башкортстан Республикасы хөкүмәте урамнарның элек бирелгән исемнәрен алмаштырганда һәм яңа урамнарга исем биргәндә, башкорт һәм тугандаш татар халыкларының билгеле язучы һәм шагыйрьләрен олылап һәм тирән хөрмәт йөзеннән чыгып эш итә.

Башкорт һәм татар халыкларының какшамас дуслыгы аларның атаклы шәхесләренең очрашу һәм күрешүләрендә дә чагылыш таба. Билгеле булуынча,

1912 нче елның язында бөек татар шагыйре Габдулла Тукай, Троицк якларына кымыз белән дәваланырга барышлый, ике тапкыр Өфегә килә. Биредә ул башкорт һәм татар халыкларының уртак шагыйре Мәҗит Гафури белән очраша, алар әдәбият, әдәби процесс турында фикер алышалар. Тукай шулай ук Өфедәге иҗади көчләр белән аралаша.

Үзенең халыкчан иҗаты белән төрки халыкларына киң билгеле булган Габдулла Тукай исеме Өфедәге бер урам атамасы буларак мәңгеләштерелә: элекке *Югары Фролов* һәм *Воскресенская урамнары* кушылуыннан барлыкка килгән урамга 1924 елда *Тукай* исеме бирелә [Узиков, 2007: 255]

Башкортстанның халык шагыйре Мәҗит Гафури (1884-1934) Өфе губерниясе Эстәрлетамак өязе Җилем-Каран авылында туа. Башта Троицк, аннары Өфедәге дини-дөньяви «Галия» мәдрәсәсендә белем ала. Газеталарда журналист булып хезмәт сала, шигырьләр җыентыклары бастыра. Шигырьләрендә ул хезмәт ияләренең аһ-зарын тасвирлый, гаделлек өчен, азат тормыш өчен көрәшкә өнди. Гражданнар сугышы елларында ул героизм, революциягә бирелгәнлек темасын яктырта, лириканы гражданлык публицистикасы дәрәҗәсенә күтәрде. Шагыйрь яңа тормыш төзүчеләрне рухланып сурәтләде. 1923нче елда Өфенең Никольская урамы *Гафури урамы* исеменә үзгәртелә [Узиков, 2007: 55].

Башкортстанда туып-үскән һәм Өфедәге данлыклы «Галия» мәдрәсәсендә 1915-1917 нче елларда татар теле һәм әдәбияты фәннәрен укыткан, каладагы 1917 нче елгы революцион хәрәкәттә актив катнашкан, азак, Казан шәһәренә күчеп, татар әдәбияты үсешенә күп көч салган, күпкырлы галим, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе буларак танылу алган Галимҗан Ибраһимовка олы хөрмәт йөзеннән Өфедәге яшеллеккә күмелгән бульварны 1960 елда *Ибраһимов бульвары* дип атый башлыйлар. Элек аны «Урал проспекты» дип йөрткәннәр [Синенко, 2010: 237]

Күренекле татар шагыйре, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил берничә мәртәбә Өфедә, Башкортстанда булган. Үткән гасырның 30нчы елларнда шагыйрь «Йоматау» шифаханәсендә, Чишмә районының Кара Якуп авылында кымыз белән дәвалана, ял итә, иҗади җәмәгатьчелек белән аралаша, шигъри кичәләр үткәрә. Герой-шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү йөзеннән Өфенең Дим районындагы элекке Куйбышев урамы 1956 нчы елда *Муса Җәлил урамы* дип үзгәртелә.

Татар халкының күренекле улларының берсе – ялкынлы революционер-оештыручы Хөсәен Ямашев Өфедә 1905-1907 нче елларда яши, РСДРПның Өфе комитетына кертелә, революция идеяләрен татар-башкорт хезмәт ияләренә үз телләрендә таратучы «Урал» газетасын чыгару эшендә актив катнашучы була. Өфенең Орджоникидзе районындагы элекке Первухин урамы урынына 1957 нче елда *Хөсәен Ямашев урамы* исеме бирелә.

Өфе халкының тарихи хәтере шәфкатьле һәм рәхимле. Өфедә туып-үскән, барлык гомерен хезмәт ияләрен якты һәм азат тормышка чыгарырга көрәшкә биргән революционер, күренекле дәүләт эшлеклесе Сәхиб-Гәрәй Сәед-Галиевнең исеме1964 елда яңа барлыкка килгән матур бер бульварга бирелә.

Башкортстанда 1917 нче елдагы социалистик революциядән соң халык мәгарифен оештыруга бөтен көчен биргән Шәриф Сүнчәләйне дә республика хөкүмәте хөрмәтли. Ул губерна халык мәгарифенең мәктәп бүлеген җитәкли, «Мәгариф фронты» педагогик журналының беренче редакторы була. Шушы елларда аның татар телендә язылган «Балалар бакчасында практик эшләр» (1921) дигән беренче педагогик хезмәте басыла. 1922-1927 нче елларда ул республикада мәгариф халык комиссарының урынбасары вазифасын башкара. Шул елларда аның «Бәләкәй балалар белән әңгәмәләр», «Башкортстан турында гомуми мәгълүматлар» һәм «Башкортстанда крайны өйрәнү эшләре» хезмәтләре дөнья күрә. Бу педагогик хезмәткәрнең исемен мәңгеләштерү теләге белән Өфенең бер урамына *Сүнчәләй урамы* исеме бирелә.

Башкортстанда туып-үскән, Октябрь революциясенә кадәр күренекле «Галия» мәдрәсәсендә белем алган Кәрим Хәкимов гражданнар сугышы елларында гади кызылармеецтан зур хәрби командирга кадәр күтәрелә. Совет дәүләте Көнчыгыш илләре белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру максаты белән аны башта Иранга, аннары Согыд Гарәбстанына, Ямәнгә илче итеп җибәрә. Аның шәхси тырышлыгы белән ул илләрдә Совет хөкүмәте белән тотырыклы сәүдә һәм сәяси багланышлар урнаша. Әмма 1937 елда күренекле дипломат репрессиягә эләгә, гомере өзелә.

Бу легендар тарихи шәхеснең якты образы Өфе урамнарының берсендә саклана: 1965 нче елда Өфенең Калинин районындагы яңа бер урамына *Хәкимов урамы* исеме бирелә [Узиков, 2007: 273].

Өфе урамнарының билгеле шәхесләргә багышлап бирелгән атамалары тематик яктан түбәндәге төркемнәргә бүленә: а) күренекле дәүләт эшлеклеләре исем-фамилияләрен йөрткән урамнар; ә) атаклы язучылар һәм шагыйрьләрнең исем-фамилияләрен йөрткән урамнар; б) күренекле мәдәният һәм мәгариф хезмәткәрләре исем-фамилияләрен йөрткән урамнар.

**Әдәбият**

Карта города Уфы. Вып. 4 с изменениями и дополнениями. – ООО “Виртуал”. – Екатеринбург: Печатный дом “Формат”, 2007.

Синенко С.Г. Неторопливые прогулки по Уфе. Городской путеводитель. – Уфа: Китап, 2010. – 376 с.

Узиков Ю.А. Уфимских улиц имена. – Уфа: Уфимск. полиграфкомбинат, 2007. – 320 с.

*Каюмова Гөлүсә Фәритовна*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Kayumova Gulusa Faritovna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

# ӘДӘБИЯТТА ҖӘМГЫЯТЬ һӘМ УКЫТУЧЫ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ БИРЕЛЕШЕ
# REFLECTION IN LITERATURE OF THE RELATIONSHIP BETWEEN SOCIETY AND A TEACHER

Аннотация. *В статье рассматривается воплощение образа учителя в татарской литературе. Автора статьи интересуют отношения общества и учителя. На основе литературных произведений, приводит примеры трагических последствий отношений общества и учителя, делает вывод о том, что педагог должен сохранить себя как личность и только затем служить идеологии.*

Annotation. *The article deals with the embodiment of the image of the teacher in Tatar literature. The author of the article is interested in the relations of society and teachers. On the basis of literary works, he gives examples of the tragic consequences of the relations between society and the teacher, concludes that the teacher must preserve himself as a person and only then serve the ideology.*

Ключевые слова: *учитель, А. Баян, архетип учителя, мотив страдальчества, личностно значимые качества учителя.*

Keywords. *A. Bayan, archetype of a teacher, motive of suffering, personally significant qualities of a teacher*

Бүгенге көндә җәмгыятьнең мөгаллим шәхесенә карата аеруча игътибарлы булуы ачык сиземләнә. Әлеге игътибар төрлечә күрсәтелә: бер яктан, җәмгыятьтә мөгаллим хезмәтенең киләчәк язмышыбыз өчен әһәмиятен аңлау тенденциясе күзәтелсә, икенче яктан, моны аңлау мөгаллимгә өстәмә таләпләр кую өчен алшарт та булып тора. А. Бизяева, К. Левитан, Е. Хорева һ.б. галимнәр, белгечләр укытучы шәхесенә хас булырга тиешле сыйфатларны, укытучы ия булырга тиешле кыйммәтләр системасын өйрәнәләр, әһәмиятлеләр рәтендә даими үзконтроль, педагогик такт, күзәтүчәнлек, һөнәри осталык, балаларның физик, рухи, әхлакый һәм акыл үсеше турында кайгыртучанлык, түземлек, сизгерлек һ.б. бик күпләрне атыйлар [Бизяева, 2004; Левитан, 1993; Хорева, 2011]. Мондый хезмәтләрнең педагогика фәне, гомумән, укытучылар укуы өчен кыйммәте зур. Шул ук вакытта тормышның көзгесе булган әдәбиятта да укытучы образының бирелешен анализлау гаҗәеп зур әһәмияткә ия. Әлеге эшебез кысаларында безне бигрәк тә Ә. Баяновның «Урланган ай» повесте, шулай ук аталган повестьтәге укытучы образын чагыштырма аспектта өйрәнү максаты белән М. Әмирнең «Саф күңел» әсәрендәге аерым мөгаллим образлары да кызыксындыра.

Ә. Баяновның «Урланган ай» повесте җәмгыять һәм укытучы мөнәсәбәтләрен бөтен каршылыклы яклары белән ачкан әсәр буларак бәяләнергә хаклы. 1994 елда язылган әлеге әсәр үзәгендә Бөек Ватан сугышы елларында укытучылык иткән Марва язмышы тора. Тырыш, фидакарь укытучы Марва мөгаллимгә хас булырга тиешле барлык уңай сыйфатларны үзләштергән герой буларак бирелә. Совет чоры әсәрләрендә укучы Марвадай тырыш, сабыр, шәхси бәхетен иҗтимагый вазыйфалар хакына корбан итәргә әзер каһарманнарның гаиләдә дә, коллективта да ихтирам казануына күнеккән иде. Әйтик, М. Әмирнең «Саф күңел» роман-дилогиясендәге укытучы, директор Сания Ибраһимованың мәктәп эшләре белән йөрүе, депутатлык вазифаларын башкару бөтен вакытын диярлек ала. Ә бит аның әле Хәсән исемле улы, күкрәк баласы бар. Шиксез, алар, гөнаһсыз балалар, сугыш шаукымын тоеп үсәргә мәҗбүр булалар. Хәсән – әнисенең ярдәмчесе булса, нәни Розочка башта абыйсы һәм Ольга Дмитриевна карамагында, соңрак иртәдән кичкә кадәр яслидә торырга мәҗбүр була. Әлеге шартлар аналар һәм балалар арасында бернинди киртә куймый, салкын мөнәсәбәтләргә юл ачмый. Ә.Баяновның “Урланган ай” повестенең төп героинясы Марва да күпмедер дәрәҗәдә Сания Ибраһимовага якын тора. Сугыш елларына кадәр үк ул инде шактый тәҗрибәле укытучы, бер бала анасы буларак җитешә. Аның үзенчәлекле сыйфатлары – намуслылык, тырышлык, үз эшенә ахыр чиккәчә бирелгәнлек. Ләкин ил эчендә бара торган зарарлы сәясәткә кушылу, аңа чын күңелдән ышану аны һәлакәт юлына этәрә бара. Эш хакына баласы мәнфәгатьләрен читкә тибәрү ана белән бала арасын ерагайта бара, нәтиҗәдә табигате белән акыллы, зирәк малай – Мэлс – Мәлх – Мәлих – Михаил җинаять кылуда катнаша, бозыклык юлына баса. Биредә гаеплеләрне атау үтә кыен. Үзе дә укытучы, галим, язучы С.Г. Исмәгыйлева фикеренә тукталыйк. Ул әлеге повестьның темасын: «укытуның, киләчәк буынны тәрбияләүнең сәяси һәм рухи әһәмиятен, ил каршындагы изге бурычының намус белән үтәлергә тиешлеген аңлаган, көн-төн шуңа хезмәтен куйган һәм ... нәтиҗәдә шәхес буларак юк ителгән укытучы темасы» буларак билгели [Исмәгыйлева, 2010: 16]. Чынлап та, илебездә дистәләгән еллар буена сугыш һәм тынычлык бер-берсен алыштырып, шулай ук үзара үрелеп торган вакытларда, тоталитар хакимлек шартларында укытучының профессиональ яктан чыныгу, җаваплы эшкә күмелү һәм, шуның белән бергә, шәхес буларак җимерелә бару фаҗигасен гәүдәләндерү ягыннан Ә. Баяновның әлеге әсәре әдәбиятыбызда кабатланмас урын били. Мәрүә – Марваның башыннан кичкән вакыйгалар, безнең фикеребезчә, аның үз-үзен тулы канлы шәхес итеп тоймавы, башкалар – ул яшәгән чор вәзгыяте, хакимлек вәкилләре, җәмгыять алдындагы бурыч таләп иткәнчә яшәве белән дә беркадәр аңлатыладыр. Аның ире – Денис Михайловичны да шул чор кешесе, коммунистик идеяләр белән рухланып, илдәге законнарны какшамас канун итеп кабул иткән кеше була. Ике яшь кешенең шул чор вәкилләре булуы малайлары тугач, исем сайлауларында да чагылыш таба. Аңа Маркс, Энгельс, Ленин, Сталин сүзләренең баш хәрефләреннән торган Мэлс исеме кушалар. Ил башына Хрущев

килгәч, малай исеме Мелх дип үзгәртелә. Инде институтта укырга кергәндә, татарчага ныграк якынаю максаты белән, егет Мәлих исемен йөртә башлый. Кызганыч, исем үзгәртү генә егет язмышын уңай якка хәл итми. Институтта укыган елларда ул үзен үткен, актив итеп таныта, группаның комсоргы вазифасын башкара. Әмма тиешле гаилә тәрбиясе, ана назы һәм ата терәген күреп үсмәгән егет дөрес кыйбла сайлый алмый: исерткеч эчемлекләр, карта уеннары белән мавыга... Нәтиҗәдә – музыкант, белемгә сәләтле студент, дусты Гайсаны үтерүдә катнаша, уеннан, кызык табудан башланган гамәл фаҗига төсмерен ала. Ике активист, закон кушканча гына яшәүче ата-анадан туган баланың шундый төпкелеккә төшүендә әдип иң элек Марваны, аның эшкә күмелүен гаепли. Әсәрнең буеннан буена шул «күмелү»нең эчтәлеге ачыла бара. Беренчедән, сугышка кадәр үк үзенә өстәмә йөкләмләрне мулдан алган Марва, Бөек Ватан сугышы елларында бөтенләе белән мәктәп эшенә чума. Өстәмә йөкләмәләр аркасында, әнисен күмү йоласында да катнаша алмый. Улын үзе белән Казанга алып киткәндә, аны пароходта ятим балалар белән эшләргә, ипи бүләргә үтенәләр. Кеше үтенечен кире кайтарырга күнекмәгән, гражданлык бурычы төшенчәсе аңына нык итеп сеңдерелгән Марва авыр капчыкларны күтәрергә дә, ипине бүлеп бирергә дә ризалаша. Соңгы ипи кисәгенә кадәр ятимнәргә бүлеп бирү нәтиҗәсендә, Марваның үз малае ач кала. Үзеңне башкалар өчен корбан итәргә әзерлек, фидакарьлек үрнәге булмый ананың бу гамәле, улыннан ераклашуга чираттагы адым була. «Башта шулай тиеш дип санады. Шулай гадел була дип уйлады. Ләкин... ул бер нәрсәне уйлап җиткермәгән булып чыкты. Ана кеше... менә хәзер күр инде, күр, әле кайчан гына икмәк өелеп торган такта әрҗә почмагына сөялеп, боегып, малае басып тора...», – дип тасвирлый Ә. Баянов әлеге күренешне [Баянов, 1997: 162]. Юдинода ярлылар өчен калдырылган пионер лагерыннан Казанга кайтып килгәндә, балаларны вагоннарга урнаштыру белән мавыгып киткән Марва үзе вагон астында кала яза, аягына зарар китереп, озак кына көч-хәл белән йөри. Марваның ихлас күңел белән, үзен аямыйча кылган гамәлләренең, Ватан алдындагы бурычын шул дәрәҗәдә төгәл башкаруының киләчәк өчен уңай нәтиҗәсе бармы? Әсәрне укыганда, укучы бу сорауга тискәре җавап бирергә мәҗбүр була. Реализм методы белән язылган «Урланган ай» повестендә җәмәгать эшләрендә аягын җәрәхәтләгән героиня атна буе ялгызы көн күрергә, аннары көч-хәл белән мәктәпкә барырга, «һәркемнең башында җан саклау кайгысы, ил язмышы. Аерым кешеләргә игътибар итәргә вакыт та, көч тә җитми» [Баянов, 1997: 172] дип үзен үзе юатырга мәҗбүр була. Марваның исә вакыты һәм көче бердәнбер баласын карап үстерергә дә җитми. Җитди кебек сылтаулар табып, бала Марваның сеңелесе Аннага җибәрелә. Нәтиҗәдә гаилә әгъзаларының берсе дә бәхетле була алмый: яшь буынны тәрбияләргә һәм белемле итәргә алынган намуслы укытучы Марва, җаны-тәне белән зарарлы сәясәткә кушылып китеп, аңсыз рәвештә үз ирегe белән үзен һәм гаиләсен җимерә, бердәнбер улын һәм аның әтисен һәлакәткә илтеп тери. Безнең фикеребезчә, Марва образында укытучы архетибының бер сыйфаты – михнәт

чигү мотивы үзенчәлекле чагылыш таба. Белгечләр искәртүенчә, укытучы архетибын тасвир иткәндә, «михнәт чигү мотивы аерым игътибарга лаек. Мифларның күбесендә, укытучы, остаз вазифасын башкаручы персонажлар төрле авырдан авыр сынауларга дучар ителәләр. Грек мифологиясендә Хирон исемле кентавр, акыл иясе һәм Ахилл, Асклепийларның тәрбиячесе, гаҗәеп дәвалаучы булуга карамастан, үз җәрәхәтен дәвалый алмый» [Дружинина]. Шулай ук «Урланган ай» повесте героинясы да, ятим балалар, мәктәп укучылары өчен кулдан килгәнне эшләп, Бөек Ватан сугышы еллары укытучысына йөкләнгән барлык эшләрне артыгы белән үтәп килсә дә, газиз баласына белем һәм тәрбияне тиешле дәрәҗәдә бирә алмый. Марваның бөтен фидакарьлеге җәмгыять тарафыннан да, үз гаиләсе әгъзалары тарафыннан да бәяләнмичә кала. М.Ш. Җәләлиева Ә. Баянов әсәрләренең үзенчәлеген шәхес язмышын үзәккә куюда дигән фикерне яклап, болай яза: «Икенче бер язучылар өчен иң элек кеше үзе бар, чынбарлыкның калган барлык күренешләре шәхескә бәйләнешле, аның язмышы итеп кабул ителә. Мондый язучыда кеше тәкъдире әйтерсең синтезлашкан, ул алгы планда, калкулыкта тора. Прозаик Әхсән Баянов шундый язучылар рәтенә керә» [Җәләлиева, 2001: 96].

Сүзебезне йомгаклап, шуны әйтергә кирәк: безнең фикеребезчә, аталган әсәр бүгенге көн педагоглары укуы өчен дә тәкъдим ителергә тиеш. Ул җәмгыять һәм укытучы мөнәсәбәтләрендәге каршылыкларны ачып кына калмый, мөгаллимнең шәхес буларак үзен саклап калырга тиешлеген дә, артык корбанчылыкка бирелүнең аянычлы якларын да ачып сала. Әлбәттә, Марва фаҗигасе – беренче чиратта шул чор фаҗигасе, ялганчы, куштаннарның өскә үрмәләве, фидакарьләрнең, бар көчләрен эшкә баглаучыларның кадерсезлек төпкелегендә калу чоры ул. Әмма бу чор, Марвалар язмышы бүгенге көндә дә безгә зур сабак бирә, уйлануларга этәрә. Хәзерге вакытта укытучыга хас булырга тиешле һөнәри һәм шәхси сыйфатларны ачып салучы фәнни хезмәтләр шактый күп. Аларда фидакарьлек, түземлек, үзконтроль кебек сыйфатлар әйдәп баручылар рәтендә атала. Марва үрнәгендә без нәкъ шундый укытучы фаҗигасен күрдек. Димәк, иң элек укытучы башкаларны да хөрмәт итәргә, үзенә карата да ихтирам таләп итәргә, тырышлыгын салып таптарга юл куймаска тиешле көчле шәхес буларак формалашырга тиеш.

**Әдәбият**

Әмир М. Саф күңел: роман-дилогия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 430 б.

Баянов Ә. Урланган ай: повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 350 б.

Бизяева А.А. Психология думающего учителя: педагогическая рефлексия. – Псков, 2004. – 216 с.

Дружинина Е.С. Архетип учителя в современном образовании. – URL: http://dspace.nbuv.gov.ua/bitstream/handle/123456789/46024/41-Druzhynina.pdf?sequence=1; дата обращения: 10.11. 2019.

Җәләлиева М.Ш. Әхсән Баянов повестьларында әдәби герой // Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре. – Казан: Мәгариф, 2001. – Б.96 – 110.

Исмәгыйлева С.Г. Иң изге һөнәр ияләре: татар әдәбиятында укытучы образлары. – Казан: ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы нәшрият үзәге, 2010. – 96 б.

Левитан К.М. Профессиональное развитие личности педагога в послевузовский период: дис. … д-ра пед. наук. – Екатеринбург, 1993. – 383 б.

Хорева Е.В. Пример учителя в формировании духовно-нравственных качеств личности // Формирование и развитие духовно-нравственных основ личности: выступления участников Всероссийской педагогической конференции (октябрь-ноябрь, 2011). – Казань, 2011. – С.35.

*Кириллова Зоя Николаевна*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Kirillova Zoya Nikolaevna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

## Р. ГАЗИЗ ҺӘМ М. КОРБАНГАЛИЕВНЫҢ ЗУРЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕ
## TATAR TEXTBOOKS FOR ADULTS OF R. GAZIZOV AND M. KURBANGALIEV

Аннотация. *Данная работа посвящена исследованию учебников татарского языка для взрослых, написанных Р. Газизовым и М. Курбангалиевым в 20-е годы XX века.*

Annotation. *This article is devoted to the study of the Tatar language textbooks for adults that have been written by R. Gazizov and M. Kurbangaliev in 20 years of XX century.*

Ключевые слова*: татарский язык, учебники для взрослых, Р. Газизов, М. Курбангалиев, 1920-е годы.*

Keywords: *the Tatar language, textbooks for adults, R. Gazizov, M. Kurbangaliev, 1920th years.*

1921 елда татар теле рус теле белән бер дәрәҗәдә дәүләт теле итеп игълан ителгәннән соң [Кириллова, 2000: 4], рус телле балаларны гына түгел, зурларны да татар теленә өйрәтү ихтыяҗы барлыкка килә. Башлангыч яки урта мәктәпләр өчен чыгарылган дәреслекләр дә беренче елларда бу максатка хезмәт итә. 1920-1930 нчы елларда руслар өчен татар теле дәреслекләренең зур күпчелеге күренекле галим, педагог һәм методист, татар телен ана теле һәм икенче тел буларак укыту, телләрне чагыштырып өйрәнү өлкәләренә гаять зур өлеш керткән Мөхетдин Корбангалиев тарафыннан төзелә. Ул үзе генә яки Риза Газиз, Х. Бәдигый һәм З. Бәдигуллиннар белән берлектә башлангыч һәм урта мәктәп укучылары, шулай ук зурлар өчен татар теленнән күп санлы дәреслекләр әзерләп чыгара.

1925 елда М. Корбангалиев һәм Р. Газизов тарафыннан «Русларга татар теле өйрәтү өчен кулланма һәм дәреслек» [Корбангалиев, 1925] төзеп бастырыла, 1928 елда аның икенче басмасы дөнья күрә. Дәреслекнең максаты итеп татар булмаган

һәм үз телләрендә яхшы укый-яза белгән зурларны татар теленә өйрәтү куела. Ул чорда төп методлар итеп саналган табигый (натураль) һәм тәрҗемәле-грамматика методларына кыскача күзәтү ясалганнан соң, зурларны бу дәреслек белән укытканда, әлеге ике методны берләштереп куллану кирәклеге ассызыклана. Авторлар фикеренчә, абстракт төшенчәләрне абстракт мисаллар белән аңлатуга караганда, әлеге сүзне укучының туган теленә тәрҗемә итү һәм ике телдәге грамматик формаларын чагыштыру күбрәк нәтиҗә бирә [Корбангалиев, 1925:II-III]. Шулай итеп, зурларны укытканда, телнең аерым сүзләрен үзләштерүләренә караганда, тел әйләнмәләре һәм сөйләм формаларына игътибар итүнең мөһимлеге ассызыклана. Моннан чыгып, дәреслекнеңберенче тугыз дәресе җанлы сөйләшү алып бару өчен билгеләнә, ягъни баштагы дәресләрдә үк уку һәм язуга өйрәтү максат итеп куелмый. Бу эш укучыларны татар сүзләрен (сүзләрдәге авазлар кушылмасын) дөрес әйтергә күнектерү һәм татар сөйләмендәге авазларны дөрес тотып алуларына ирешү максатына хезмәт итә. Дәреслекнең «Сүз башы»нда әйтелгәнчә, шуннан соң укучылар татар хәрефләрен җиңел үзләштерәләр, укытучыга, хәреф өйрәткәндә, күп көч куярга туры килми. Сөйләшү дәресләре шул рәвешчә бөтен курс дәвамында үткәрелергә тиеш була, шулай итеп, өйрәтүнең мондый системасында вакытка зур экономия ясала [Корбангалиев, 1925: III].

Дәреслекнең төзелү системасы түбәндәгечә.

Беренче дәрестә татарча һәм русча иң кирәкле әйберләрнең исемнәре бирелгән. Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| *бу – это* | *такта – доска* |
| *кем – кто* | *дәфтәр – тетрадь* |
| *нәрсә – что* | *бур – мел* |
| *китап – книга* | *букча – сумка* һ.б. |

Алга таба, шул ук сүзләрдән чыгып, татарча сораулар һәм аларга җаваплар китерелә: Бу нәрсә? – Бу – китап. Бу – карандаш. Бу – такта һ.б.

Икенче дәрестә, беренче дәрестә бирелгән сүзләрдән чыгып, кайда дигән сорауга җавап булган җөмләләр язылган: *Китап кайда? – Китап букчада. Бур тактада. Дәфтәр букчада* [Корбангалиев, 1925: 7].

Моннан соңгы 7 дәрестә (7-13 б.) кеше әгъзаларының исемнәре белән таныштыруга юнәлтелгән төрле исемнәр бирелгән. Шушы исемнәрдән чыгып, сораулар һәм аларга җаваплар язылган. Укучыларның сөйләм телләрен үстерү максатыннан чыгып, сорауларга җаваплар бирү һәм язылып бетмәгән җөмләләрне тәмамлау кебек күнегүләр тәкъдим ителә, ә дәрес азагында, кагыйдә рәвешендә, бөтен дәрестәге материалга нәтиҗә чыгарыла һәм әлеге нәтиҗәләр рус телендә биреләләр. Барлык кагыйдә-аңлатмалар да рус грамматикасы белән чагыштыру нигезендә төзелгән.

Алдагы 17 дәрес «Уку-язуга өйрәтү дәресләре» (13-39 б.) дип атала, алфавитны үтү һәм татар теленең төп грамматик формалары белән танышу максатын күздә тота. Һәр дәрес башында укучылар өчен таныш булмаган сүзләрнең тәрҗемәләре

биреп барыла, дәрес ахырында рус телендә нәтиҗәләр тәкъдим ителә. Татар телендәге килеш кушымчаларын һәм фигыльнең өч заман формасын үтеп бетергәч исә, 12 дәрестән башлап, әзер кагыйдәләр бирелми, ә авторларның «Опыт краткой практической грамматики татарского языка» китабындагы параграфларга мөрәҗәгать итәргә кушыла. III бүлектә (39-50 б.) йорт кирәк-яракларына багышланган, ә IV бүлектә (51-117 б.) ел фасыллары белән бәйле рәвештә авыл хуҗалыгы турында һәм Татарстан сәнәгатенең кайбер тармаклары хакында текстлар (авторлар аларны мәкалә дип атый – З.К.) бирелгән.

Аерым дәресләрдә яңа сүзләрнең тәрҗемә итеп бирелүеннән тыш, дәреслек ахырында алфавит нигезендә төзелгән 18 битлек сүзлек тә урын алган.

Үткәннәрне кабатлау һәм яхшырак истә калдыру максатыннан чыгып, төрле эчтәлекле күнегүләр дә урнаштырылган: татар хәрефләре белән сүзләрне уку һәм язу, аерым сүзләрдән җөмләләр төзү, текстларны тәрҗемә итү һәм үз исемеңнән сөйләргә яки язарга өйрәнү һ.б. Телдән һәм язма биремнәр арасында затны үзгәртеп сөйләргә яки язарга кушылган бирем өстенлек ала.

Дәреслекне төзегәндә, оста методист һәм педагог буларак, М. Корбангалиев һәм Р. Газизов укучыларның телне белмәвен һәм алар читенсенә торган барлык якларны да искә алып эш итәләр. «Чит тел»не өйрәтә башлаганда, әле башта ук укырга һәм язарга өйрәтергә, яки алфавит белән таныштырырга керешелми, бәлки элек теге яки бу сүзләрне әйтә белергә, авазларның татарча дәрес әйтелешенә ирешүгә игътибар ителә. Шуннан соң гына алфавит белән таныштыру, гомумән, укырга-язарга өйрәтүгә урын бирелгән, шуның белән бергә, сөйләм телен үстерү һәм грамматика буенча белем бирү бергә бәйләнеп алып барылырга тиешлек күздә тотылган һәм дәреслек тә шуңа яраклаштырып төзелгән [Вәлеева, 2004: 104-105].

М. Корбангалиев техникум, рабфак, вуз һәм втузлар өчен 1934 елда «Татарлардан башкалар өчен татар теле дәреслеге»н [Корбангалиев, 1934] төзеп бастыра. Бу дәреслектә морфология һәм синтаксис буенча тулы мәгълүмат бирелә һәм татар әдәбиятыннан да үрнәкләр китерелә. Грамматиканың бүлекләре аерым-аерым бирелгән булса да, материалның һәм күнегүләрнең урыны һәм эчтәлегенә караганда, уку, язу, сөйләм телен үстерү һәм грамматика буенча белем бирүнең бергә бәйләнеп барырга тиешлеге, шулай ук дөрес әйтелешкә дә һәрвакыт игътибар бирү кирәклеге аңлашыла.

Татар теленең күп кенә грамматик формалары, бигрәк тә морфология бүлеге, рус теле белән чагыштырылып бирелә, ягъни мәктәпләрдәге кебек үк, урта һөнәри һәм югары уку йортларында да рус теле белән татар телен чагыштырма рәвештә өйрәнү алга куела. Морфологияне өйрәтүгә багышланган бүлек (6-121 б.) синтаксис өлешенә (122-151 б.) караганда күпкә зуррак, аның беренче битләрендәшулай ук татар алфавиты, татар теленең авазларын төркемләү, сузык һәм тартык авазларның калын яки нечкә әйтелешенә багышланган, ягъни фонетикага караган материал да урын алган.

Большую группу в географических реалиях указанных районов составляют антротопонимы. В них имена собственные имеют различное происхождение. Одни из них указывают на первопоселенца населенного пункта, другие – на владельца земли, третьи являются посвящениями. Например, названия сёл Николаевка, Андреевка, Быково, Волково Благовещенского района; Акбердино, Фаткуллино, Амирово, Блохино Иглинского района. Так, название села Николаевка Благовещенского района связано сименем владельца Благовещенского завода Николая Хлебникова, а название села Саннинска с именем барина Санина. Если названия башкирских сел в основном образованы от имени первопоселенца (Акбирде, Фаткулла, Амир), то наименования русских селений в большинстве случаев произошли от фамилии поселенцев (Быков, Волков, Блохин и т.д.). В Иглинском районе название некоторых населенных пунктовобразованы от этнонимов: п. Кудеевка,д. Новокубово, д. Старокубово,

с. Минзитарово. Указанные этнотопонимы связаны с древними племенами башкир, которые проживали в прошлом на данной территории. Особое место в топонимии башкирского края занимают наименования географических объектов, связанных с гидронимами. Например, д. Нижние Лемезы, Тауш, Кушкуль, Мончазы, Симское Иглинского района; д. Нижний Изяк, Уса Благовещенского района. Ярко представлена на карте региона и фитотопонимия. Об этом свидетельствуют названия населенных пунктов Березовая Поляна, Берёзовка, Карагайкуль, Яблочный Благовещенского района; Урман, Ягодная, Карамалы Иглинского района.

В географических названиях отражены все стороны общественно-политической жизни народа. Особую группу образуют топонимы, которые возникли после Октябрьской социалистической революции. Часто встречаются они в топонимии Иглинского района:Ленинское, Октябрьское, Социалистический, Заветы Ильича, Пятилетка, Майский и др. В названиях населенных пунктов нередко фигурируют и имена политических деятелей: д. Кировка, п. Калининский, п. Буденновский, п. Ворошиловский, п. Чкаловский и др.

Этнокультурной особенностью топонимии Благовещенского района можно считать художественную рецепцию православной религии в названиях географических объектов. Во многих топонимах района отразились церковные праздники: д. Рождественское, д. Воскресенка, д. Покровка, д. Преображенское, д. Успенка и т.д. О происхождении названия города Благовещенск существует несколько версий. Некоторые считают, что город так назван по имени действующей при медеплавильном заводе Церкви Благовещения Пресвятой Богородицы. По мнению краеведа В. Е. Мещерякова, название города связано с праздником Благовещения, случившимся в период закладки завода. Религиозные воззрения народа отразились и в названиях населенных пунктов Иглинского района: д. Новотроицк, д. Вознесенская, д. Преображенка, д. Михайловка, д. Покровка, д. Спасское.

В топонимии края ярко отразились межэтнические связи и взаимодействия. К примеру можно привести название возвышенности «Мына (мана) гора» Иглинского района, где запечатлены башкирско-русские контакты. По рассказам жителей края, в далекие времена, когда русские переселенцы появились в здешних краях, попросили у башкирского старшины место для поселения, тот, указав на возвышенность, сказал: «Мына гора, там и живите!». Старшина знал по-русски слово «гора», а указательное местоимение «бына/мына» («вот») не смог перевести на русский язык. С тех пор гора носит такое необычное название. В деревне Нижние Лемезы вышеназванного района нам довелось записать топонимы, образованныес использованием русских антропонимов. Так, название озера Пеньковосвязывают с фамилией мужчины, утонувшего когда-то в нем, а в деревне Блохино, Шипово жили семьи с такими фамилиями. В названии села Чуваш-Кубово Иглинского района также яркоотражены межкультурные связи. Как свидетельствуют информанты, село было основано башкирами Кубовской

волости Ногайской дороги. Впоследствии на этих землях заселились ясачные марийцы, а затем чуваши.

В топонимах Алаторка, Ауструм, Балтика Иглинского района сохранились прежние названия населенных пунктов, откуда переехали их жители. Так, Алаторка была основана на вотчинных землях башкир Кубовской волости в 1720 году сосланными стрельцами – Прокофьевым и Рябовым. Название деревни происходит от города Алатырь, откуда прибыли стрельцы.

Как показывают наши наблюдения, в названиях населенных пунктов изучаемых районов активно употребляются лексемы «иҫке» (старый) и «яңы» (новый). Исторические материалы и народные рассказы свидетельствуют о том, что компонент «яңы» (новый) используется для новых населенных пунктов, выделившихся из недр базового «старого»: Новоиликаево – Староиликаево, Новонадеждино – Старонадеждино Благовещенского района, Старая Кудеевка, Старый Юрмаш, Старые Карашиды, Новая Березовка Иглинского района.

В топонимии указанных районов используются также номинации по свойствам, признакам, качествам самого объекта: д. Большой Лог, д. Каменная Поляна, д. Каменный Лог Благовещенского района, д. Высокая, с. Улу-Теляк, д. Улу-Карамалы, д. Черный Ключ, д. Ясная Поляна Иглинского района.

Таким образом, топонимическая номинация ярко свидетельствует об особенностях народного восприятия и концептуализации окружающего мира.

**Литература**

1. Березович Е. Л. Топонимия и исторические предания: к вопросу о взаимодействии различных версий этнокультурной информации// Ономастика и диалектная лексика: сб. научных трудов. – Екатеринбург, 1999. – Вып. 3. –С. 3-30.

2. Кульсарина И. Г., Фаткуллина Ф. Г. Мифология и фольклор в топонимической системе Республики Башкортостан // Этапы и особенности развития просветительства в Башкортостане и России: филологические, философские, историко-культурные, педагогические и правовые аспекты: материалы Международной научно-практической конференции. –Уфа: РИЦ БашГУ, 2016. –С. 256-261.

3. Тихонова Е. Л. Топонимическая номинация как ориентир в коммуникативном пространстве (на примере фольклорной прозы) // Вестник Бурятского государственного университета. –2016. –Вып. 2. – С. 223-230.

*Мирхаев Рифат Фирдинатович*
*Миннуллин Бәхтияр Кимович*
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Казан, Россия
*Mirkhayev Rifat Firdinatovich*
*Minnullin Bakhtiyar Kimovich*
Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russia

# ТЕЛ ГАЛИМЕ, ДИАЛЕКТОЛОГ Ф.Й. ЙОСЫПОВНЫҢ ФӘННИ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ КАРАТА
# ABOUT SCIENTIFIC ACTIVITY OF THE SCIENTIST-LINGUIST, DIALECTOLOGIST F.YU. YUSUPOV

Аннотация. *В статье освещаются основные вехи и направления научной деятельности известного татарского языковеда (лингвиста, диалектолога) и общественного деятеля Ф.Ю. Юсупова, труды которого внесли большой вклад в развитие современного татарского языкознания. Она посвящается 80-летию со дня рождения учёного.*

Annotation. *The article highlights the main milestones and directions of research activitiesof the famous Tatar linguist (linguist, dialectologist) and public figure F.Yu. Yusupov,whose works have greatly contributed to the development of modern Tatar linguistics.It is dedicated to the 80th birthday of the scholar.*

Ключевые слова: *татарское языкознание, диалектология, лингвистичекая география, ареальная лингвистика, татарский диалектный язык.*

Keywords: *Tatar linguistics, dialectology, linguistic geography, areal linguistics,Tatar dialect language.*

Татарлар дөньяга күп кенә атаклы кешеләр биргән милләтләрнең берсе санала. Алар арасында филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Йосыф улы Йосыповның исеме дә лаеклы урын алып тора. Аның кебек шәхесләр турында сөйләгәндә, «Алар туган халкы, милләте өчен яши һәм эшли», дип әйтәләр.

Татар тел белеменең күптөрле тармакларында, этнография, халык мәгарифе, педагогика һәм методика фәннәре өлкәләрендә бүген дә киң кырлы фәнни эшчәнлек алып баручы галим, дүрт йөздән артык фәнни хезмәт, балалар бакчалары, урта мәктәпләр өчен күпсанлы программалар, дәреслекләр, уку әсбаплары авторы Фәрит Йосыповның исеме тел белеме өлкәсендә эшләүче галимнәргә генә түгел, бәлки укытучыларга, укучыларга, һәм ата-аналарга да яхшы таныш. Шулай да, ул иң беренче чиратта тел белгече, әлеге өлкәнең гыйлемле профессоры, талантлы диалектолог, бу фәнне төрки телләр арасында беренчеләрдән булып яңа баскычка күтәрүче, шушы өлкәдә бөтенләй яңа бер юнәлеш ачып җибәргән галим санала.

Фәрит Йосыпов 1939 елның 15 маенда хәзерге Татарстан Республикасының Яшел Үзән, Биектау районнары чигендә урнашкан Олы Караужа авылында туып үсә. Авыл халкы тарафыннан иң мәртәбәле һәм абруйлы кешеләрнең берсе буларак искә алынучы әтиләре Йосыф ага сугышта батырларча һәлак була. Берсеннән-берсе кечкенә сабыйлары белән тол калган әниләре Асия апа аларны тәрбияләп олы тормыш юлына бастыра.

Булачак галимнең язмышына Камали бабасы зур йогынты ясый. Чөнки әйләнә-тирә авылларда иң өлкән яшьтә булган бу ил агасы буыннардан-буыннарга тапшырылып килгән тарихи вакыйгаларны яхшы хәтерли, еш искә ала һәм алар турында бәләкәй Фәриткә дә сөйли торган була. Өлкән буын тарихчы һәм этнографлар да Камали агай янында еш булганнар һәм аннан күпсанлы риваятьләр язып алганнар.

Туган төбәгенең үзенчәлекле тарихыбелән кызыксыну Фәрит Йосыповны Казан дәүләт университетына алып килә. Биредә ул татар теле галимнәренең күбесе өчен чын мәгънәсендә остаз булган Латыйф ага Җәләйнең татар диалектологиясе, татар теленең тарихи грамматикасы буенча лекцияләрен йотлыгып тыңлый. Шул елларда ук яшь студент һәм атаклы галим арасында бик җылы мөнәсәбәтләр урнаша.

Икенче курста укыганда Фәрит Йосыпов танылган галим Диләрә Гариф кызы Тумашева җитәкчелегендә Себер татарларының телен өйрәнүгә багышланган фәнни экспедициядә катнаша. Утыз ел үткәннән соң, танылган галим буларак, ул бу юлларны кабат уза.

Диплом эшен яшь егеткә үзе хыялланганча, диалектология буенча язарга насыйп булмый. Фәнни җитәкчесе Әнвәр Әфләтүнов аның алдына Сталин репрессиясенең аяусыз корбаны булган күренекле тел белгече һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Шәрәфнең фәнни мирасын барлау, аның архивын эзләп табып өйрәнү бурычын куя. Мәшһүр шәхеснең намуслы исеме шул рәвешле Казан дәүләт университетының гади генә бер студенты тарафыннан татар халкына кире кайтарыла.

Университетны тәмамлагач, булачак галим берничә ел Кама Тамагында чыга торган «Кызыл байрак» газетасының җаваплы сәркатибе вазифасын башкара, бер үк вакытта Татарстан радиосы һәм телевидениесе белән хезмәттәшлек итә. 1962 нче елда аны СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият, тарих институтының фәнни хезмәткәре итеп кабул итәләр. Шул рәвешле язмыш аны кабаттан остазы Латыйф Җәләйэшләгән җиргә кайтара. Биредә ул Мирфатыйх Зәкиев, Диләрә Тумашева, Ләйлә Мәхмүтова кебек атаклы галимнәр белән бергә 1969 нчы елда Мәскәүдә рус телендә дөнья күргән академик «Хәзерге татар әдәби теле» хезмәтен язуда катнаша.

1964 елның көзендә Фәрит Йосыповка Көньяк Урал һәм Урал арты территориясендә таралган татар сөйләшләрен фәнни яктан өйрәнү эше тапшырыла. Шушы мизгелдән башлап диалектологның бөтен тормышы халык арасында, җанлы сөйләш үрнәкләрен туплауга багышланган фәнни

экспедициялəрдə үтə. Соңыннан тупланган тел материаллары җентеклəп эшкəртелə һəмнəтиҗə буларак, татар диалект теленең тулы бер системасы төзелə. Əлеге фəнни проблема татар һəм төрки теллəр диалектологиясе өлкəсендə беренчелəрдəн булып татар галиме Фəрит Йосыпов тарафыннан куела һəм уңышлы рəвештə хəл ителə. Бу эшне галим Көньяк Урал һəм Урал артының урманлы-далалы киңлеклəрендə чəчелеп урнашкан бихисап татар авылларының тел үзенчəлеклəрен өйрəнүдəн башлый һəм татар халкының фəндə моңа кадəрбилгеле булмаган эчкен, сафакүл, нагайбəк татарлары дип аталучы этник төркемнəрен ача.

Дүрт ел дəвам иткəн киеренке фəнни-тикшеренү эшлəре кандидатлык диссертациясен яклау белəн тəмамлана. Шул чорда башка яшь диалектологлар белəн бергə Фəрит Йосыпов фəнгə зур яңалык алып килə – ул диалект һəм сөйлəшлəрне географик лингвистика (тел географиясе) алымы белəн өйрəнүне башлап җибəрə. Бу ысул тел күренешлəрен шартлы билгелəр белəн картага төшереп, аның таралыш чиклəрен төгəл билгелəргə ярдəм итə. Алга таба галим бай архив материалларына нигезлəнеп, татар теленең мөстəкыйль диалектлары һəм сөйлəшлəре формалашуның тарихи этапларын ачыклый һəм һəр сөйлəшне аерым мөстəкыйль тел статусы югарылыгы дəрəҗəсендə тасвирлый.

Фəрит Йосыповның төрки теллəр диалектологиясенə керткəн яңалыгына килгəндə, ул барлык диалект һəм сөйлəшлəр өчен хас булган күптөрле вариантлыкны, нинди генə кыйммəткə ия булуына карамастан, бер тəртип бөтенлеген (системаны) тəшкил итə торган вак системалар төзелеше итеп карарга тəкъдим итə. Галим кулланган бу методика иксез-чиксез киңлеклəргə таралган татар теленең территориаль үзенчəлеклəрен гомум милли тел кысаларында кысаларында карарга, аны барыбыз өчен дə уртак булган туган телнең бер варианты итеп санарга мөмкинлек бирə.

Студент вакытында остазы Дилəрə Тумашева җитəкчелегендə себер татарларының телен өйрəнү максаты белəн катнашкан фəнни экспеция галим күңелендə гомер буе гүзəл бер хəтирə булып сакланып кала. Əлеге уңайдан аның тарафыннан себер татарларының рухи хəзинəсен саклап калу максаты белəн төзелə башланган «Себер татарлары халык əдəбияте антологиясен» телгə алып китми мөмкин түгел. Бүгенге көндə аның дүрт томы дөнья күрде. Беренче томда тобол-иртыш татарлары халык əдəбияты жанрларыннан дастаннар, мөнəҗəтлəр, бəетлəр урын ала. Икенче том элекке заманнарда халык арасында аеруча популяр булган йомак-масал жанрына багышлана. Өченче томда хикəят (халык хикəялəре) жанрына киң урын бирелə. Галим фикеренчə, килеп чыгышы ягыннан борынгы һинд, фарсы əдəбиятларына барып тоташкан əлеге жанр себер татарларына Ислам дине белəн бергə килеп керə. Бу томда шулай ук күп төрле риваятьлəр, борынгы мəҗүсилек чорында халыкның дөньяны танып белү барышында туган мифларга да зур урын бирелə. Себер татарлары халык авыз иҗаты антологиясенең дүртенче томы музыкаль мирас əсəрлəренə багышлана. Биредə

себер татарларының музыкаль жанрларга караган 400 гә якын әсәре нота язмалары белән тәкъдим ителә.

Фәрит Йосыпов – милли мәгариф үсешенә дә зур өлеш керткән шәхесләрнең берсе. Кандидатлык диссертациясен уңышлы яклаганнан соң, Алабуга педагогия институты ректоры Тәлгат Галиуллин яшь белгечне чит телләр факультетының деканы вазифасына чакыра. Биредә аның алдына фәнни дәрәҗәле бер генә хезмәткәре дә булмаган факультетны тиз арада шул ук институтны тәмамлап чыккан фәнни кадрлар белән тәэмин итү бурычы куела. 1970-80 елларда Алабуга педагогия институтының чит телләр факультеты Россиядәге бу төр институтлар арасында иң абруйлы факультетларның берсенә әверелә.

Галимнең тормышында Милли мәктәпләр институтында эшләү чоры аерым урын алып тора. 1984 нче елда аны Алабугадан РСФСР Милли мәктәпләр институтының Татарстан филиалы директоры итеп күчерәләр. Шул вакыттан башлап XX гасырның 90 нчы еллары уртасына кадәр республиканың барлык методик мөмкинлекләрен үз тирәсенә туплаган әлеге оешма җитәкчелегендә татар теле һәм әдәбияты буенча яңа эчтәлектәге программалар төзелә, күпсанлы дәреслекләр, хрестоматияләр, уку-укыту әсбаплары языла.

Узган гасырның 80 нче еллары уртасында Кырым татарларының проблемалары белән шөгыльләнәчәк Дәүләт комиссиясе төзелә. Аның күпсанлы комитетлары арасында халык мәгарифе мәсьәләләре белән шөгыльләнүче төркемнең җитәкчесе итеп татар галиме Фәрит Йосыпов билгеләнә. Ул иң беренче эш итеп Кырым татарлары яши торган төбәкләрне ачыклый. Алар – Казахстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан республикалары. Баштарак Кырым татарлары Мәскәү тарафыннан билгеләнгән Казан татары белән аралашудан катгый рәвештә баш тарталар. Әмма берникадәр вакыт үткәч, галим алар арасында зур ихтирам казана. Нәтиҗәдә кырым-татар балалары мәктәпләрдә туган телләрен өйрәнә башлыйлар. Ташкент педагогия институтында кайчандыр бу халык өчен эшләп килгән тел-әдәбият бүлеге яңадан аякка бастырыла һәм ул үзенә кырым-татар яшьләрен кабул итә башлый.

Мәгариф өлкәсендәге хезмәтләре өчен профессор Фәрит Йосыпов «Намуслы хезмәте өчен» һәм Д.М. Ушинский исемендәге медальләр белән бүләкләнә. Ул – Россиянең мәгариф отличнигы, Бөтенроссия укытучылар съезды делегаты, Россия тюркологлар комитеты, Шәрыкъны өйрәнү ассоциациясе, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау советлары әгъзасы булып тора. Төрки телләр, педагогика, методика фәннәре өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге өчен ул Англиядәге автобиографик үзәкнең карары нигезендә XX гасырның иң атаклы кешеләренең берсе итеп танылды.

*Мөгътәсимова Гөлназ Ринатовна*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Mugtasimova Gulnaz Rinatovna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

# ФИТОНИМ КОМПОНЕНТЛЫ ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ХАЛЫК МӘКАЛЬЛӘРЕН ЧАГЫШТЫРЫП ӨЙРӘНҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
# FEATURES OF A COMPARATIVE STUDY OF TATAR AND TURKISH PROVERBS WITH PHYTONYM COMPONENTS

Аннотация. *Рассматриваются особенности употребления фитонимической лексики в татарских и турецких пословицах. Показано, что фитономическое поле анализируемых фольклорных текстов составляют названия деревьев и трав. Также показана их роль в формировании различных установок культуры, выявлены сходства и различия, выражаемые пословицами с компонентом - фитонимом в двух родственных языках. Диапазон применения результатов исследования достаточно широк: от дальнейших научных изысканий лексико-семантических особенностей фитонимов в языке пословиц до отражения этноязыковой картины мира этноса на примере фольклора.*

Abstract. *This article is devoted to the features of the use phytonym vocabulary in Tatar and Turkish Proverbs. It is shown that phytonym field of analyze folklore texts are the names of trees and herbs. Their role in the formation of different cultural attitudes is also shown, similarities and differences expressed by proverbs with the component – phytonym in two related languages are revealed. The range of application of the research results is quite wide: from further research of lexical-semantic features of phytonyms in thelanguage of proverbs to reflect the ethno-linguistic picture of the world of ethnos on the example of folklore.*

Ключевые слова: *татарский язык, турецкий язык, пословица, фитонимы.*
Keywords: *the Tatar language, the Turkish language, proverb, phytonyms.*

Һәр телдә дөньяны кабул итү һәм тәртипкә салу ысулы чагылыш таба. Төрле тел вәкилләре дөньяны үз күзлеге аша күрә һәм кабатланмас тел сурәте барлыкка китерә. Милли дөнья сурәтендәге аермалар иң элек мәдәниятләр арасындагы аермалыкларга бәйле. Шунлыктан һәр халыкның дөнья сурәтендә мәдәни һәм көнкүреш реалияләре, карашлары, йолалары гәүдәләнә. Милли мәдәният үзенчәлекләре мәкальләрдә аеруча аермачык чагыла, чөнки мәкальләр ул – мәдәният һәм халык менталитеты турындагы кыйммәтле чыганак. Күренекле галим Н. Исәнбәт: «Мәкальләр халкыбызның тарихын да, язмышын да, аның табигатькә, җәмгыятькә мөнәсәбәтләрен дә, рухи төзелеше ничек ясалуын да, ышануларын һәм дөньяга карашларын да, нәрсәне ярату, килештерү яки яратмавын да, акылын-фигылен, характерын, милли зәвыгын, теләкләрен, әхлагын һәм башка сыйфатларын да чагылдыралар. Беренче карауга каршылыклы күренгән мәкальләр аша без татар халкының рухи йөзе,

психологиясе турында кызыл җеп булып сузылып барган шактый кызыклы һәм эзлекле фикерләр ясый алабыз» дип язып калдырган [2, с. 7].

Мәдәният һәм лингвомәдәният турында сөйләгәндә, бик мөһим үзенчәлекне билгеләп үтәләр: тел берәмлекләрендәге мәдәни мәгълүмат имплицит характерга ия, ул мәгънә артына яшеренгән кебек.

Лингвомәдәният белән шөгыльләнүчеләрнең күбесен телнең паремиологик фонды үзенә җәлеп итә, чөнки мәкальләрнең күбесе халык аңы стереотипларын чагылдыра.

Татар һәм төрек мәкальләрендә агач һәм куак, чәчәк һәм үлән, ашарга яраклы һәм яраксыз үсемлек атамалары урын алган. Табигать һәм географик үзенчәлекләре халыкның мәдәниятенә йогынты ясамый калмый.

Татар телендә дә, төрек телендә дә агач белән бәйле бик күп мәкальләр очрый. Мәсәлән, татар халык мәкальләре арасында түбәндәгеләр күзәтелде: ***Агач** җимеше белән, адәм эше белән; Адәм адәмгә сыенмыйча, **агачка**, ташка сыенмый; Җимешле **агачның** башы түбән; **Агач** кайсы якка кыек булса, шул якка авар; Бала кош очар, кунар **агачын** тапмас; Кыеш **агачның** ботагы туры булмас; **Агачта** да колак бар; Чәчәк күрсәтмәгән **агачта**н җимеш көтмә; **Агач**беленә җимешеннән, адәм – кыланмышыннан; Вөҗдансыз кеше үзәксез **агач** кебек, үзлегеннән аварга тора; Борыныңны бик күтәрмә, **агач** башына эләкмәсен; Каршы **агачка** каты чөй; **Агачтагы** яшерен ут кабынмыйча күренми.*

Ağaç (агач) берәмлеге кергән түбәндәге төрек мәкальләре табылды:*Acele bir **ağaçtı**r, meyvesi pişmanlık; **Ağaçtan** maşa, aptaldan paşa olmaz; Aklına geleni işleme, her **ağacı** taşlama; **Ağaç** yaş iken eğilir; **Ağaç** yaprağı ile güzeldir (gürler); **Ağaç** kökünden yıkılır; **Ağacı** kurt, insanı dert yer; **Ağaca** çıkan keçinin dala bakan oğlağı olur; Taşa çıkan keçinin, **ağaca** çıkan oğlağı olur; **Ağaca** balta vurmuşlar sapı bedenimden demiş.*

Һәр халык үз телендә чынбарлыкта булган фактлар белән бергә табигать күренешләрен дә, ягъни үзенә якын һәм аңлаешлы булганны гәүдәләндерә. Нәкъ менә шушы фикердән чыгып карасак, татар һәм төрек мәкальләрендә Татарстан һәм Төркия җирләрендә үсә торган агач һәм куак атамалары булуы табигый. Мәсәлән, татар мәкальләрендә каен, юкә, имән атамалары актив күзәтелү гайре табигый түгел: *Алдарга эләкмә, кәкре **каенга** терәтер; карга каеным, ди; Черек **каен** бакадан да курка. **Юкә** агачы белән бәйле, бары тик берәү генә: Ие шул, **юкәдә** икән чикләвек; Эшчән кеше – **имәндәй; Карагайның** көле күп, **имәннең** күмере күп; Корыган **тирәк** су янында да яшәрмәс* һәм башкалара.

Чикләвек татарларда урманнарда гына үсә, аларны кешеләр үзләре утыртмыйлар. Мәкальләр арасында әлеге үсемлек атамасы кулланылганыда бар: ***Чикләвек** ватмасаң, төшен ашый алмассың.*

Төрек мәкальләрендә исә нарат, чия, зәйтүн, тополь атамалары күзәтелде: ***Çam ağacından** ağıl olmaz, el çocuğundan oğul olmaz; **Kiraz** dut yetişmese beni yiyenin boynunu sapıma döndürürüm demiş; Bağ babadan, **zeytin** dededen kalmalı; **Kavakta** da boy var; Dut yaprağı açtı, soyun: döktü giyin.*

Төрек мәкальләрендә телендә Төркиядә яратып үстерелә торган инжир агачы атамасы да очрады: *Darı unundan baklava,* ***incir ağacından*** *oklava olmaz;* ***İncir*** *yaprağı deve tabanı kadar olmayınca yaz gelmez.*

Төркиядә чикләвек куагы һәр өй саен диярлек үстерелә, шунлыктан халык телендә түбәндәге мәкаль иҗат ителгән: ***Ceviz*** *gцlgesi yavuz gцlgesi,* ***söğüt*** *gölgesi yiğit gölgesi,* ***dut*** *gцlgesi it gцlgesi.*

Көнбатыш, Үзәк һәм Көнчыгыш Африка, көньяк һәм көньяк-көнчыгыш Азия, Һинд океанының тропик урманнарында үсә торган эбен агачы атамасы да төрек мәкальләрендә теркәлеп калган. Төрекләр аны *abanoz* дип атый:*Bir ağaç suda çok durursa, olur* abanoz*; Bir misafir çokoturursa olur babanız.* Әлеге бик кыйммәтле агач Кызыл китапка теркәлгән. Хәзерге вакытта әлеге агачны төрле зәркән эшләнмәләрендә күрергә була.

Төрле үлән атамалары күзәтелгән татар халык мәкальләре шактый күп. Мәсәлән, ***Сарана*** *төбендә суган ятыр;* ***Сары мәтрүшкә*** *җитмеш төрле авырудан им;* ***Сары мәтрүшкә*** *– алтмыш төрле авырудан,* ***көрән мәтрүшкә*** *җитмеш төрле авырудан дәва;* ***Үги ана*** *– яфрак, үз әнием яхшырак;* ***Ак алабута*** *– ачлык елның бодае;* ***Алабута*** *– ачлык елның икмәге;* ***Алабута*** *– аш, имеш;* ***Балтырган*** *– бал татыр;* ***Быламыттан*** *чәй булыр;* ***Актамыр*** *атка булган үчен сабаннан алыр;* ***Актамырга*** *ат көче (чыдый);* ***Актамыр*** *сабан аударыр;* ***Камышлы*** *җир – көмешле җир;* ***Камышны*** *үз күлеңнән ал;* ***Камыш*** *судан туймас;* ***Камыш****, суда утырса да, бар үләннән элек корый; Карда* ***камыш*** *үсми; Корыган* ***камыш*** *еректан тавыш бирер;* ***Кылган*** *башы юкка кымшанмый;Күк* ***үлән*** *үскән җиренә үсәр; Олы юлга* ***үлән*** *үсми; Судагы* ***камышның*** *асылы-нәселе бер,алай да берсеннән чыпта сугалар,берсеннән шикәр сыгалар;* ***Сырлан*** *сырып алыр,****берлән*** *бөреп алыр;* ***Татыр*** *– татырда мал ятыр;* ***Тигәнәктән*** *йон ал;* ***Тигәнәк әрекмәннән*** *ерак китми; Унҗиде сәгать суккач,* ***үләннең*** *шифасы тамырга төшәр; Чыксыз* ***үлән*** *үсми;* ***Шайтан таягына*** *кырау тими;* ***Шайтан таягы*** *чүплек башында; Шиңгән* ***үләнне*** *ашаган мал шиңгәк булыр; Питрауга чаклы* ***үләннең*** *шифасы чәчәктә, питраудан соң – тамырда;* ***Эт эчәгесенең*** *очы-башы булмас*һәм башкалар.

***Isırgan otu*** *ile taharet olmaz;* ***Otu*** *çek, kököne bak* кебек төрек халык мәкальләрендә үлән атамаларын күзәтергә була.

Татарлар төрле чәчәкләр белән бәйле түбәндәге мәкальләрне иҗат итеп калдырганнар: ***Давыл чәчкәсе*** *өзсәң, давыл чыгар; Матур* ***чәчәкне*** *кырау тиз ала;* ***Мәк*** *ашаган тиз йоклар;* ***Мәк*** *астында яткан төшенә исерер;* ***Мәкнең*** *бер сабагы – дару, бер сабагы – агу;* ***Мәк чәчәгенең*** *төсе матур булса да, исе яман; Мәлсез* ***чәчәк*** *ярылмас;* ***Төнбоек*** *күзен көндез йомар, кич ачар;* ***Умырзаяны*** *ашаса, тавык үләр;* ***Умырзаяның*** *гомере бер көн;* ***Умырзая*** *яфрагыннан алда чәчәген күрсәтер;* ***Утчәчәктән*** *ат талаулар;****Чәчәкне*** *вакытында өз;* ***Чәчәк*** *җыйган чәнечкедән курыкмый;* ***Эргәзембай*** *– бер көнлек;* ***Эргәзембай*** *бер төптә;* ***Эргәзембай*** *– яз күрке;* ***Эргәзембай*** *– яз кунагы.*

*Bezir bardağına* ***zambak*** *yakışmaz; Arı bal alacak* ***çiçeği*** *bilir; Bir* ***зisekle*** *bahar (yaz) olmaz; Her* ***зisek*** *koklanmaz;* ***Gьlь*** *seven dikenine katlanır; Oğlanınki oğul balı, kızınki bahçe* ***gьlь*** кебек төрек мәкальләрендә чәчәк сүзе һәм атамалары сакланып калган. Димәк, татар һәм төрек мәкальләрендәге чәчәк, үлән атамалары охшаш булмавы ачыкланды.

Шулай да төрле үсемлек атамасы кулланылган татар һәм төрек халык мәкальләренең охшашлары бар. Мәсәлән, *Ач тавык төшендә* ***тары*** *күрер – Aç tavuk (düşünde) kendini* ***buğday (arpa, darı)*** *ambarında sanır (görür); Йомшак* ***агачны*** *корт басар –* ***Ağacı*** *izinden kurt yer; Адәм күрке – чүпрәк,* ***агач*** *күрке –* ***яфрак*** *–* ***Ağaç yaprağı*** *ile, adam keremiyle gьzeldir;* ***Чыбык*** *вакытында бөкмәсәң, зурайгач бөгә алмассың –* ***Ağaç*** *yaş iken eğilir;* ***Җимешнең*** *асылын эт ашар –* ***Armutun (armudun)*** *iyisini ayılar yer; Ике карбыз бер култыкка сыймас – İki karpuz bir koltuğa sığmaz; Алма агачыннан ерак төшмәс – Elma, ağacından uzağa düşmez; Һәммә – бодай, без – салам, һәммә яхшы, без яман – Herkes iyi ben yaman; herkes buğday ben saman.*

Димәк, үсемлекләр дөньясы реалияләрен аңлатучы лексик берәмлекләр татар һәм төрек мәкальләренең бер өлешен тәшкил итәләр, шулай ук этномәдәни дөнья сурәтен модельләштерү чарасы булып та торалар. Үсемлекләр эстетик үрнәкләрнең гомумкешелек хәзинәсе булганга, үсемлекләр дөньясын чагылдыра торган лексика мәкальләрнең тасвири нигезен барлыкка китерә. Шулай итеп, безнең материал күрсәткәнчә, халык авыз иҗаты телендә кулланылган үсемлекләр дөньясын алга таба да тикшерү, анализлау сорала.

**Әдәбият**

1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Өч томда.– Казан: Татар. кит. нәшр., Т.1. –1959. – 913 б.; Т.2. 1963. – 959 б.; Т.3. 1967. – 1013 б.

2. Исәнбәт Н. Мәкальләребез турында // Татар халык мәкальләре. Т.1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – Б. 7-243.

3. Ömer Asım Aksoy. Atasözleri ve Deyimler. – Ankara: Tьrk Dil Kurumu, 2009. – 175 s.

*Мукимова Нәсимә Әнвәровна*
БашДУ ның Стәрлетамак филиалы
Стәрлетамак, Россия
*Mukimova Nasima Anvarovna*
Sterlitamak branch of BashSU
Sterlitamak, Russia

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЛЕКСИКОГРАФИК ЧЫГАНАКЛАРЫНДА ТОТРЫКЛЫ ЧГЫШТЫРУЛАР
# SUSTAINABLE COMPARISONS IN THE LEXICOGRAPHIC SOURCES OF THE TATAR LANGUAGE

Аннотация. *Сравнение является одним из популярных средств выразительности в литературе, особой лексической единицей, организованной по определенной синтаксической модели. Среди сравнительных конструкций выделяются устойчивые обороты, которые в татарском языкознании системно не исследованы. В данной статье описываются результаты изучения словарей татарского языка на предмет фиксации в них устойчивых сравнений.*

Annotation. *Comparison is one of the most popular means of expression in literature, a special lexical unit organized according to a specific syntactic model. Among comparative constructions, expressions are distinguished, which are not systematically studied in Tatar linguistics. This article describes the results of studying the dictionaries of the Tatar language with a view to fixing sustainable comparisons in them.*

Ключевые слова. *Устойчивые сравнения, татарский язык, словари.*

Keywords. *Sustainable comparisons, the Tatar language, dictionaries*

Дөньяны танып белүдә иң беренчел һәм актив алымнарның берсе – чагыштыру. Ул – фәндә кулланылган универсаль төшенчә. Чагыштыру, татар тел гыйлемендә лексик-синтаксик категория буларак һәм әдәбият белемендә киң кулланылган тел-сурәтләү чарасы рәвешендә, С.Ш. Поварисов, Ф.М. Хатипов һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә киң яктыртылды. Чагыштыруга корылган конструкциянең төзелешен җентекле итеп тикшерүче С.Ш. Поварисов әлеге лексик-синтаксик берәмлекне куллана белүнең әһәмиятен болай дип билгели: «компонентларның үзенчәлеген, аларның кайсы яктан, нинди сыйфатлары буенча охшаш булуын төшенеп эш итү мөһим» [Поварисов, 1996: 8].

Рус тел гыйлемендә «Устойчивые сравнения» термины куллануга һәм бу тел берәмлегенә багышланган берникадәр хезмәтләр булуга карамастан, аның билгеләмәсе бирелми. Әлеге мәсьәләгә кагылышлы хезмәтләр авторы В.М. Огольцев, рус телендәге тотрыклы сүзтезмәләрне туплап, сүзлек төзи. Аның билгеләвенчә, язучылар тарафыннан уйлап табылган һәм әсәрләрдә урын алган яки көндәлек тормышта спонтан рәвештә телдән сөйләмдә барлыкка килгән индивидуаль һәм ирекле чагыштырулар, вакытлар үтү белән, гомумхалык кулланылышына күчәләр һәм тотрыклы чагыштыруга әйләнәләр. Ирекле чагыштырулардан аермалы буларак,

алар телдә әзер килеш яшиләр һәм сөйләм күренеше түгел, тел системасының берәмлекләре булып торалар [Огольцев, 2001: 5-6].

Татар тел гыйлемендә, гомумән, бу терминның кулланылышы күзәтелми һәм бүгенге көнгәчә татар телендәге тотрыклы чагыштырулар комплекслы төстә системага салып өйрәнелмәгән. Алда күрсәтелгән хезмәткә һәм мәгълүматларга таянып, тотрыклы чагыштыруга аңлатма бирәбез һәм мәкалә кысаларында әлеге берәмлекләрнең татар теле сүзлекләрендә бирелүен тикшерү нәтиҗәләрен тәкъдим итәбез.

Билгеле булганча, телдәге төшенчәләр бер сүз белән генә түгел, ә үзгәртелми, таркалмый торган тотрыклы сүзтезмәләр, ягъни фразеологизмнар белән дә белдереләләр. Безнең күзәтүебезчә, фразеологик сүзтезмәләр арасында чагыштыруга корылганнары да бар, мәсәлән, *эт белән песи кебек яшәү, уклау йоткан шикелле тору, ике җирдә икең дүрт кебек, күрше тавыгы каздай, бармак башы кадәр һ.б.* Димәк, аларны тотрыклы чагыштырулар дип атарга була, чөнки алар да фразеологизмнар кебек кимендә ике сүздән торалар, телдә үзгәрешсез яшиләр, сөйләмгә әзер килеш килеп керәләр.

Шулай итеп, тотрыклы чагыштыру – ул гомумхалык телендә кабул ителгән, сөйләмдә әзер материал буларак кулланылган һәм чагыштыруга корылган сүзләр тезмәсе.

Телдәге тотрыклы чагыштырулар берничә мәгънәгә дә ия булырга мөмкин: *эт кебек – усал якитугры,чабу (күп, шәп һәм тәртипсез йөрү), ару һ.б.* Бу тотрыклы чагыштыру халык мәкальләрендә дә урын тапкан*: Аш янында ат кебек, эш янында эт кебек.* (Аш янында ат кебек ашап та, эшләгәндә эт шикелле мәнфәгатьсез йөргән, карулашкан кешеләр турында) [Исәнбәт, 2010:238]; *Эт кебек эшли, ат кебек ашый* [Исәнбәт, 2010:241].

Татар теленең аңлатмалы сүзлекләрендә тотрыклы чагыштырулар теркәлмәгән, тик -ча/-чә аффикслары белән ясалган охшату-чагыштыру рәвешләре арасында билгеле бер милләтнең теленә күрсәтүче рәвешләр (абхазча, аварча, адыгейча, албанча, бурятча һ.б.), һөнәргә хас билгене күрсәтүче (артистларча һ.б.), яшь билгеләре буенча катламга хас сыйфатларны белдерүче (ата-аналарча, балаларча, бабайларча һ.б.), кешеләрнең мөнәсәбәтен белдерүче рәвешләр (дошманнарча, дусларча һ.б.) бар.

Татар телендәге тотрыклы чагыштырулар дип билгеләп булган конструкцияләр «Татарча-русча тезмә сүзләр сүзлеге»ндә бирелгән. Ачыкланган 27 лексик берәмлекнең барысын да тотрыклы чагыштырулар дип танырга кирәк, әмма аларда чагыштырылучы компонент бирелми: *әфлисун төсле* – апельсиновый; *балавыз сыман* – как воск; *дуга кебек* – дугой, дугообразный; *җен кебек* – как чёрт; *имән кебек* – (таза, нык) – крепкий как дуб; *кара төсле* – тёмнолицый; *картлар кебек* – по-стариковски; *каштан төсле* – каштанового цвета; *көмеш төсле* – серебристый; *көмеш төсле тавыш* – серебряный голос; *келәшчә кебек* – как клещ; *кристалл кебек* – кристальный; кристально-чистый; твердый как кристалл; *көл төсле* – пепельный; *майланган кебек* – как по маслу;*миләүшә төсле* – фиолетовый; *сирень төсле* – сиреневый; *сөлек кебек* –

поджарый о лошади, әмма татарча-русча сүзлектә: очень стройный и физически развитый, красавец; *тән төсле* – телесный; *төп кебек таза* – крепкий как пень;*фирәзә төсле* – бирюзовый; *шуның кебек* – подобный, такой; *шуның шикелле* – подобный, такой; *чәчәк кебек* – во цвете лет, как цветок; *чия төсле* – вишнёвый; *шикәр кебек (төсле)* – сахаристый; *ялап куйган кебек* – как облизанный; *ярка кебек* – как бревно, обрубок.

Әлеге чагыштыруларны белдерүдә *кебек, төсле* бәйлекләре актив, ә *шикелле һәм сыман* бәйлекләре бик сирәк кулланылган. Бу төзелмәләрдә предметның төсен күрсәтүчеләр шактый (*чия төсле, каштан төсле, көмеш төсле, көл төсле, кара төсле*). Күпчелек очракта предмет һәм аның сыйфаты чагыштырыла, ә процесс буенча чагыштыру тик ике очракта: *ялап куйган кебек, майланган кебек*.

«Татарча-русча идиомалар сүзлеге»ндә чагыштыруга корылган 64 лексик берәмлек билгеләдек, шуларның берничәсе:*ата күркә кебек кабарган* – надулся как индюк; вздулся, как тесто на опаре; *афишага баккан кәҗә сыман* – уставиться как баран на новые ворота; *ачы булсаң, тоздай бул, татлы булсаң балдай бул* – будь во всём последовательным; *аяз көндә яшен суккан кебек булу (суккандай булу)* – как гром среди ясного дня; *әвене янган кешедәй йөрү* – быть унылым (мрачным); ходить как в воду опущенный; *багана кебек катып калу* – остолбенеть; окаменеть; *бала сүзе батмандай, килен сүзе китмәндәй* – слово своего дитя – сосуд мёда, слово снохи словно кирка; *балтасы суга төшкән кебек* – как в воду опущенный; сам не свой; голову повесил; нос повесил. Бу тотрыклы чагыштырулар кешенең хәл-тормышын, яшәү рәвешен сурәтләгәндә кулланылалар.

*Бар чакта бүредәй, юк чакта шүредәй* – есть – так густо, нет – так пусто; *биш бармагың кебек белү* – знать как свои пять пальцев; *бүреләр белән яшәсәң, бүречә (бүре кебек, бүре сыман) уларсың)* – с волками жить, по-волчьи выть; *дөядәй буең булганчы, төймәдәй акылың булсын* – чем иметь рост с верблюда, лучше иметь ум с пуговицу; *еландай бөтерелү* – виться ужом (*букв.* змеёй). Бирелгән берәмлекләрдә әйбернең кадерен белү, чама хисен онытмау, акыллы булырга тырышу кебек кешелек сыйфатлары ачык сурәтләнә.

*Ефәк кебек булды* – стал как шёлковый; *җил алгандай* – как ветром сдуло; как не было; *җилкәдән (өстән) тау төшкән кебек була* – (как) гора с плеч; камень с души свалился; *җир астыннан калкып чыккандай булу* – как (словно) из-под земли вырасти; *җир тишегенә керердәй булдым* – быть готовым провалиться сквозь землю; *ике икең дүрт кебек* – как дважды два четыре; *ике күзем кебек* – свет очей моих; моя радость; *ике тамчы су кебек* – как две капли воды; *иманнан качкан шайтан кебек* – как чёрт от ладана; *имән кебек*–крепкий как дуб; здоровяк; *итәгенә ут капкандай чаба* – бежит как угорелый; *йоны йолкынган тавык кебек* – как ощипанная курица һ.б.

Искә алырга кирәк, шулай ук халык сөйләшләрендә, аерым җирлектә генә кулланыла торган чагыштырулар була, алар шушы җирлектәге табигатьнең, билгеле объектларның, кешеләрнең үзенчәлекләре белән бәйле була: *Җигән елгасы кебек бормалы-бормалы, сылап куйган кебек булды (Гафури районы, Үтәк*

*авылы), икенде күләгәсе кебек кенә калган (Бишбүләк, Ает авылы), бите йомран күкәе кебек (Авыргазы районы, Солтанморат авылы)* һ.б. Димәк, әлеге берәмлекләрнең диалектологик сүзлекләрдә теркәлүен дә күзәтү кирәк.

Шулай итеп, беренчел күзәтүләр нигезендә тотрыклы чагыштыру конструкцияләренең сүзлекләргә теркәлеп бетмәгәне ачыкланды. Алдагы көндә татар әдәби телендәге тотрыклы чагыштыруларны туплаган лексикографик чыганак кирәклеге ачык.

Индивидуаль сөйләм актында образлылык тудыру өчен предметлар һәм күренешләр арасындагы чагыштыруга нигезләнгән күптөрле һәм күп сандагы бәйләнешләр урын алуга карамастан, тик аерым кайсыберләре генә тел системасында ныгып кала. Катлаулы һәм күптөрле бәйләнешләрне билгеләүче берәмлекләр буларак, тотрыклы чагыштырулар телдә үзенчәлекле структурага һәм семантикага ия булган система тәшкил итәләр.Бу алдагы тикшеренү эшләрендә чагылыш табар.

**Әдәбият**

1. Гафарова Ф.Ф, Саберова Г.Г. Татарча-русча идиомалар сүзлеге. – Казан, 2006. – 232 б.
2. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда, 1 нче том. – 2 нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.– 624 б.
3. Огольцев В.М. Словарь устойчивых сравнений русского языка (синонимо-антономический). – М.: ООО «Русские словари»: «ООО Издательство Астрель»: ООО «ИздательсвоАст», 2001. – 800с.
4. Поварисов С.Ш. Татар телендә чагыштыру төзелмәләре. – Уфа, 1996. – 118 б.
5. Сафиуллина Ф.С., Газизова Ф.М. Татарча-русча тезмә сүзләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 364 б

*Мулласалихова Гөлсирә Гусмановна*
Саба районы Шәмәрдән лицее
Шәмәрдән, Россия
*Mullasalikhova Gulsira Gusmanovna*
Shemordanskylyceum of Sabinsky district
Shemordan, Russia

## ТАТАР ТЕЛЕН РУС ТЕЛЕ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРЫП ӨЙРӘТҮ
## ACOMPARATIVE STUDY OF THE TATAR AND RUSSIAN LANGUAGES

Аннотация. *Статья посвящена сопоставительномуизучению татарского и русского языков в целях формирования билингвальных личностей школьников. Билингвизм (двуязычие) - это свободное владение двумя языками одновременно, является главным и решающим фактором коммуникации людей, укрепления дружбы и мира между разными народами. Изучение языка – это не только изучение правил языка, но и развитие речи.*

Annotation. *The article is devoted to the comparative study of Tatar and Russian languages in order to form bilingual personalities of schoolchildren. Bilingualism (bilingualism) is the fluency of two languages at the same time, is the main and decisive factor of communication of people, strengthening of friendship and peace between different peoples. Language learning is not only learning the rules of language, but also the development of speech.*

Ключевые слова: *коммуникативный, метод обучения, ударение, фонетика, закон сингармонизма, аффиксы.*

Keywords: *communicative, teaching method, stress, phonetics, law of synharmonism, affixes.*

Без бүген төрле телләрне өйрәнү мөмкинлеге булган заманда яшибез. «Дөньяда гакылдан шәриф нәрсә юк вә рух байлыгыннан артык байлык юк. Берәү чит телне өйрәнәсе булса, башта үз телен яхшы белсен». Бөек татар мәгърифәтчесе, күренекле галим һәм мөгаллим Габделкаюм Габделнасыйр углы Насыйриның әлеге сүзләре бүгенге көндә дә үзенең актуальлеген югалтмый.

Татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнүнең тарихы ерак гасырлардан килә. XVIII һәм XIX гасырларда ук төзелгән «Азбука» һәм «Грамматика татарского языка для русских учебных заведений» хезмәтләрендә дә ике телнең гомуми һәм үзенчәлекле якларын аерып алу методы кулланылган. Мәсәлән, И. Гиганов, И. Хәлфин, А. Троянский, А. Казембекларның хезмәтләре шундыйлардан [Харисова 2001:28]. Әмма татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасын төзүне башлап җибәрүче дип хаклы рәвештә энциклопедист-галим һәм мәгърифәтче К. Насыйрины санарга тиешбез. Аның «Краткая татарская грамматика» (1860) һәм «Образец русско-татарской грамматики» (1893) китаплары татар телен өйрәнүче руслар һәм рус телен өйрәнүче татарлар өчен беренче лингвометодик әсбап булып тора [Харисова 2001:31]. К. Насыйри рус телен үзләштерү, рус китапларыннан файдалану өчен кирәк булган уку китапларын булдыру өстендә дә эшли («Кыйраәте рус», 1889). Рус теленең грамматикасын («Нәмүнә, яки әнмүзәҗ», 1891) төзеп бастырып тарата. Бу эшләрен үзенең практик, укыту процессында сынап, ул бер телне икенче тел белән чагыштыру методын куллана. К. Насыйри башлап җибәргән юлны дәвам иттерүче,әдәби телнең матур бинасын коручы тел галимнәренең берсе – Мөхетдин Корбангалиев.

М. Корбангалиевның 1924 елда Р. Газизов белән берлектә төзегән «Опыт систематической грамматики татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка» дигән кулланмасы татар телен рус теле белән чагыштырып өйрәнү өлкәсендә зур әһәмияткә ия булып тора. Бу кулланма үз вакытында татар телен өйрәнүчеләр өчен дә, аны укытучылар өчен дә бердәнбер кулланма булып санала. М. Корбангалиев үзенең эшләү практикасында барлык нечкәлекләргә дә игътибар иткән [Харисова 2001:31]. Анын, бу өлкәдәге хезмәте тулысынча оригиналь булып тора. Монда ул теге яки бу методистлардан үрнәк алмаган, аларның методларыннан файдаланмаган, бәлки икенче телне өйрәнгән вакытта

кулланырга яраклы төрле метод һәм алымнарны үз тәҗрибәсеннән чыгып тәкъдим иткән; эшләү юлларын күрсәткән.

Мин рус сыйныфларында укучы татар балаларына, рус телле укучыларга татар теле һәм әдәбиятын укытам. Укыту дәверендә байтак тәҗрибә тупларга насыйп булды. Рус телле балаларның татар телен яхшы һәм җиңел үзләштерүләрен булдыру өчен, телнең үзенә генә хас үзенчәлекләрен белүләренә ирешергә кирәк. Татар теленә чит тел буларак өйрәтүнең башлангыч этабында рус телле балаларны татар телендә төрле темаларга сөйләшергә өйрәтү, типик җөмләләрне файдаланып, аралашу күнекмәләрен булдыру; укытучының гади генә һәм бик катлаулы булмаган җөмләләрен аңларга, яшьтәшләре белән аралашырга өйрәтү; уку һәм язу күнекмәләрен формалаштыру, балаларны татар халкының этнокультурасына аз-азлап күнектерә бару – төп бурычлар булып торалар. Шулардан чыгып, рус телле балаларга татар теле укытуның җиңел, отышлы һәм аңлаешлы алымнарын сайлап алырга туры килә. Үземнең эш тәҗрибәмнән чыгып, татар теленә өйрәтүне татар телен рус теле белән чагыштыру, охшаш һәм аермалы якларын ачыклау юлы аша төшендереп, тормышка ашырырга мөмкин дип саныйм.

Татар телен рус теле белән чагыштырып өйрәнү ике яклы планда үткәрелә: рус теле – татар теле белән, татар теле рус теле белән чагыштырыла. Телгә өйрәтү барышында кыенлыклар исәпкә алына, алардан чыгу юллары күрсәтелә, даими кабатлаулар аша дөрес әйтү күнекмәләре булдырыла. Татар теленең үзенчәлекле тартыклары ([w], [гъ], [къ], [җ], [ң]) әйтелеш кыенлыклары арасында зур урынны алып тора.

Татар телендә иҗекләрнең ачык һәм ябык типлары бар, ә рус телендә күбрәк ачык иҗекләр ясала. Шунлыктан, сүзләрне иҗекләргә бүлгәндә, түбәндәге тип хаталар барлыкка килә: дә-ре-скә - дә-рес-кә. Шуңа күрә укучыларга татар телендә берничә тартык рәттән килмәве турында ешрак исләренә төшерергә кирәк. Башка милләт балаларын татар теленә өйрәтүдә фонетик кыенлыкларны җиңү зур әһәмияткә ия.

Моннан тыш, татар телендә исемнәр одушевленный - неодушевленный дигән төрләргә бүленмәгәнлектән, хайваннар, кошлар, бөҗәкләргә дә кем соравы куялар. Язганда һәм сөйләгәндә, күплек сан формалары ясаганда, хаталар җибәрәләр. Рус телле балалар өчен татар теленең үзенчәлекле грамматик категориясе – тартым, бигрәк тә аның аффикслары зур катлаулылык тудыра. Өйрәнү өчен иң кулае булып тартымның иялек килешендәге зат алмашлыгы белән белдерелгән формасы санала: минем китап (китабым), синең китап (китабың). Әлеге формадагы сүз тәртибе белән аның мәгънәсе балаларның туган (рус) теле белән туры килә, һәм моны исәпкә алу тартым категориясен үзләштерүне беркадәр җиңеләйтә.

Татар теленең килеш категориясенә килгәндә, төшем килеше исеме һәм мәгънәсе буенча ике телдә дә уртак булып тора (винительный падеж): хат-ны

(язу) – писать письмо, әнине (ярату) – любить (маму). Рус һәм татар телендә алтышар килеш бар, әмма аларның мәгънәләре күп очракта туры килми.

Рус укучыларының татар әйтелешен авыррак үзләштерүе әлеге телләрнең үзенчәлекләренә бәйле. Беренчедән, алар төрле типологик групппаларга керәләр: татар теле һәм башка төрки телләр агглютинатив булса, рус теле исә флектив телләр рәтенә керә. Икенчедән, төрки телләрдә төп фонетик закон – сингармонизм хәрәкәт итә. Бу телләрдә сузыклар һәм тартыклар системасында да аермалар шактый. Мәсәлән, төрки телләрдә сүз һәм иҗек башында берничә тартык янәшәкилә алмый. Ике телдә дә басымның гомуми һәм үзенчәлекле яклары бар, иҗеккә бүленеш белән интонациядә дә үзенчәлекләр шактый нык сизелә. Рус һәм татар телендә басымның урыны төрлечә булуны белү бик әһәмиятле. Рус телендә басым сүзнең бер иҗегенә генә беркетелмәгән, ул төрле иҗеккә төшә. Татар телендә, гадәттә, басым сүзнең соңгы иҗегенә төшә.

Өйрәнә торган телнең әйтелеш системасын үзләштерү, билгеле булганча, авазларны кабул итү белән әйтеп карау нәтиҗәсендә ишетү һәм артикуляцияләү күнекмәләре булдыруга да бәйле. Шуңа күрә чагыштырма телләрдәге фонемаларның физиологик һәм акустик үзенчәлекләрен өйрәнү бик мөһим. «Авазлар, чыннан да, сүз эчендә һәм аннан тыш та яши, билгеле бер акустик һәм артикуляцион характеристикага ия. Чит телнең авазын дөрес куллану өчен, аны сүз составында да, аерым да ишетә һәм әйтә белергә кирәк» [Баранников 1984:17]. Аерым аваз, сүз яки җөмләне әйтүнең үзенчәлекләрен белгән шартта гына дөрес әйтелешкә өйрәтүне нәтиҗәле итеп оештырып була. Үзара охшаш булган аваз һәм фонетик күренешләрне әйтүдәге хаталар чит телнең әйтелеш нормаларын боза.

Чит телне өйрәнгән вакытта телләр үзара катлаулы бәйләнешкә керәләр һәм чит телдәге күренешләр туган тел фонында кабул ителәләр. Рус телендә сөйләшүче укучыларны татар әйтелешенә өйрәтүнең фәнни яктан нигезләнгән методикасын әлеге ике телнең чагыштырма характеристикасына һәм укучыларның гамәли яктан әзерлегенә таянып төзергә мөмкин.

Рус телле балаларга татар телен укыту программасында әйтелгәнчә, укучылар, фонетик, лексик, грамматик минимумнарны үзләштереп, лингвистик һәм коммуникатив компетенциягә ия булырга тиешләр. Татар теле сөйләшү-аңлашу, аралашу чарасы буларак укытыла. Алар белемнәрен һәм күнекмәләрен төрле аралашу ситуацияләрендә куллана белергә тиешләр.

Укучыларның лексик күнекмәләрен үстерү өчен, сүзләрнең әйтелешен, язылышын, мәгънәсен, ясалышын, башка сүзләр белән бәйләнешен, сөйләмдә кулланылышын үзләштерү мөһим. Моның белән беррәттән, татар һәм рус телләрендәге сүзләрнең мәгънә ягыннан аермаларын күрсәтеп бару, рус телендә эквивалентлары булмаган сүзләрне аңлатып бирү дә сорала. Бу очракта укучыларның сөйләмендәге лексик-семантик хаталарны киметү мөмкинлекләре күбәя. Татар телендә (полисемия) күренеше киң таралган. Шуңа күрә укытучы

сүзнең тиешле мәгънәсен контексттан чыгып сайлап алу күнекмәләрен камилләштерүгә дә аерым игътибар бирергә тиеш.

**Әдәбият**


1. Баранников И.В. Обучение звуковой системе русского языка. – Улан-Удэ: Бурят. кн. изд-во, 1984. – С. 36.
2. Газизов Р.С. Сопоставительная грамматика татарского и русского языков. – Казань: Таткнигоиздат, 1966. – С.5.
3. Хайдарова Р.З. Научно-педагогические аспекты билингвального образования в Республике Татарстан: Монография. – Набережные Челны: ОАО «Набережночелнинская типография», 2006. – 200с.
4. Харисова Ч.М. Обучение татарскому произношению в русской школе. – М.: Гуманит. изд. центр ВЛАДОС, 2001. – С. 38.



*Муталов Расул Османович*
Институт языкознания РАН
Москва, Россия
*Mutalov Rasul Osmanovich*
Institute of Linguistics of the RussianAcademy of Sciences
Moscow, Russia
*Гасанова Узлипат Усмановна*
Дагестанский государственный университет
Махачкала, Россия
*Gasanova Uzlipat Usmanovna*
Dagestan state University
Makhachkala, Russia


# ХАРАКТЕРИСТИКА ДЕЕПРИЧАСТНЫХ ФОРМ В КАДАРСКОМ ЯЗЫКЕ
# CHARACTERISTICS OF PARTICIPIAL FORMS IN THE KADAR LANGUAGE


*Работа выполнена при финансовой поддержке Российского фонда фундаментальных исследований (РФФИ), проект № 18-012-00718 «Документирование кадарского языка: грамматический очерк, тексты, словари».*



Аннотация. *В работе исследуются способы образования и функционирования деепричастных форм в кадарском языке. Рассматриваются как деепричастия образа действия, так и союзные деепричастия, служащие для присоединения зависимых предложений к главным в полипредикативных конструкциях. На основе сравнения с материалом других даргинских языков выявлены основные особенности деепричастия данного языка.*

Annotation.*The article describes the methods of formation and functioning of the participial forms in the Kadar language. Both the participles of the mode of action and the conjunctional participles that are used to attach dependent sentences to the main ones in poly-predicative constructions are considered. On the basis of a comparison with the other Dargin languages, the main peculiarities of the participle of this language are revealed.*

Ключевые слова. *Даргинские языки, кадарский язык, глагол, деепричастие.*
Keywords. *The Dargin languages, the Kadar language, verb, participle.*

Кадарский язык относится к даргинской ветви нахско-дагестанских языков. Долгое время данный идиом развивался в отдалении от других даргинских языков, в тесном контакте с кумыкским языком, относящемся к тюркской языковой семье. На кумыкском языке в советские годы велось делопроизводство, данным языком владеет практически все взрослое население. Влияние кумыкского языка на кадарский обнаруживается как в фонетике и лексике, так и в грамматической структуре языка.

Кадарский язык обладает своеобразными чертами на каждом языковом уровне, особенно ярко они проявляются в морфологии. Целью настоящего исследования является выявление особенной образования и функционирования одной из отглагольных форм кадарского языка – деепричастия. Данная форма служит основой образования различных форм времени, как синтетических, так и аналитических.

Деепричастие – нефинитная форма глагола, обозначающая второстепенное действие, подчиненное главному, выраженному в предложении сказуемым или инфинитивом в разных синтаксических конструкциях. В даргиноведческой литературе данное отглагольное образование получило довольно подробное освещение [Абдуллаев, 1954; Магометов, 1979; Муталов 2003 и др.]. Однако деепричастие кадарского языка пока не получило какого-либо удовлетворительного описания: до сих пор вне поля зрения остается богатый материал даргинских языков, которые до недавнего времени считались диалектами одного языка и вследствие этого оставались неизученными.

Результаты сопоставительного анализа русских предложно-падежных конструкций и их соответствий в татарском языке позволяют утверждать, что татарский язык тяготеет к языкам с «семантически» ориентированными падежными системами. Татарские эквиваленты довольно часто (но не всегда) представляют собой конструкцию «баш килеш (основной падеж) + послелог или послеложное слово»: *отойти* ***от двери*** (Р.п.) – ***ишек*** (Б.к.) ***яныннан*** *китү; товары* ***для дома*** (Р.п.) - ***өй*** (Б.к.) ***өчен*** *җиһазлар; подъехать* ***к дому*** (Д.п.) - ***өй*** (Б.к.) ***янына*** *килеп туктау; идти* ***по следу*** (Д.п.) – ***эз*** (Б.к.) ***буенча*** *бару*.

Сравнительный анализ категории падежа русского и татарского языков будет неполным без описания ее грамматической семантики. В русском языке выделяются 4 типа диктальных падежных значений: субъектное, объектное, обстоятельственное (адвербиальное) и определительное (атрибутивное). Практическивсе русские падежи способны выражать каждое из этих значений, однако наиболее частотными среди них являются субъектное, объектное и определительное. В татарском языке, наоборот, наибольшее распространение получило обстоятельственное значение. Так, данное значение характерно следующим падежным формам: основ. п.: ***бер ай*** *кунак булу* – гостить месяц, направ.п.: ***елгага*** *төшеп, су коендым* – спустившись к реке, я искупался; вин.п.: *алар* ***һәр елны*** *авылга кайталар* – они каждый год приезжают в деревню; исход.п.: ***юлдан*** *бару* – идти по дороге и др. [Татарская грамматика, 1993: 46-54].

Подводя итоги, следует сказать, что функционирование категории падежа в разносистемных языках, каковыми являются татарский и русский, имеет ряд специфических особенностей. Их выявление и описание имеет важное значение как для характерологии грамматических систем, так и для практики преподавания русского и татарского языков в иноязычной аудитории. И в этом плане большую ценность представляет научно-методическое наследие Э.М. Ахунзянова, посвященное изучению морфологического строя русского и татарского языков.

**Литература**

1. Ахунзянов Э.М. Контрастивная грамматика: морфология русского и тюркских языков: учеб. пособ. – Казань: КГУ, 1987. – 151 с.

2. Лингвистический энциклопедический словарь / Под ред. В.Н. Ярцевой. – М.: Советская энциклопедия, 1999. – 685 с.

3. Мусатов В.Н. Русский язык: Морфология: учебник. – М.: Флинта, 2019. – 464 с.

4. Плунгян, В.А. Общая морфология: Введение в проблематику: учеб.пособ. – М.: Эдиториал УРСС, 2000. – 384 с.

5. Татарская грамматика: В 3 т. Т. 2. Морфология. – Казань: Татар.кн. изд-во, 1993. – 397 с.

*Харисов Фираз Фахразович*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Kharisov Firaz Fakhrazovich*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

## УКУЧЫЛАРДА КОМПЕТЕНЦИЯЛӘР ФОРМАЛАШТЫРУ МӘСЬӘЛӘСЕ
## STUDENTS COMPETENCES FORMATION PROBLEMS

Аннотация. *Статья посвящена проблеме формирования компетенций у учащихсяпри обучении татарскому языку. Дается краткая характеристика следующим компетенциям: коммуникативная, лингвистическая компетенции, компетенции, относящиеся национальной культуре и социально-культурная компетенция.*

Annotation. The article deals with *the problem of the formation of students competencies inteaching of the Tatar language. A brief description of the following competencies is given:: communicative, linguistic competencies, competencies related to national culture and socio-cultural competence.*

Ключевые слова. *Компетенции, учащихся, обучение, татарский язык.*

Keywords. *Competencies, students, teaching, the Tatar language.*

Тупланган белем үзе генә, кулану осталыгы һәм күнекмәләр булдырудан башка, мәктәптән тыш эшчәнлеккә әзерләү мәсьәләсен хәл итә алмый. Шуңа күрә хәзер бу проблема киңрәк һәм башка төрле яссылыкта куела: иҗтимагый тормышка әзерләү өчен, укучыларда кирәкле компетенцияләрне булдыру белеем алуның максаты итеп куела.

«Европада урта белем» проекты кысаларында эшләнгән һәм Берн шәһәрендә 1996 нчы елда үткәрелгән симпозиумда кабул ителгән компетенцияләр түбәндәгеләр: икътисади-сәяси компетенция яки көндәлек тормышта туган проблемаларны чишүгә әзерлек (карар кабул итү һәм аны гамәлгә ашыру җаваплылыгын үз өстеңә алу); мәгълүмати компетенция; коммуникатив компетенция (аралашу компетенциясе); иҗтимагый-мәдәни компетенция; гомер буе белеем алуга әзер буллу компетенциясе. [Соловьёва, 2002: 11–14; 228; Зимняя, 1999: 112]

Югарыда саналган компетенцияләрнең уку-укыту эшчәнлегендәге әһәмиятен һич тә инкяр итмичә, татар теленә өйрәткәндә, түбәндәге компетенцияләрне булдыру мөһим.

***1.*** *Аралашу компетенциясе.* Узган гасырның 80 нче елларында «коммуникатив компетенция» дигән төшенчә барлыкка килә. Бу терминны

Америка социолингвисты Делл Хаймс тәкъдим итә. Ул аралашу өчен тел тамгаларын һәм аларның кушылу кагыйдәләрен белү генә җитмәвен, мәдәни һәм иҗтимагый яктан әһәмиятле шартларны, вакыйгаларны да белү кирәклеген әйтә. Шуңа күрә коммуникатив компетенцияне «интегратив белем бирү» дип атый һәм аның эчтәлегенә лингвистик һәм иҗтимагый-мәдәни компонетларны кертә. Бу фикер күп кенә чит ил галимнәре тарафыннан кабул ителә һәм кулланылышта йөри башлый, ләкин аңа өстәмәләр дә кертелә. Мәсәлән, Америка галимнәре М. Кэнэл һәм М. Свейн 4 хосусый компетенцияне аерып чыгара: грамматик (лингвистик), дискурсив, социолингвистик һәм стратегик. [Соловьёва, 2002: 18–22]

Аралашу компетенциясе үз эченә түбәндәгеләрне ала:

❖ башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасы;

❖ хәзерге татар әдәби теле нормаларына ия булу, сүз байлыгын, сөйләмнең грамматик ягын дөрес үзләштерү;

❖ бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен телдән һәм язма формада булдыру;

❖ урта һәм өлкән сыйныф укучыларының кызыксыну даирәсен киңәйтү, психологик һәм төрле аралашу ситуацияләренә бәйле рәвештә туган телдә аралаша белүгә ирешү, дәресләрдә үзләштергән белем һәм күнекмәләрдән нәтиҗәле итеп файдалана белү һ. б.

Шуның белән беррәттән, аралашу эшчәнлеген үстерүгә караган универсаль күнекмәләрдән түбәндәгеләргә өстенлек бирелергә тиеш:

❖ төркем белән эшләү күнекмәләрен булдыру (укучының иптәшләре һәм укытучы белән бергәләп эшләве мораль-әхлакый һәм психологик яктан гамәли эш алымнарына өйрәтә);

❖ аралашу компетенциясе нигезендә төрле бурычларны хәл итү алымнарын үзләштерү, тел өйрәнүнең башка кешеләр белән аралашу нигезен тәшкил итүен гамәлгә ашыру, шул максаттан чыгып, тормыш хәлләренә бәйле рәвештә иптәшең белән аралашу нормаларын һәм формаларын үзләштерү;

❖ телне өйрәнү акыл эшчәнлеген үстерүдә мөһим булган сөйләм эшчәнлеген камилләштерүне алгы планга кую (укучыларның ана телен өйрәнүендә аралашу компетенциясен истә тотып эш итүенә этәргеч ясый).

***2.*** *Лингвистик компетенция* укучыларның сөйләмне грамматик яктан дөрес формалаштыруларын, өйрәнелә торган телнең төрле яруслары буенча телдән һәм язма формада ирекле аралашуларын оештыра алырлык белемгә ия булуын аңлата.

***3.*** *Милли мәдәният өлкәсенә караган компетенция,* ягъни телне милли-мәдәни яссылыкта үзләштерү укучыларны сөйләмгә өйрәткәндә, рухи, эстетик тәрбия һәм белем бирү чарасы буларак, милли үзенчәлекләрне чагылдырган текстлар белән эшләү, тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, сынлы сәнгать әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү, татар сөйләм әдәбе нормаларын үзләштерү, шулар аша халыкның милли-мәдәни үзенчәлекләрен белү, телнең милләтләр арасында аралашу-аңлашу чарасы булуына төшенү; тел тарихы белән халык тормышының аерылгысыз булуын аңлау.

Телне мәдәният белеме яссылыгында өйрәнү, мәдәнияткә караган текстлардан файдалану укучыларның тел белән мәдәният бәйләнеше турындагы белемнәрен тирәнәйтергә мөмкинлек тудыра, яшь буында милли үзаң булдыруда зур роль уйный, татар телен чит тел буларак өйрәнүчеләргә башка милләт вәкилләренә түземле булырга, үзенең рухи байлыклары белән чагыштырып карарга һәм дөньяга карашын киңәйтергә ярдәм итә.

***4.*** *Иҗтимагый-мәдәни компетенция.* Иҗтимагый-мәдәни белем бирү–мәгариф системасында чагыштырмача яңа төшенчә, һәм ул иҗтимагый-мәдәни компетенция формалаштыру белән бәйле булган аралашу компетенциясе составына керә, аның бер өлеше санала.

Укыту процессына иҗтимагый-мәдәни яссылыкта якын килү телгә татар мәдәнияте аша өйрәтү юнәлешен билгели.

Иҗтимагый-мәдәни компетенциягә түбәндәгеләр керә:

❖ телнең танып белү һәм аралашу чарасы гына түгел, бәлки иҗтимагый хәтер формасы да икәнлегенә төшенү;

❖ тел берәмлеге эчендә аңа хас булган мәдәни эчтәлекне күрә-тоя белү;

❖ өйрәнелә торган тел вәкилләре һәм сөйләм белән милли-мәдәни мохит арасындагы бәйләнешне аңлау;

❖ тел һәм җәмгыять үсеше турындагы белемнәр җыелмасын куллану, татар телендә аралашу осталыгына ия булу;

❖ иҗтимагый-мәдәни эчтәлектәге белем (Туган ил яки туган төбәк, өйрәнелә торган тел, аның рухи байлыклары, мәдәни традицияләре турында мәгълүмат) алу;

❖ аралашу тәҗрибәсен туплау;

❖ телне куллану алымнарын белү;

❖ чит тел мәдәнияте күренешләренә шәхси мөнәсәбәт белдерү;

❖ мәгълүмати яктан бай булу;

❖ актуаль һәм заманча булу;

❖ аутентик текстларның күплеге;

❖ татар мәдәниятен чагылдырган текстлар булу;

❖ укучыларның кызыксыну даирәсен истә тоту;

❖ сөйләмнең татар әдәби теле нормаларына туры килүе;

❖ өйрәнә торган текстларның катлаулана бару принцибына туры килүе;

❖ рус мәдәниятен чагылдырган материалларны даими куллану;

❖ сайлап алынган материалларның аңлаешлылык һәм көч җитү принципларына туры килүе.

Яңа буын Стандартта укучыларны иҗтимагый тормышка әзерләү мәсьәләсенә зур урын бирелә. Мондый таләпләрне уңай хәл итү укучыларда татар теле чаралары ярдәмендә иҗтимагый-мәдәни компетенция булдыруның нәтиҗәлелеген күтәрергә ярдәм итәчәк.

Яңа җәмгыятьтә үз урыныңны табу телләр белүгә бәйле, һәм бу уңайдан гомуми белем бирү оешмаларында аны тиешенчә үзләштергән шәхес тәрбияләү

мөһим бурычлардан санала. Проблеманы уңай хәл итүнең бер юлы–дәресләрдә иҗтимагый-мәдәни материалларны кирәгенчә куллану. Билгеле булганча, текст аның төп эчтәлеген тәшкил итә. Шуңа күрә башка чыганаклар гамәлдә киң кулланылырга тиеш, болар – аерым темага караган текстлар, Татарстан һәм Россия турында матур әдәбият әсәрләреннән алынган өзекләр, диалог (полилог) үрнәкләре, җырлар, шигырьләр, аудио- һәм видеотекстлар һ.б.

Укучыларда иҗтимагый-мәдәни компетенция булдыру белем бирүдә яңа юнәлешләрнең берсе булып санала. Әлеге мәсьәләнең уңай чишелеше телне милли һәм мәдәни яссылыкта өйрәтү белән бәйләнгән. Бала дәресләрдә үзенең һәм башка халыкларның мәдәниятен хөрмәт итәргә, аны дөрес бәяләргә, төрле халыкларның мәдәни кыйммәтләрен үзара бәйләнештә карарга өйрәнсен. Өйрәнү материалына мондый караш телгә һәм мәдәнияткә кызыксынучанлык, башка милләт вәкилләренә сабыр һәм түземле мөнәсәбәт тәрбияли. Шуңа да тел дәресләрендә татар һәм рус халкының мәдәни традицияләре, гореф-гадәтләре, кыйммәтләре белән танышу өчен зур мөмкинлек тудырылуга җирлек бар [Харисов, 2018: 25-32].

Билгеле булганча, бу компетенцияләр үзара тыгыз бәйләнештә яши. Иҗтимагый-мәдәни компетенциянең бүгенге көндә аеруча актуаль булуын, татар теле методикасына караган элеккеге һәм хәзерге хезмәтләрдә чагылыш тапмавын истә тотып, аңа киңрәк тукталдык.

Укучыларда төрле компетенцияләр булдыруның һәм үстерүнең кирәклеге яңа Стандартның эчтәлегеннән аңлашыла. Аны гамәлгә ашыру телгә өйрәтүне милли һәм мәдәни яссылыкта алып баруның стратегиясен билгели. Кыскача гына әйткәндә, бу күренеш хәзерге күптөрле милләтләр яшәгән җәмгыятьтә үзара дустанә мөнәсәбәткә ия булган хезмәттәшлеккә әзерлекне дә аңлата. Укучыларда аны формалаштыру һәм үстерү уку-укыту процессына куела торган белем бирү, үстерү һәм тәрбияви максатларны да хәл итүгә юнәлтелгән.

**Литература**

Зимняя И.А. Педагогическая психология. – М.: Логос, 1999. – С. 112.

Соловьёва Е.Н. Методика обучения иностранным языкам: базовый курс. – М: Просвещение, 2002.

Харисов Ф.Ф. Татар теле: теория һәм практика. Монография. – Казан: «Ак бүре» нәшр., 2018. – Б. 25-32.

*Хәбибов Лотфулла Гайфуллович*
БРның Мәгарифне үстерү институты
Уфа, Россия
*Habibov Lutfulla Saifullovich*
Institute of education development RB
Ufa, Russia

# АЕРЫМ СҮЗ ТӨРКЕМЕ БУЛАРАК ХӘБӘРЛЕК СҮЗЛӘР
# PREDICATIVE WORDS AS AN INDEPENDENT PART OF SPEECH

Аннотация. *В татарском языкознании предикативные слова долгое время не рассматривались как отдельная часть речи. Часть из них зачислилась в разряд собственно модальных слов, хотя они обозначают недейственное состояние предмета и выступают преимущественно в функции сказуемого самостоятельно или в сочетании с другими словами. Кроме них в языке имеются и другие предикатиивные слова:бәхил* (прощение)*, риза, разый* (довольный, согласный)*, там* (устар.) (полный, в совершенстве), *таман* (в пору), *таң* (поражаться)*, тартым* (похожий), *тансык* (желанный), *тәмам* (окончательно),*үтүт* (не досталось никому)*, хуп* (одобрение), *хөрт, хөрти* (неважный)*, ярыйсы* (подходяче).

Annotation. *In Tatar linguistics, predicative words were not considered as a separate part of speech for a long time. Some of them were included in the category of modal words proper, although they denote the non-effective state of the subject and act primarily as a predicate alone or in combination with other words. In addition to them in the language there are other predicate words: bahil (forgiveness), riza, razy (contented, consenting), taman (at the time), tan (amazed), tartym (similar), tansyk (desired), tamam (finally), utut (did not get anyone), hyp (approval), khort, khorti (unimportant), yaryysy (approach).*

Ключевые слова: *самостоятельная часть речи, предикативные слова, модальные слова, функция.*

Keywords. *independent part of speech, predicative words, modal words, function.*

Татар тел белемендә хәбәрлек сүзләр (предикативлар) үзаллы лексик-грамматик разряд, ягъни аерым сүз төркеме буларак 20 нче гасырның урталарында танылды. Г. Алпаров 1945 нче елда нәшер ителгән «Сайланма хезмәтләр» дигән китабының «Функциональ сүзләр (ярдәмлекләр)» бүлегендә *кирәк, тиеш, мөмкин, бар, юк* сүзләрен тулы мәгънәле сүз белән ярдәмлекләр арасындагы хәбәрлек функциясендәге сүзләр дип билгели һәм аларның аерым сүз төркемен тәшкил итә алуларына беренчеләрдән булып игътибар итә. Мондый сүзләрнең синтаксик һәм морфологик үзенчәлекләрен күрсәтеп, ул болай дип яза: «Болар үзләре аерым торганда да хәбәр була алалар һәм өстәмәләр белән төрләнә алалар. Боларны үзенә бер төркем “хәбәрлек сүзләр” дип атап аерырга ярый» [1: 232]. Дөрес, хәбәрлек сүзләргә караган аерым мисалларны К. Насыйриның «Әнмүзәҗ» (1895) грамматикасында да очратабыз. Алга таба хәбәрлек сүзләр Җ. Вәлидинең игътибарын җәлеп итәләр. Ул аларны исем фигыль дип атый, «вак сүзләр»нең бер төркеменә кертә.

Н.К. Дмитриев «Башкорт теленең грамматикасы» (Уфа, 1950) дигән саллы хезмәтендә кисәкчәләргә мөнәсәбәтле рәвештә модаль сүзләрне аерым бер лексик-грамматик разряд итеп билгели: «Модаль сүзләр аерым бер сүз белән кисәкчә арасында урта бер урын алып тора. Функцияләре белән алар – кисәкчәләр, ә үзләренең фонетика һәм этимологияләре белән аерым сүзләр. Шуңа күрә аларны аерым бер төркемгә кертергә туры килә. Модаль сүзләргә без түбәндәгеләрне кертәбез: 1) *бар* (русча: есть, имеется), 2) *юк* (русча: нет, не имеется). 3) *түгел* (не есть = ist nicht) 4) *кирәк* (надо) һәм *тиеш* (должно), 5) *икән* (оказывается), 6) *бугай* (должно быть)» [2: 133]. Галим саф модаль сүзләр рәтенә хәбәрлек сүзләрне дә (*бар, юк, кирәк, тиеш*) керткән. Күрәсең, ул әлеге сүзләрнең семантик ягына гына игътибар иткән.

«Татар теле грамматикасы» (Казан, 1959) хезмәтендә В.Н. Хангилдин югарыда китерелгән сүзләрне «хәбәрлек сүзләр» дип атый һәм аларның функциональ яктан фигыльгә якынлыкларын билгели.

«Хәзерге татар әдәби теле» (Казан, 1965) дигән коллектив хезмәттә хәбәрлек сүзләр «Мөнәсәбәтлек (модаль сүз)» бүлегендә мөнәсәбәтлекләр (модаль сүзләр) составында «хәбәрлек сүз булып килүче мөнәсәбәтлекләр», ягъни модаль сүзләр буларак карала. Модаль сүзләр (мөнәсәбәтлекләр) мәгънә үзенчәлекләре буенча модаль кисәкчәләргә туры килә. Кисәкчәләр мөстәкыйль сүзнең нинди дә булса бер кисәге (аффикс яки префикс) булсалар, модаль сүз (мөнәсәбәтлек) – чагыштырмача бер бөтен сүз. Кисәкчә аерым сүзгә генә караган булса, модаль сүз (мөнәсәбәтлек) җөмләгә тулаем карый, шул җөмләнең хәбәрен төзүдә катнаша яки шул җөмләнең структурасында кереш сүз булып килә. Җөмләдәге функцияләреннән чыгып, модаль сүзләр ике төркемгә бүленәләр: хәбәрлек сүз булып килүче модаль сүзләр һәм кереш сүз булып килүче модаль сүзләр [6: 272]. Бу хезмәттә хәбәрлек сүз булып килүче модаль сүзләргә түбәндәгеләр кертелгән: *бар, юк, тиеш, кирәк, мөмкин, ярый, икән, бугай, инде, соң*.

Д.Г. Тумашева «Хәзерге татар әдәби теле» (Казан, 1978) хезмәтендә хәбәрлек сүзләрне аерым сүз төркеме буларак танымый, аларны ул хәбәр составында йөреп, сөйләмнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен объектив рәвештә белдерә торган модаль сүзләр дип исәпли һәм аларның составын *бар,юк, тиеш, кирәк, мөмкин, ярый, ярар, ихтимал, имеш, икән* сүзләре тәшкил итүен билгели [4: 210].

Ф.М. Хисамованың югары уку йортлары өчен төзелгән «Татар теле морфологиясе» дәреслегендә дә (Казан, 2006) шулай ук хәбәрлек сүзләр, Д.Г. Тумашева карашы нигезендә, хәбәр составында йөреп, сөйләмнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен объектив рәвештә белдерүче сүзләр дип каралалар [7: 58, 317]. Дәреслек авторы *бар, юк, кирәк, тиеш* кебек сүзләрнең хәбәрлек сүзләр дигән аерым сүз төркеме эчендә каралырга тиешле булуның объектив нигезе юк дип исәпли. Ул хәбәрлек сүзләрнең дә һәм модаль сүзләрнең дә семантик яктан уртаклык күрсәтүләрен – модаль мәгънә белдерүләрен генә нигез итеп ала һәм түбәндәге нәтиҗәгә килә: «Хәбәрлек сүзләр дип модаль сүзләрдән аерылган *кирәк. тиеш, мөмкин, ярый* сүзләренә игътибар итсәк, семантик яктан

аларны бары тик кирәклек, тиешлек, мөмкинлекне белдерә торган сүзләр дип кенә бәяли алабыз» [7: 319]. Галимә фикеренчә, бер үк грамматик күренешне төрлечә бәяләүнең объектив сәбәпләре дә бар. Сәбәпләрнең беренчесе итеп ул модальлек категориясенең, модаль сүзләрнең грамматик хезмәтләрдә чагыштырмача соңрак өйрәнелә, тикшерелә башлануны, төрле телләрдә бу тел күренешен аңлатуда хәзергә кадәр фикер башкалыклары булуын күрсәтә. Икенче сәбәпне шәрехләп, автор болай дип яза: «...бу ике төр модаль сүзләр үзләренең грамматик табигате, бигрәк тә синтаксик функцияләре белән, чыннан да, бер-берсеннән шактый нык аерылалар. Беренче төр модаль сүзләр: *бар, юк, тиеш, кирәк* һ.б. җөмләдә күбрәк мөстәкыйль рәвештә хәбәр булып яки кушма хәбәр составында киләләр һәм предметларның яки күренешләрнең булуын (барлыгын) яки юклыгын, кирәклеген, булырга тиешлеген һ.б. объектив рәвештә хәбәр итәләр» [7: 318].

Әлеге аңлатмада хәбәрлек сүзләрнең лексик-грамматик һәм синтаксик билгеләре тәгаен күрсәтелгән. Бу сүз төркемендәге сүзләрнең үзенә генә хас булган лексик мәгънәсе бар. Бу аеруча сөйләмдә аларның мөстәкыйль рәвештә хәбәр функциясен башкаруларында чагылыш таба. Мәсәлән: ***Бар иде*** *бездә Сафый атлы кеше.* (Г. Тукай) *Уйлану* ***бар****, сизенү* ***бар****, ә чын дөресен генә белү* ***юк иде****.* (Ә. Еники) *Әртил* ***кирәк****, колхоз, каммун* ***кирәк*** *диген.* (Г. Ибраһимов) *Башкача* ***мөмкин түгел****.* (Ә. Еники) һ.б. Мисаллардан күренүенчә, *бар* сүзе нәрсәнең дә булса реаль барлыгы турында, ә *юк* сүзе нәрсәнең дә булса реаль юклыгын хәбәр итә (предикацияли). Хәбәрлек сүзләр, фигыльләр кебек, эшне-хәлне белдермиләр, ә предмет, күренеш, билгенең вакытка, хәрәкәткә бәйсез булган торышын хәбәр итәләр.

Хәбәрлек сүзләрнең үзаллы һәм мөстәкыйль сүз төркемен тәшкил итүләре аларның диалогик сөйләмдәге җавап репликаларында ким җөмләләр яки сүз-җөмләләр булып килә алуларында да дәлилләнә. Мәсәлән:

*– Калач бармы? – дип сорады Сәмигулла.*

*–* ***Бар****, – диде сатучы.* (С. Рафиков)

яки

*– Винтовкалар бармы?*

*–* ***Юк****.*

*–* ***Бар*** *бит. Барлыгын беләбез.*

*– Санитарларга ул.*

*– Ничек инде ул! Санитарларга* ***бар****, ә безгә* ***юк****!?*

*– Яралыларга* ***юк****.* (А. Шамов)

яки

*– Бер нәрсә дә ишетә алмадыгызмы?*

*–* ***Юк****.* (Г. Ибраһимов)

яки

*– Шаярасың?*

*–* ***Юк****.* (К. Нәҗми)

Хәбәрлек сүзләр җөмләдә төп предикацияләү (нәрсә турында булса да хәбәр итү) чарасы булганлыктан, мөстәкыйль сүз төркеменә карый. *Бар* һәм *юк* сүзләре, төрле килеш формаларын алып, синтетик иярчен җөмләдә хәбәр булып килә: *Уе **юкның** теле юк; теле **юкның** иле юк.* (Н. Арсланов) Мондый сүзләрнең кайберләре, мәсәлән *кирәк*сүзе, хикәяләү һәм шарт наклонениеләрендә зат һәм сан белән төрләнә, хикәяләү наклонениесендә исә өч төрле заман формаларында кулланыла ала. *Кирәк* һәм *тиеш* сүзләренең хикәяләү һәм шарт наклонениеләрендә зат-сан белән төрләнүләре *бул* һәм *иде* ярдәмче фигыльләре аша да белдерелә ала.

Хәбәрлек сүзләрнең кайберләре морфологик яктан төрле формаларда килә ала: барлыкта-юклыкта (*кирәк–кирәкми, ярый – ярамый*), заманнарда (*кирәк – кирәкте – кирәгәячәк – кирәгер*), шарт фигыль формасында (*кирәксә – кирәкмәсә*). Хәбәрлек сүзләрнең кайберләренә килеш һәм тартым кушымчалары ялгана ала, шуңа бәйле рәвештә алар җөмләнең төрле грамматик кисәкләре булып килә ала. Мәсәлән: *Менмәмен мин, ходай кушса, мич башына, шигырьләрдән килер миңа **кирәк** җылы.* (Г. Тукай) ***Юктан** бар яхшы.* (Мәкаль) һ.б.

Ч.М. Харисова хәбәрлек сүзләрне үзаллы аерым сүз төркеме буларак тикшерә һәм «...алар мөстәкыйль һәм модаль сүз төркемнәре арасында тора дип әйтү дөресрәк булыр» дигән фикергә килә [5: 104]. Аның бу карашы хәбәрлек сүзләрнең чынбарлыктагы предмет, күренеш һәм төшенчәләргә нинди дә булса мөнәсәбәтне белдерү үзенчәлекләренә, ягъни модаль мәгънә белдерә алу үзлекләренә нигезләнә.

Хәбәрлек сүзләрнең бер өлеше генә җөмләдә тиешлек, кирәклек, мөмкинлек, рөхсәт итү кебек модаль мәгънәләрне белдерә ала. Әмма алар грамматик билгеләре буенча предикатив (хәбәрлекле) сүзләр төркеменә карыйлар.

Хәбәрлек сүзләрнең составы югарыдагы сүзләр белән генә чикләнми. Түбәндәге сүзләр, билгеле бер мәгънәгә ия булып, лексик-грамматик һәм синтаксик билгеләре белән хәбәрлек сүзләр буларак характерлана алалар һәм мөстәкыйль сүз төркеме буларак тикшерелергә тиешләр.

*Бәхил.* Гафу итү, кичерү, ризалашуны аңлата. *Сау бул инде, хуш, **бәхил бул**, и минем туган җирем.* (Г. Тукай) *Шул вакыйганы янәдән тәфсилләп язмасаң, һич тә **бәхил түгел**.* (Ш. Камал)

*Риза (Разый).* Риза-канәгать булу, карышмау. *Гөлшаһидә Акъярыннан **риза иде**. Халык шуңа да **риза.*** (Г. Гобәй) *Мин иң авыр җәзаларны да күтәрергә **риза**.* (Ә. Айдар) *Гали (Зөләйхага):Үзеңне миңа бирергә атаң-анаң разый вакытта да син минем белән качарга **разый идең**.* (Г. Коләхмәтов)

*Там* (иск.) Тулы, камил көчендә. *Өмет зур, ниятем **там.*** (Ш. Бабич)

*Таман.* Зурлыгы, күләме яки башка үлчәме буенча кирәгенчә, тиешле чамада. *Акылым-буем **таман**, тик бәхетем яман.* (Мәкаль) *Итекләр өченче берәүнең аягына **таман** булып чыкты.* (Ә. Исхак)

*Таң*. 1. Кадерле, кирәкле. *Калган күлгә – бака хан, бай хатынына – ялчы **таң**.* (Мәкаль) 2. Гаҗәп күркәм, искиткеч матур. *Таң **таң ата**, чулпан калка, Чулпан таңны уята.* (Җыр)

Бу хәбәрлек сүз белән фразеологик әйтелмә дә телебездә барлыкка килгән: *таң калу (булу), таңга калу*. Ул да ике мәгънәдә кулланыла: 1. Бик нык гаҗәпләнү; сокланып гаҗәпләнү. ***Таң калам** мин тавышыңа, нинди тылсымлы тавыш!* (Ш. Бабич) 2. Аптырау, хәйран булу. *Хәзер уйлап карыйм да бөтенләй **таңга калам**: чыдаса да чыдый икән адәм баласы!* (И. Гази)

*Тартым*. Билгеле бер нәрсәгә (кешегә) охшашлы, шуны хәтерләтә торган. *Картым – убырга **тартым***. (Әйтем) *Итләч озын борыны, озын кара мыегы, яшьләй агарган каты чәче белән ул [Шәмсетдин] көньяк халкына **тартым кебек.*** (Г. Бәширов)

*Тансык*. Теләп, сагынылган, көтеп алынган. *Кояш, чык, чык, чык! Синең җылың бик* **тансык**. (Такмак) Бөтенесе дә аңа **тансык**. (Сөйл.)

*Тарханда*. Эштән һ.б. азат, ирекле, буш. *Ат яхшысы – арканда, начарлары – **тарханда.*** (Мәкаль)

*Тәмам*. (Берәр эш) соңына, ахырына, ахыр чиккә җитү, төгәлләнү, бетү турында. *Инде хәзер чыпчыкның да гомере **тәмам***. (Г. Тукай) Хәзер сугыш беткәч, эш ***тәмам***. (Р. Ишморат)

*Үтүт*. Берәр нәрсәнең була алмый яки кемгә дә булса эләкми калуын белдерә. *[Әхмәт:] Ул егет, канатлы айгырына атланып, айга очып менмәкче була. Айдагы кызны алып төшмәкче булып йөри. [Шәйхулла:] Зөһрә кыз **үтүт** инде. Хәзер ул Шәйхулла байның сараенда чикләвек ярып утыра.* (Д. Аппакова)

*Хуп*. Нинди дә булса эшкә яки сүзгә карата ризалыкны, канәгатьләндерүне белдереп әйтелә: яхшы, ярый. *Вакытында җыеп, вакытында задание тапшыра алсак, бик **хуп**, инде булдыра алмасак, "Чулпан"ның янә базары төшәчәк.* (Г. Бәширов)

*Хөрт (Хөрти)*. Начар, рәтсез. *[Хәйрүш:] Кем килә? Җавап бир! Бер ... югыйсә... Эшең **хөрт** булыр*. (А. Алиш) – *Менә шул шул, − диде солдат, аны моңзар аңлаучыга санап. – Кояш баю белән минем хәл дә, әйтергә мөмкин, бик **хөрти.*** (К. Нәҗми)

*Ярыйсы*. Яхшы ук булмаса да канәгатьләндерерлек, уртача (азмы-күпме ярарлык). – *Бу инде, Нургали абый, **ярыйсы гына түгел**, бу минемчә, бик яхшы.* (Ә. Еники) – *Хәлем **ярыйсы**, тик менә эч пошуга түзәр хәлюк.* (Ә. Фәйзи)

Шулай итеп, хәбәрлек сүзләр реаль мәгънәле сүз төркемнәре арасында тора. Алар билгеле бер лексик мәгънәгә ияләр, морфологик яктан алар килеш, тартым, зат-сан , заман һәм юклык кушымчалары алып формалаша, синтаксик яктан үзләре генә дә хәбәр, шулай ук төрле җөмлә кисәкләре булып та килә алалар. Бу лексик-грамматик билгеләр аларны саф модаль сүзләрдән аерып торалар. Шуның белән бергә, хәбәрлек сүзләрнең кайберләре сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен объектив рәвештә белдереп тә килә алалар. Бу исә аларның лексик-грамматик табигатенең синкретлы булуы белән билгеләнә.

**Әдәбият**

Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр. – Казан: Мәгариф, 2008. – 287 б.

Дмитриев Н.К. Башкорт теленең грамматикасы. – Уфа: Башгосиздат, 1950. – 300 б. (башкорт телендә)

Татар грамматикасы. – Т.II. – М.: «Инсан», Казан: «Фикер», − 2002. – 448 б.

Тумашева, Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: КДУ нәшр., 1978. – 222 б.

Харисова Ч.М. Татар теле. Морфология: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2010. – 128 б.

Хәзерге татар әдәби теле. – Казан, 1965. – 300 б.

Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.

*Хәйруллина Әлфирә Сәлихҗан кызы*
Казан федераль университеты
Алабуга, Россия
*Hajrullina Alfira Salihzyanovna*
Kazan F ederal University
Elabuga

## Л. ҖӘЛӘЙНЕҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ ИҖАТЫ (КЫСКАЧА КҮЗӘТҮ)
## A BRIEF OVERVIEW OF THE LIFE AND WORK OF L. ZALAYA

Аннотация. *В статье дается краткий обзор жизни и творчества известного педагога, профессора, критика Л. Заляя. Дается подробное описание о его трудах, таких как «Вопросы изучения диалектологии татарского языка» (1940), «Диалектология татарского языка» (1947), «Диалектологический словарь» (1948) и другие. Также приводятся отзывы его учеников.*

Abstract. *The article discusses a brief overview of the life and work of a famous teacher, Professor, critic L. Zalaya. Provides a detailed description of his works such as «The study of dialectology of the Tatar language» (1940), «Dialectology of the Tatar language» (1947), «Dialectological dictionary» (1948) and others. Alsoprovidesreviewsofhisstudents.*

Ключевые слова: *языкознание, образование, педагог, наставник, родной язык, критик.*

Keywords: *linguistics, education, teacher, mentor, native language, critic.*

Татар тел белеменә зур өлеш керткән күренекле галим, тәнкыйтьче һәм педагог профессор Җәләлетдин улы Җәләлетдинов 1894 елның 17 ноябрендә Самара губернасы Мәләкәс өязе, Иске Кызылсу авылында туа. Аның балачагы шунда үтә. Мәхәллә мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1906 елда Мәләкәс мәдрәсәсенә укырга керә. 13 яшендә әлеге шәһәрдә сезонлы эшчебулып эшли. Үзенең чиксез тырышлыгы аркасында заманына күрә ярыйсы гына төпле белем ала һәм 1912 елда Иске Фәйзулла авылы мәдрәсәсендә укытучы булып эшли башлый. Дөнья күрү теләге белән, 1914 елның башында ул Урта Азиягә китә. 1915-1917 елларда солдат хезмәтләрендә була, Беренче Бөтендөнья сугышында катнаша.

1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң Л. Җәләйгә белемен күтәрү һәм яраткан укытучылык хезмәтен дәвам иттерү өчен мөмкинлекләр ачыла. Туган авылындагы мәктәптә өч ел эшләгәч, 1921 елда аны Самара шәһәрендәге педагогия техникумына татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп күчерәләр. 1924-1925 елларда ул шул ук Самарада ятим балалар йортында мөдир булып эшли. 1925-1928 елларда Самара шәһәре мәгариф бүлегендә инспектор хезмәтен башкара. 1928 елдан алып 1932 елга кадәр Кузнецк, Мәләкәс һәм Самара шәһәрләрендәге партия мәктәпләрендә татар телен һәм әдәбиятын укыта.

Шушы чорда Л. Җәләйнең әдәби һәм гыйльми иҗат эшчәнлеге башлана. 1929 елны Самарада аның атеистик тәрбия мәсьәләләренә багышланган беренче кулланмасы басыла. Аннан соң «Туган тел» (1930), «Уку китабы» (1933) кебек дәреслекләре дөнья күрә.

1932 елда Л. Җәләй Самара авыл хуҗалыгы институты каршындагы аспирантурага керә, 1933 елда анда татар теле буенча аспирантура ябылгач, Казанга күчеп, укуын Казан педагогия институты аспирантурасында дәвам итә. 1935 елда аны тәмамлаганнан соң, 1939 елга кадәр шул ук институтның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә тел тарихы, тарихи грамматика һәм татар диалектологиясе фәннәрен укыта.

1939 елда Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты ачылгач, Л. Җәләйне анда тел секторы мөдире итеп билгелиләр.

1944 елда Л. Җәләй яңадан Казан педагогия институтына кайтып укыта башлый һәм шул ук елны, Казан дәүләт университетында татар филологиясе бүлеге ачылгач, анда да кайбер курслар буенча лекцияләр алып бара.

1946 елда Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих фәнни тикшеренү институты СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалына кергәч, Л. Җәләй бу филиалга күчә һәм лаеклы ялга чыкканчы (1962 елның апреленә кадәр), башта өлкән фәнни хезмәткәр, 1956 елдан тел секторы мөдире булып эшли. «Татар теленең урта диалекты» исемле хезмәте өчен ул 1954 елда филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була, 1958 елда профессор исемен ала.

Л. Җәләй озак еллар буе уку йортларында, фәнни оешмаларда эшләү дәверендә йөзләрчә яшь кадрлар тәрбияләп үстерә. Аның турыдан-туры җитәкчелеге астында гына да ике дистәгә якын яшь белгеч кандидатлык диссертациясе яклый. Алар арасында Мирфатих Зәкиев, Нәҗия Борһанова,Вахит Хаков, Галимҗан Ахунҗанов, Фоат Ганиев һ.б. галимнәр бар.

Ф.Ә. Ганиев аның турында болай дип яза: «Л. Җәләй һәрвакыт студентлар, яшь белгечләр арасында булды. Алардан бик күп фәнни хезмәткәрләр, галимнәр җитештерде, Казан дәүләт университетында, СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалында аның һәрвакыт аспирантлары булды. Ул яшь галимнәрне үстерү өчен бөтен көчен бирде» [Ганиев, 1969: 181].

В.Х. Хаков: «Аның шәкерте һәм эшен дәвам иттерүче буларак, мин ага Җәләйнең исемен һәрвакыт зур хөрмәт һәм горурлык белән искә алам. Бу исем фәнгә бирелгәнлекнең, шуңа тырышып хезмәт итүнең бер чагылышы, гүзәл

үрнәге һәм символы булып тора», – ди аның турында [Хаков, 1994: 62]. «Ул безгә, барыннан да элек, күренекле тел галиме, әдәби тәнкыйтьче,олы остаз, киң күңелле иптәш, эчкерсез киңәшче буларак билгеле. Л. Җәләй –татар тел белеме өлкәсендә фәннәр докторы дигән югары дәрәҗә алган беренче галим», – дигән фикерне әйтә М.З. Зәкиев [Зәкиев, 1964: 139].

Г.Ф. Саттаров аны олылап, хөрмәт итеп: «Фикерләргә бай Җәләй – шәкертләргә җай Җәләй иде ул», – дип искә ала [Саттаров, 1994: 73].

Л. Җәләй гомере буена татар халкының сөйләм телен өйрәнә, сөйләм телен әдәби телнең төп чыганагы һәм байлыгы дип бәяли. Ул татар тел белеменең диалектология тармагын өйрәнүгә һәм тикшерүгә аеруча зур урын бирә. Аның күпсанлы мәкаләләре һәм китаплары шуны күрсәтә. Мәсәлән: «Татар теле диалектлары» (Совет мәктәбе, 1938, № 5, 6, 8); «Телнең диалектларын өйрәнү буенча кыскача программа» (Совет мәктәбе, 1940, № 3); «Татар теле диалектларын өйрәнү буенча сораулыклар» (Казан, 1940); «Татар теленең диалектларын өйрәнү» (Кызыл Татарстан, 1949, 26 июнь); «Татар диалектологиясе» (Казан, 1947); «Диалектологик сүзлек» (Казан, 1948); «Татар теле диалектларын өйрәнү буенча сораулыклар» (Казан, 1949); «Диалектолог блокноты» (Казан, 1950); «Укучылар телендә диалектизмнар һәм аларга каршы көрәш» (Татар телен укыту мәсьәләләре буенча фәнни-практик конференция материаллары, Казан, 1953); «Татар теленең урта диалекты» (1954) һ.б. Үзенең гаять әчтәлекле «Татар тел белеме алдында бурычлар» (Совет Татарстаны, 1956, 2 октябрь) исемле мәкаләсендә Л. Җәләй татар теленең диалектологик атласын, тулы диалектологик һәм тулы аңлатмалы сүзлекләрен төзүнең кирәклеген, бу проблемаларның көн тәртибенә басканлыгын күрсәтә.

Ярты гасырлык иҗат дәверендә галим тел белеменең аз өйрәнелгән тармакларын тикшерүгә, бәхәсле мәсьәләләрен хәл итүгә зур өлеш кертә. М.Ә. Сәгыйтов һәм Р.Ә. Шакирҗановлар Л. Җәләй турында: «Татар теленең орфоэпик нигезләре» хезмәтендә әдәби әйтелеш нормаларын татар тел белеме тарихында беренче булып конкрет системага сала һәм шулар белән татар филологиясендә киң колачлы галим буларак тирән эз калдыра», – дип язалар [Латиф Җәләйнең иҗат юлы 2001: 28]. «Телебезнең орфоэпик нигезләре Җәләйнең иҗат юлы» (Татарстан яшьләре, 1940, 15 декабрь), «Чишелә алмый яткан әһәмиятле мәсьәлә (татар теленең орфографиясе хакында)» (Совет Татарстаны, 1957, 29 ноябрь) кебек мәкаләләрендә һәм «Татар теленең орфоэпик нигезләре» (1953) хезмәтендә татар теленең орфоэпик һәм орфографик системасы бирелә, нормалары ачыклана.

«Профессор Л. Җәләй татар теленең тарихи грамматикасын өйрәнү өлкәсендә зур эшчәнлек күрсәтте. Татар тел белеменең бу тармагы буенча аерым китап һәм бик күп мәкаләләр бастырып чыгарды» [Ганиев,1969 : 180], – ди Ф.Ә. Ганиев үзенең бер хезмәтендә. Галим Ә. Ахунҗанов белән берлектә язган «Татар милли әдәби теле туу мәсьәләсенә карата» (Совет әдәбияты, 1956, № 2) дигән мәкаләсендә

татар әдәби теленең барлыкка килү һәм формалашуы процессын яктырта. Л. Җәләйнең әдәби тел тарихына караган бик күп материаллары архивта саклана.

Ул – матур әдәбиятта әдәби осталык мәсьәләләрен күтәреп чыккан принципиаль карашлы, нечкә зәвыклы тәнкыйтьче дә. Бу өлкәдә аның алтмыштан артык мәкаләсе, рецензияләре бар. Алар арасында «Тукай телендә фигыльләр» (Совет әдәбияты, 1938, № 3, 4, 5), «Татар телен баетуда Тукайның роле» (За педагогические кадры, 1938, № 914), «Татар әдәби телен баетуда Ш. Камалның роле» (Совет әдәбияты, 1940, № 1, 2), «Совет чоры татар матур әдәбияты теленә бер күзәтү» (Совет әдәбияты, 1951, № 10), «Г. Тукай поэзиясенең кайбер синтаксик үзенчәлекләре» (Совет әдәбияты, 1954, № 5), «Язучылар телен өйрәнү принциплары» (Совет әдәбияты, 1960, № 10) кебек матур әдәбиятның тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнүгә багышланган теоретик характердагы мәкаләләре белән беррәттән, М. Әмир («Миңлекамал» // Кызыл Татарстан, 1944, 14 май), С. Хәким («Шагыйрь С. Хәким поэзиясенә обзор» // Совет әдәбияты, 1947, № 1), И. Максуд («Күгәрчен» // Кызыл Татарстан, 1944, 12декабрь), М. Ногман («Давыллы еллар мирасы» // Кызыл Татарстан, 1944, 10 октябрь), А. Расих («А. Расихның бер хикәясе турында» // Совет әдәбияты, 1944, № 3), Ә. Юныс (Әсән елга // Кызыл Татарстан, 1941, 2 декабрь), Г. Бәширов (Үч // Кызыл Татарстан, 1943, 9 июнь; Сиваш // Совет әдәбияты, 1938, № 6) һәм башка язучыларның иҗатын яки аерым әсәрләрен анализлаган тәнкыйть хезмәтләре билгеле.

Л. Җәләй диалектологик, фразеологик, терминологик сүзлекләр төзүдә дә катнаша. «Сүзлекләр төзү юлында безгә нәрсә һәм ничек эшләргә?» (Совет Татарстаны, 1951, 2 октябрь) дигән мәкаләсендә ул болай дип яза: «Хәзер татар әдәби теленең сүзлек хәзинәсен төгәл барлау һәм аны тормыш таләпләренә җавап бирерлек итеп фәнни эшкәртелешкә кертү өчен, бүгеннән аның түбәндәге сүзлекләре төзелергә тиешләр: а) тулы аңлатмалы сүзлек; б) русча-татарча сүзлек; в) татарча-русча сүзлек; г) фразеологик сүзлек; д) синонимик сүзлек; е) этимологик сүзлек; ж) орфографик һәм орфоэпик сүзлекләр». Галим өч кисәктән торган «Диалектологик сүзлек» (1948, 1953, 1958) чыгаруда зур хезмәт куя. Сүзлекнең беренче чыгарылышында ул төзүче, II-III кисәкләрендә редактор буларак катнаша. 1957 елда татар теленең фразеологик берәмлекләре, мәкаль һәм әйтемнәре тупланган хезмәте дөнья күрә [Җәләй, 1959].

Л. Җәләй – мәктәпләр өчен төзелгән дәреслекләр, фәнни-методик кулланмалар, уку-укыту әсбаплары авторы да. «Туган тел» (1930), «Уку китабы» (1933-34), «Систематик диктантлар җыентыгы» (1941), «Тыныш билгеләре буенча күнегүләр» (1941), 8 нче класслар өчен «Әдәбият буенча дәреслек-хрестоматия» (1940), 8 нче класс өчен «Әдәбият дәреслеге» (1945-47) дигән китаплар һәм кулланмалар бастырып чыгара.

Л. Җәләй үзенә кадәр тел өлкәсендә эшләүче галимнәрнең хезмәтләрен өйрәнә, аларны анализлый. Мәсәлән, «Гыймад Нугайбәк» (Совет әдәбияты, 1941, № 8), «Татарларда мәгърифәтчелек һәм Каюм Насыйри» (Совет әдәбияты, 1945, № 2), «Каюм Насыйри» (Совет Татарстаны, 1945, 8 декабрь), «Татарның бөек

галиме К. Насыйри» (Совет Татарстаны, 1945, 17 декабрь), «Күренекле татар галиме — телче» (Кызыл таң, 1959, 31 март). Әлеге мәкаләләре аңа кадәр тел өлкәсендә эшләгән олуг галимнәргә «мәдхия» булып тора.

Ә бит җәмәгатьчелектә ул киң эрудицияле тел галиме буларак кына түгел, бәлки әдәбият белгече, әдәби матур әдәбиятта әдәби осталык мәсьәләләрен күтәреп чыккан принципиаль карашлы, нечкә зәвыклы тәнкыйтьче буларак та билгеле. Аның әдәби мирасны өйрәнү, төрле язучыларның әсәрләрен тикшерүгә багышланган алтмыштан артыкҗитди мәкаләсе, рецензияләре бар. Алар арасында «Тукай телендә фигыльләр» (Совет әдәбияты, 1938, № 3, 4, 5), «Татар телен баетуда Тукайның роле» (За педагогические кадры, 1938, № 914), «Татар әдәби телен баетуда Ш. Камалның роле» (Совет әдәбияты, 1940, № 1, 2),һ.б.

Л. Җәләйнең үзенең киң колачлы фәнни-тикшеренү эшләрен һәрвакыт практика белән тыгыз бәйләп баруы күренә. Аның диалектология, тел тарихы өлкәсенә караган күп кенә фәнни хезмәтләре моның ачык дәлиле булып тора.

Ярты гасырлык иҗат дәверендә галим тел белеменең аз өйрәнелгән тармакларын тикшерүгә, бәхәсле мәсьәләләрен хәл итүгә зур өлеш кертә:диалектологик, фразеологик, терминологик сүзлекләр төзүдә дә катнаша, шулай ук мәктәпләр өчен төзелгән дәреслекләр, фәнни-методик кулланмалар, уку-укыту әсбаплары авторы да. «Туган тел» (1930), «Уку китабы» (1933-34), «Систематик диктантлар җыентыгы» (1941), «Тыныш билгеләре буенча күнегүләр» (1941), 8 нче класслар өчен «Әдәбият буенча дәреслек-хрестоматия» (1940), 8 нче класс өчен «Әдәбият дәреслеге» (1945-47) дигән китаплар һәм кулланмалар бастырып чыгара.

Л. Җәләй үзенә кадәр тел өлкәсендә эшләүче галимнәрнең хезмәтләрен өйрәнә, аларны анализлый. Мәсәлән, «Гыймад Нугайбәк» (Совет әдәбияты, 1941, № 8), «Татарларда мәгърифәтчелек һәм Каюм Насыйри» (Совет әдәбияты, 1945, № 2), «Каюм Насыйри» (Совет Татарстаны, 1945, 8 декабрь), «Татарның бөек галиме К. Насыйри» (Совет Татарстаны, 1945, 17 декабрь), «Күренекле татар галиме – телче» (Кызыл таң, 1959, 31 март). Әлеге мәкаләләре аңа кадәр тел өлкәсендә эшләгән олуг галимнәргә «мәдхия» булып тора. Стилистика өлкәсендә калдырган мирасы – телне өйрәнүче галимнәр өчен якты үрнәк.

Әмма шундый дәрәҗәдә зур мирас калдырган галим Л. Җәләйнең үзенең эшчәнлеге бүгенге көнгә кадәр тел галимнәре тарафыннан тиешенчә тикшерелмәгән. Өйрәнелгәннәре дә аерым-аерым өлкәләрдәге хезмәтләрен яктырткан мәкаләләрдән генә гыйбарәт.

Фән үсә, алга бара, яңа проблемалар туа. Әмма олуг галим Л. Җәләйнең хезмәтләре бүген дә игътибар үзәгендә тора, актуальлеген югалтмый. Аның татар тел белеменә, тюркологиягә караган зур мирасы архивларда саклана.

**Литература**

1. Ганиев Ф. А. Татар филологиясенә зур өлеш керткән галим // Казан утлары. – 1969. – № 11 – 192 б.

2. Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986 (Файдаланылды һәмберкадәр үзгәрешләр кертелде).

3. Зәкиев М. 3. Күренекле галим // Казан утлары. – 1964. – № 12. – 192 б.

4. Саттаров Г. Ф. Туган телне яратып // Татарстан хәбәрләре,1994. – 18 ноябрь.

5. Саттаров Г. Ф. Фикерләргә бай Җәләй - шәкертләргә җай Җәләй // Мәгърифәт, 1994. – 12 ноябрь

6. Хаков В. Х. Яшәү һәм хезмәт үрнәге // Казан утлары, 1964, № 12; 1984. – № 12 – 192 б.

*Хәмидуллина Айгөл Альбертовна*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Khamidullina Aigul Al'bertovna*
Kazan, Russia

## ТАТАР ТЕЛЕ ФОНЕТИКАСЫН ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫНА КҮЗӘТҮ
## REVIEW OF THE HISTORY OF STUDYING THE PHONETICS OF THE TATAR LANGUAGE

Аннотация. *В данной статье рассмотрена история изучения фонетики татарского языка в разных аспектах. Рассмотрены и проанализированы труды ученых-тюркологов. Статья будет полезна и интересна студентам, магистрантам тем, что в одном тексте представлены все труды ученых-тюркологов, изучавших фонетическую систему татарского языка.*

Abstract. *This article describes the history of studying the phonetics of the Tatar language in different aspects. The works of scientists-turkologists are considered and analyzed. The article will be useful for students, undergraduates because all the works of scientists-turkologists who studied the phonetic system of the Tatar language are presented in one text.*

Ключевые слова. *Фонетика, аваз, грамматика.*

Keywords. *Phonetics, sound, grammar.*

Татар фонетикасы буенча иң беренче фәнни мәгълүматлар К. Насыйриның «Кыскача татар нәхүе», «Татарча вә урысча үгрәнүчеләргә файдасыгам булсын өчен» (1860) китабында күренәләр. Бу китапта татар хәрефләрен (ул да әлегә «аваз» терминын кулланмый) сузыкларга һәм тартыкларга аера. Авазларны сыйфатлап тормыйча, ул сөйләм телендәге кайбер аваз үзгәрешләрен билгеләп үтә. Аның бу китабында, беренчеләрдән булып, басым хакында да мәгълүмат бирелә. Тамыр сүзләрдә ике иҗекле һәм күп иҗекле сүзләрдә басымның һәрвакыт кушымчага (ягъни сүз ахырында) төшмәвенә д әигътибар итә.

В.В. Радловның «Төньяк төрки телләр фонетикасы» (1883) төрки аваз төзелешен чагыштырып өйрәнү өлкәсендә зур әһәмияткә ия була. Галим, әдәби тел кысалары белән генә чикләнмичә, диалектлардагы авазларны да катыштырганлыктан ахырда күрсәтелгән [а], [ә] сузыкларын, алар вариант кына булсалар да мөстәкыйль фонема дип таный булса кирәк. Шул УК вакытта телдәге

[ы] фонемасының алынмавы күренә. Тартык авазларга килгәндә ул татар телендә 23 тартыкны санап чыга. Ләкин [ң] борын тартыгын искә алмый, ә [л] ның ике вариантын мөстәкыйль аваз буларак күрсәтә.

Җ. Вәлиди исә үзенең «Татар теленең грамматикасы» (1919) исемле хезмәтендә татар телендә барысы 53 аваз, шуның 10 сы сузык, 43 е тартык аваз булуын яза. Хәреф белән авазны бутамаска куша. Хәрефләр фонетика таләпләрен үтәүдән ерак торалар, ди. Әлеге хезмәт бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмый, моңа мисал булып хезмәтнең 2007 дә янәдән басылып чыгуы тора.

Моңарчы чыккан грамматика китаплары беренче нәүбәттә дәрес китаплары буларак дөнья күргәннәр, аларда теге яки бу мәсьәләне фәнни тикшерү максат итеп куелмаганда. Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) исемле хезмәте татар авазларын чын фәнни нигездә тасвирлап бирүче хезмәт булып тора.

Татар теле фонетикасына зур әһәмият биргән галим – профессор В.А. Богородицкий. Аның «Татар тел белеменә кереш» (1953) исемле хезмәтендә татар теленең вокализмы (сузыкавазлары) һәм консонантизмы (тартыкавазлар) мәсьәләләре карала. Шул ук хезмәтнең 32 нче битендә татар теленең фонетикасы эксперементаль яктан чыгып тикшерелә.

Профессор В.А. Богородицкий татар телендәге һәм башка төрек телләрендәге сузыкларга чагыштырма характеристика бирә, ул сузыклар өлкәсендә татар теленең башка телләрдән аерылып торганын билгели. Тартыклар бүлегендә автор башка төрки телләрендәге һәм татар телендәге тартыкларны чагыштыра.

Р.Ф. Шакированың «Хәзерге татар теле фонетикасына кереш» (1954) исемле китабы татар теленең авазларын тасвирлаучы беренче монографик хезмәт булып тора. Биредә авазлар беренче тапкыр фонологик яктан карала башлый, шулай ук татар әдәби теленең фонетик төзелешен өйрәнүгә нигезләнгән. Р.Ф. Шакирова татар телендә фонемалар системасының барлыгы 40 фонема булганлыгын исбатлый. Шуларның 28 е тартык, 12 се сузык фонема. Чыгышлары ягыннан 35 фонема татар теленең үз фонемалары, 5 фонема рус теленнән алынган фонемалар дип йөртә. Рус теленнән кергән фонемаларның өчесе ([ц], [в], [щ]) тартык фонемаларга, икесе (киң әйтелешле [о] һәм [э]) сузык фонемаларга кертелә.

Ф.М. Хисамованың татар филологиясе бүлеге студентлары өчен язган «Хәзерге татар теле фонетикасы» (1987) исемле методик күрсәтмәсендә иң беренче эш итеп сөйләм авазларының өч аспектта өйрәнелүе турында яза.

Г. Алпаров, Ф.Г. Исхаков үзләренең хезмәтләрендә тартык фонемаларның санын 46 дип күрсәтәләр. Бу очракта тартык фонемаларның калын һәм нечкә вариантта килүләре исәпкә алалар. Ә Ф.М. Хисамова үзенең хезмәтендә 28 фонема тартыкны күрсәтә. Ул татар телендә кайбер башка телләрдән аермалы буларак, тартыклар калынлык-нечкәлек буенча фонологик яктан каршы куелмыйлар, ягъни тартыкларның калынлыгы-нечкәлеге фонематик роль уйнамый, ул тулысынча сузыкларга бәйле була. Соңыннан һәрбер тартык фонемага характеристика биреп чыга.

Г.М. Сөнгатовның татар диалектлары фонетикасын өйрәнүгә караган хезмәтендә татар теле диалектларында авазлар системасы, фонетик закончалыкларның үзенчәлекләрен өйрәнә. Аңа кадәр Г.Ф. Саттаров, Ф.Ю. Юсупов һ.б. хезмәтләрендә диалекталь фонетикага игътибар ителгән булса да, Г.М. Сөнгатовның әлеге зур булмаган хезмәте бу юнәлештә эзлекле башкарылган, нигезле фактларга таянган булуы белән хөрмәткә лаек.

Г.М. Сөнгатов диалектология өлкәсендә дә хезмәт куючы буларак, диалекталь сөйләм үзенчәлекләренең нечкәлекләренә игътибар биргән. Хезмәттә транскрипция тәкъдим ителә. Алга таба һәм сузык һәм тартык авазларның татар сөйләшләрендә кулланылган вариантларына күзәтү ясалган. Авазларга ясалу ысулы һәм урынына карап, фәнни әдәбиятта кабул ителгәнчә характеристика бирелгә.

Ф. Хәкимҗан «Татар әдәби теле: Фонетика» (2001) хезмәтендә иң беренче фонетиканың тел тармаклары һәм башка фәннәр белән бәйләнеше, фонетиканың төрләре турында яза. Р.Ф. Шакированың фонема турында әйткән мәгълүматларны тирәнәйтеп Ф.С. Хәкимҗанов фонема турында үзенең өстәмәләрендә кертә, транскрипция һәм транслитерация турында мәгълүмат бирә.

Татар фонетикасына багышланган соңгы хезмәтләрдән Х.С. Сәлимовның тикшеренүләрен атарга була. Автор беренче мәртәбә спектраль анализ методын кулланып, татар вокализмын тикшерә, алынган мәгълүматларга таянып, татар сузыкларын акустик яктан тасвирлый, аларны рус һәм кайбер төрки телләрнең авазлары белән чагыштыра, комбинатор һәм позицион аваз үзгәрешләренең төрләрен ачыклый. Шул ук автор тарафыннан татар теленең беренче орфографик сүзлеге төзелә, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен фонетика буенча кулланмалар языла. Әлеге авторның хезмәтләре объектив методка таянып башкарылганга, алар икенче бүлектә карала.

Татар фонетикасына күпмедер өлеш керткән чит ил лингвистларыннан Н. Поппенны атарга була. Ул үзенең инглиз телендә басылган китабында татар теленең фонетик ситемасын инглиз, швед, норвег, гарәп телләре белән чагыштыра.

Татар фонетикасың кайбер аерым мәсьәләләре төрле хезмәтләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, татар һәм рус телләренең фонетик системаларын чагыштыру, В.А. Богородицкийдан ук башланып, Р.С. Газизов, З.М. Вәлиуллина, Ф.С. Фасеев, Ә.М. Ахунҗановларның хезмәтләрендә дәвам иттерелә. Д.Х. Бакеева хезмәтләрендә татар телләренең фонетик системалары чагыштырыла. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча Л. Җәләй башлаган тикшеренүләрне Л.И. Яфаров, В.Х. Хаковлар дәвам итә. Диалекталь фонетика буенча бик кызыклы күзәтүләр Л. Җәләй, Л.Т. Мәхмүтова, Д.Г. Тумашева, Ф.Й. Йосыпов, Г.Ф. Саттаровлар тарафыннан ясала. Татар теленең графикасы, орфографиясе, орфоэпиясе мәсьәләре Л. Җәләй, Х. Курбатов, Б.М. Мифтахов хезмәтләрендә яктыртыла.

**Литература**

Җәләй Л. Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар. – Казан: Таткнигоиздат, 1954. – 108 б.

Сәлимов Х.Х. Татар теле фонетикасы / Х.Х. Сәлимов. – Чаллы: “Камаз” нәшр., 1993. – 31 б.

Сөнгатов Г.М. Татар диалектлары фонетикасы. – Казан, КГУ, 2000. – 44 б.

Хаков В. Х. Татар әдәби теле тарихы. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. – 325 б.

Богородицкий В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. Изд 2-е. – Казан: Татгосиздат, 1953. – 219 с.

*Хисамов Олег Ришатович*
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан
Казан, Россия
*Khisamov Oleg Rishatovich*
Language, Literature and Art Institute named after G.Ibragimov
Academy of Science of Republic of Tatarstan
Kazan, Russia

## ТАТАР ЛИНГВИСТИК ГЕОГРАФИЯСЕ ҺӘМ АРЕАЛЬ ЛИНГВИСТИКА ФӘННӘРЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ ГАЛИМ
## FOUNDER OF TATAR LINGUISTIC GEOGRAPHY AND AREAL LINGUISTICS

Аннотация. *В статье идет речь о основоположнике татарской лингвистической географии и ареальной лингвистики Юсупове Ф.Ю. Юсупов Фарит Юсупович – языковед, доктор филологических наук, профессор, заслуженный деятель науки РТ, член-корреспондент Международного турецкого лингвистического общества (Турция, Анкара).*

Annotation. *The article deals with the founder of Tatar linguistic geography and areal linguistics Yusupov F. Yu. Yusupov Farit Yusupovich – linguist, doctor of Philology, Professor, honored scientist of the Republic of Tatarstan, corresponding member of the International Turkish linguistic society (Turkey, Ankara).*

Ключевые слова: *лингвистическая география, ареальная лингвистика, Юсупов Ф.Ю., диалектология, лингвистика.*

Keywords: *linguistic geography, areal linguistics, Yusupov F. Yu., dialectology, linguistics.*

Диалектология фәне – тел гыйлеменең билгеле бер территориядә яшәүче кешеләрнең тел үзенчәлекләрен өйрәнә торган мөстәкыйль тармагы ул. Диалектологның бөтен тормышы халык арасында, җанлы сөйләш үрнәкләрен туплауга багышланган фәнни экспедицияләрдә үтә. Диалектолог галим кабинет галиме түгел. Аның язганнары чын мәгънәсендә халыктан бөртекләп җыела. Диалектолог булыр өчен үз фәнең белән яшәргә, шуннан тәм табарга, аңа бөтен гомереңне багышларга кирәк.

Лингвистик география тел белеменең телләрнең һәм тел күренешләренең географик яктан таралышын өйрәнә торган тармагы. Төрле дәрәҗәдәге тел күренешләренең (изоглоссаларының) таралыш географиясен өйрәнә. Ареаль лингвистика диалектларның, телләрнең территориаль таралыш нәтиҗәсендә бер-

берсенә тәэсир итү ареалларын билгеләү мәсьәләре белән шөгыльләнә. Аның нигезен лингвистик география тәшкил итә.

Фәрит Йосыф улы Йосыпов татар халыкы, татар теле, татар фәне, татар диалектологиясе дип яшәүче кеше. Аның бөтен тормышы, яшәү рәвеше, гаиләсенең яшәү рәвеше татар теленә хезмәт итүгә багышланган. Татар диалектларын лингвистик география һәм ареаль лингвистика методларын кулланып өйрәнүне беренче булып Фәрит Йосыпов башлап җибәрә. Ул татар лингвистик географиясенә һәм ареаль лингвистикасына нигез салучы галим. Үзенең кандидатлык диссертациясендә ул беренче булып лингвистик географик методларын кулланган булса, докторлык диссертациясендә ареаль лингвистика югарылыгына күтәрелә.

Фәнгә мәхәббәт кечкенә Фәриттә бала чакта ук уяна. Монда без аның бөтен тирә якка танылган Камали бабасының тәэсирен күрәбез. Ләкин фән белән чын мәгънәсендә кызыксыну студент елларында башлана. Үз төбәгенең үзенчәлекле тарихы, теле, этнографиясе белән кызыксыну Фәрит Йосыповны Казан дәүләт университетына алып килә. Университетта укыганда Фәрит Йосыпов Латиф Җәләй лекцияләрен тыңлау, Диләрә Тумашева оештырган экспедицияләргә катнашу бәхетенә ирешә.

1962 елны Фәрит Йосыпов СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият, тарих институтының фәнни хезмәткәре булып эшли башлый.

1964 елны Көньяк Урал һәм Урал арты территориясендә таралган татар сөйләшләрен фәнни яктан өйрәнү Фәрит Йосыповка тапшырыла. Бу галимнең тормыш юнәлешен билгеләгән төп момент була. Шушы вакыттан башлап Йосыповның бөтен яшәү рәвеше диалектология фәненә буйсындырыла. 1964-66 елларда Курган, Чиләбе өлкәләренә фәнни экспедицияләр оештырыла. Җәй айларын Көньяк Урал һәм Урал артындагы татар авылларында тел материаллары туплап, кышын Уфа, Оренбург, Чиләбе, Мәскәү архивларында сакланган борынгы документларны өйрәнеп уздыра.Нәтиҗә буларак Йосыпов моңа хәтле билгеле булмаган сөйләш үзенчәлекләре, тормыш-көнкүрешләре, гореф-гадәтләре, халык авыз иҗатлары, ниһаять, татар халкының моңа кадәр бер галим тарафыннан да өйрәнелмәгән эчкен, сафакүл, нагайбәк татарлары дип аталучы этник төр-кемнәрен ача. Әлеге сөйләшләрнең фонетик, морфологик, лексик үзенчәлекләрен җентекләп туплап, анализлап бөтен фән дөньясына тарата. Әлеге фәнни-тикшеренү эшләре кандидатлык диссертациясе булып оеша. Ф. Йосыпов үз чоры өчен диалектология фәненә зур яңалык алып килә - диалект һәм сөйләшләрне географик лингвистика (тел географиясе) алымы белән өйрәнүне беренчеләрдән булып башлап җибәрә. Бу ысул тел күренешләрен шартлы билгеләр белән картага төшереп, аның таралыш чикләрен төгәл билгеләргә ярдәм итә. Ягъни, сөйләшләр һәм диалектларның кайсы өлкәдә, районда, авылда башланып, кайда тәмамлануын төгәл билгеләү мөмкинлеген бирә. Көньяк Урал һәм Урал артындагы гаять зур киңлекләргә таралган татар сөйләмнәрен яңа ысуллар белән өйрәнү Ф. Йосыповка бу географик территориядә татар теленең

нигез сөйләмнәреннән изоляцияләү шартларында, күрше телләрнең көчле тәэсире нәтиҗәсендә формалашкан, фәнни җәмәгатьчелеккә моңа кадәр билгеле булмаган нагайбәк, эчкен, сафакүл сөйләшләренең татар диалектлар системасындагы урынын төгәл итеп билгеләргә ярдәм итә. 1979 нчы елда галимнең әлеге өлкәдәге тикшеренүләрнең нәтиҗәсе булган «Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре» исемле хезмәте дөнья күрә.

Болгар чорында ук Урта Идел һәм Түбән Кама тирәләрендә укмашып, үз дәүләтенең нигезен корган борынгы бабаларыбыз өчен Урал төбәкләре дә беркайчан да чит булмаган. Урал итәкләре бик борынгы заманнардан ук татарларның изге Ватаннары булып саналган. Идел Болгарстаны монголлар тарафыннан басып алынгач, Казан ханлыгы җимерелеп, дәүләт туздырылганнан соң да, алар шул тарихи Ватан туфракларына барып сыеналар. Әлеге фикер галимнең хезмәтләрендә кызыл җеп булып сузыла. Әлеге фикерне ул һәрбер мәкаләсендә, һәрбер лекциясендә кабатлый: «Урал, Себер төбәкләре безнең бабаларыбызның төп йорты, ватаны. Безнең анда яшәүче милләттәшләребез әлеге төбәкнең җирле халкы. Алар килмешәк халык түгел». Әлеге фикерне Фәрит Йосыпов хезмәтләрендә генә кабатлап калмый ул фикерне ул иң югары даирәләргә дә ишеттерүгә ирешә. Аның 2006 нчы елны чыккан «Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты» дигән хезмәтенә язылган кереш сүздә мондый сүзләр бар: «...Безнең як туфракларында дүрт гасырдан артык славян һәм төрки халыклар үзара татулык һәм дуслык шартларында яшиләр. XVI гасыр азагында, чал Урал артындагы уңдырышлы җирләргә руслар килгәндә, монда татарлар һәм башкортлар яши иде инде. Шуңа күрә дә без татарларны диаспора – килгән халык дип исәпләмибез. Алар – өлкәбезнең җирле халкы». Әлеге сүзләрне Курган өлкәсе губернаторы О.А. Богомолов яза. Татар галименең китабына шундый дәрәҗәдәге рус кешесе кереш язган икән, димәк галимнең фикере иң югары дәирәләргә барып җиткән дигән сүз инде бу.

Фәрит абый Йосыповның татар теле фонемаларының төрле диалект һәм сөйләшләрдә таралган вариантлары, аларның әдәби телдән аермалары, шуларга нигезләнеп татар орфоэпиясен дөрес үзләштерү турындагы фәнни хезмәте «Җирле сөйләш шартларында фонетика укыту» исеме белән 1977 елда басылып чыга. Анда татар әдәби телендәге сузык һәм тартык фонемаларның артикуляцион һәм акустик үзенчәлекләре турында киң мәгълүмат бирелә, аннан соң аларның төрле төбәкләрдәге әйтелеш вариантлары күрсәтелә. Күзәтүне автор а авазыннан башлап китә. Бу сузык аваз телдә иң еш кулланылучы, ишетелү мөмкинлеге буенча иң көчле аваз, шуңа күрә аны дөрес әйтергә өйрәнү гаять әһәмиятле. Фәрит абый Йосыпов а ның татар сөйләшләрендәге иренләшкән, нык иренләшкән, ачык әйтелешле, аеруча ачык әйтелешле вариантлары барлыгын күрсәтә, сүзнең төрле позицияләрдәге төсмерләрен ачыклый. Биредә рус телендәге ачык әйтелешле а һәм татар телендә иренләшү төсмере белән әйтелә торган а арасындагы артикуляцион аерма конкрет мисаллар нигезендә аңлатыла.

Китапта башка сузыкларның барлык вариантлары һәм тәңгәллекләре турында да бәян ителә, дифтонглар кулланылышындагы төрлелекләр яктыртыла, сузык һәм тартык аваз закончалыклары сөйләшләр буенча чагыштырып бирелә.

Галимнең «Җирле сөйләш шартларында фонетика укыту» китабында хәзергә кадәр көн үзәгендә кала килгән ике зур мәсьәлә куела. Беренчесе — татар теленең авазлар системасын бербөтен итеп, барлык сөйләшләрдә таралган вариантларын барлап, чагыштырмалы-тарихи планда өйрәнү; икенчесе – халкыбызның күп гасырлар буена буыннан-буынга тапшырылып, эшкәртелеп килгән орфоэпия нормаларын дөрес үзләштерү һәм куллану.

Үзенең докторлык диссертациясен Ф. Йосыпов татар диалектларының һәм сөйләшләренең морфологиясен өйрәнүгә багышлый. Әлеге хезмәтнең төп яңалыгы фигыль категориясен яңача ысул белән, моңа кадәр татар диалектологиясендә кулланылмаган ареаль метод белән тикшерүдән гыйбарәт. Моңа кадәр татар диалектологлары һәрбер сөйләшне аерым-аерым өйрәнсәләр, Фәрит Йосыпович бөтен татар сөйләшләрендәге фигыль формаларын бергә алып, ареаль планда тикшерә. Әлеге тикшерүнең нәтиҗәләре 1985 елда «Неличные формы глагола в диалектах татарского языка», 1986 елда «Изучение татарского глагола», 2004 елда «Морфология татарского диалектного языка. Категории глагола» хезмәтләрендә чагылыш таба. 1998 елда «Татарский глагол в ареальном освещении» дигән темага докторлык диссертациясе яклана. Әлеге хезмәтләрдә татар диалектологиясендә беренче тапкыр «диалект теле», «диалект системасы» кебек төшенчәләр фәнни әйләнешкә кертелә.

Галим барлык диалект һәм сөйләшләр өчен хас булган күптөрле вариантлыкны, нинди генә кыйммәткә ия булуына карамастан, бер тәртип бөтен-леген (системаны) тәшкил итә торган вак системалар төзелеше итеп карарга тәкъдим итә. Үз чиратында вак системалар үзләреннән дә ваграк булган микросистемаларга бүленә. Алар үз эчләрендә иң кечкенә тел элементлары – фонема һәм морфемаларга таркала. Диалектларның шушы катлаулы системасын Ф. Йосыпов диасистема (диалектлар өчен хас системалар) дип атый. Ләкин һәр системаны тәшкил итүче элементларның диалект һәм сөйләшләр системасында үзенең төгәл урыны һәм вазифасы бар. Мәсәлән, кайбер элементлар телнең барлык диалект һәм сөйләш системаларында кулланыла, хәтта урынчылык дип аталып йөртелгән микросистемага үтеп керә һәм бөтен микросистеманың зарури элементын тәшкил итә. Бу элементтан башка бер генә диалект та, сөйләш тә нормаль яши алмый. Шушындый элементлар исәбенә татар теленең барлык диалект һәм сөйләшләре, гомумхалык теле тирәсендә тупланып аның бер территориаль вариантын тәшкил итә. Бу мәҗбүри, икенче төрле әйткәндә, зарури элементлар, бер төркемгә берләшеп, гомуми диасистеманың үзәген хасил итә. Фәрит Йосыпов фикеренчә, бу элементлар үзәк яки төш элементлары белән тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Кайбер очракларда бер диалектның аерым диасистемасы тулысы белән төш элементларыннан гына гыйбарәт була. Киресенчә, аерым диалект, сөйләш, урынчалыкларда гына очрый торган тел

элементлары да бар. Алар, гомуми система масштабыннан караганда, беренчеләр кебек, уртак диасистеманың яшәеше өчен мәҗбүри түгел. Шуңа күрә дә алар, гомуми системаның үзәгенә үтеп кереп, төш элементы була алмыйлар, үзәктән читтәрәк булалар. Бу үзлекләреннән чы-гып, аларны чик элементлары дип атыйлар. Алар чикләнгән территориядә яшәүчеләр телендә генә кулланыла. Төш элементлары, барлык диалектлар өчен хас булып, диалектара парадигматиканы хасил итәләр. Бу элементлар белән барлык диалект вәкилләре дә үзара аңлаша.

Фәрит Йосыпов бүгенге көндә дә актив рәвештә фән белән шөгыльләнә. Олпат галимебезгә ныклы сәламәтлек, иҗади уңышлар, планлаштырылган тагын барлык идеяларын тормышка ашыруны теләп калабыз.

*Һадиева Алсу Фаилевна*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Khadieva Alsu Failevna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

## ПРЕЦЕДЕНТ ИСЕМНӘР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ХӘЗЕРГЕ ТАТАР МАТБУГАТЫНДАГЫ ФУНКЦИЯЛӘРЕ
## PRECEDENT NAMES AND THEIR FUNCTIONS IN THE MODERN TATAR PRESS

Аннотация. *В статье рассматриваются особенности применения прецедентных имен в татарской печати и выявляются их функции.*

Annotation. *The article discusses the features of the use of precedent names in the Tatar press and identifies their functions.*

Ключевыеслова: *татарский язык, прецедентные имена.*

Keywords: *the Tatar language, precedent names.*

Прецедентлык – хәзерге заманда телебезнең үзенчәлекле ягы, ул матбугат сөйләменә дә хас. Журналистик язмаларда прецедент исемнәр куллану язманы тулыландыра, тасвирлы итә. Сөйләмдәге үзгәрешләр беренчеләрдән булып матбугат телендә барлыкка килә.

Әлеге фәнни эш кысаларында без татар матбугатында прецедентлык феноменың кулланылыш үзенчәлекләрен тикшердек һәм түбәндәге газета-журналларны кулландык: «Безнең гәҗит», «Сәхнә», «Татарстан яшьләре», «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Безнең мирас» һ.б. Аларда мондыйрак прецедент исемнәр очрады: *Мамай явы, Хуҗа Насретдин, Шәкүр карак, Шомбай, Мәҗнүн гыйшкы, Гобәй белән Хобәй булу, Гали үз эшендә, Вәли үз эшендә, Бәдигъ мәзин күркәсе, Галигә дуслыктан түгел, Могавиягә дошманлыктан, Габдулла биясе, Хуҗа Насретдин ишәге, Тыр-тыр Зариф, Сафура бураны, Мәҗнүн, Биби,*

*Клеопатра, Аполлон, Кощей Бессмертный, Плюшкин, Мать Тереза, Иисус Христос, ХәмДүнь, Хәмднюша, Мәһдиев, Тукай һ.б.*

Мәсәлән: *Шәхсән үзем, **Плюшкин** сыман кыланып, токмачтан, соктан, торттан, сөт ризыкларыннан бушаган барлык төр савытларны, бер кулланылышлы стаканнарны ел дәвамында гараждагы капчыкларга җыеп барам* (Гарипова Х. Кайда үстерергә: тартмадамы, ... йомырка кабыгындамы? // Татарстан яшьләре. – 2017. – 22 март).

*Атна уртасында Казандагы Тукай музеенда "Граммофон тәлинкәләре ни сөйли?" исемле музыкаль кичә узды. Җырчы Идрис Газиев Камил Мотыгый, Мәрьям Искәндәрова кебек **Тукай чоры** артистларын ишеттерде* (Дәүләт Б. Идрис Газиев Тукай чоры җырларын тыңлатты // Азатлык радиосы.hww.azatliq.org/a/24501916.htmlttps://w (мөрәҗәгать итү вакыты: 15.09.2018).

Татар матбугатын тикшерү вакытында очраган прецедент исемнәрнеәсәр геройлары (*Плюшкин*), халык иҗаты геройлары (*Кощей Бессмертный, Хуҗа Насретдин*), тарихи образлар (*Клеопатра, Аполлон*), татар язучылары (*Мәһдиев чоры, Тукай чоры*), Библиядән геройлар (*Мать Тереза, Иисус Христос*) һ.б. төрләргә бүлеп була.

Матбугатта кайвакыт ялгызлык исемнәр уртаклык исемгә дә әверелә. Мәсәлән:

*Тегеннән-шуннан селтәп, укыган-ишеткәнне кушып, инша шәкелендә мәтәштерүләрне **шомбайлык** дип кенә санарга рөхсәт итегез...* (Зарипов Р. «Космаполитлар» (хата минеке – Р.З.) // Татарстан яшьләре. – 2017. – 13 июль). Шомбай – татарлар арасында киң таралган әкият герое. Надан, эшлексез кешеләргә карата кимсетү сүзе буларак кулланыла. Шомбайлык, димәк, ясалма сүз.

Күзәтүләр күрсәткәнчә, татар газеталарындагы язмаларда атау функциясе башкаручы исемнәр аеруча еш эшкә җигелә. Бу очракта баш исеменә бөтен текстның кыскача эчтәлеге чыга: *«Хуҗа Насретдин» яңадан сәхнәгә кайта»* («Хуҗа Насретдин» яңадан сәхнәгә кайта// Шәһри Казан.http://shahrikazan.com/news/teatr/hua-nasretdin-yaadan-shng-kayta (мөрәҗәгать итү вакыты: 15.04.2018).

Журналистик язмаларда баш исемнең экспрессив функция үти торганнары да кулланыла ала. Баш исемнең мондый төренә автор укучыны кызыксындыру, аның игътибарын җәлеп итү максатында мөрәҗәгать итә:

*«Шомбай-fest» яратырга өйрәтә* («Шомбай-fest» яратырга өйрәтә // Шәһри Казан http://shahrikazan.ru/news/m%D3%99d%D3%99niyat/shombay-fest-yaratyirga-yrt (мөрәҗәгать итү вакыты: 15.04.2018).

*«Айгөл Хәйруллина Наполеоннан калышмый»* (Шиһапов И. Айгөл Хәйруллина Наполеоннан калышмый // Шәһри Казан. – 2016. – 15 гыйнв.).

Текстларның үзләренә килгәндә, матбугатта прецедент исемнәр еш кулланыла. Мәсәлән: *Бәйрәм алдыннан халык барлык төп ризыкны кырып-себереп сатып алып бетергән, **Мамай явы** узган диярсең* (Нурулла М. Кемгә бәйрәм, кемгә – матәм // Безнең гәҗит. – 2016. – 11 гыйнв.).

Биредә Яңа ел алдыннан кибетләрдә әйберләр калмауны укытучы яу үткән дип чагыштыра, язмага сурәтләү чаоасы кертә. «Мамай явы» дигән прецедент исем, гомумән, татар матбугатында еш очрый. Мәсәлән:

*Россиянең урта полосасы аша* ***Мамай явы*** *үткән диярсең – тоташ чәчелмәгән, билчәнле, әремле кырлар, ташландык, җимерек авыллар, фермалар* (Шәрифуллин Н. Нефть тозагы // Ватаным Татарстан. – 2017. – 29 ноябрь.).

Биредә автор киресенчә эшкәртелмәгән, бернәрсә эшләнелмәгән җирләрне Мамай явы белән чагыштыра. Мамай явы – сугыш вакыйгасы, тарихи факт. Мамай хан XIV гасырда яшәгән, ә аның исеме бүген еш кына күчерелмә мәгънәдә матбугатта кулланыла.

Мамай явы – тезмә сүз, күчерелмә мәгънәдә бирелә. Әмма туры мәгънәдә дә очрыйлар. Мәсәлән:

***Мамайда*** *яшәүче әнием Надияне дә бик хөрмәт итә, гел булышып* торабыз (Мингатина С.»Әни усалрак, болай икесе дә «нормальный» -гади бер гаилә турында // URL: http://matbugat.ru/news/?id=19403 Тулырак: http://matbugat.ru/news/?id=19403 (мөрәҗәгать итү вакыты: 18.05.2019).

Биредә Мамай – авыл исеме.

Татар газеталарында прецедент исемнәр ясалышлары ягыннан төрлечә очрыйлар. Мәсәлән:

***Сталин*** *әмере нигезендә, Советлар Союзының һәр гражданы, төрле сәбәпләр аркасында кая һа булса киткән икән, башкарган хезмәт урынына кайтурга тиеш* (Шәмсуаров Т. Катя – Кэт – Кәтибә язмышы: канлы юлда үлекләр түшәлеп кала // Ватаным Татарстан. – 2018. – 10 апр.).

Биредә прецедент исем булып, *Сталин* фамилиясе килгән. Әмма, без беләбез: кеше исемнәрендә исем һәм әтисенең исеме дә була. Шулай да матбугатта Сталин, Ленин, Горбачев h.б. шундый исемнәрнең фамилия белән генә бирелүе еш күренеш.

*Мәхәббәт турындагы шигырьләреңне укып шундый фикергә килдем: син сөюдән шашкан, хисләрдән тилергән бер* ***Мәҗнүн*** *кебек* (Гәбдерәхим. Ленар Шәех: «Яшь буынга остаз булырдай язучылар калмады» // Акчарлак. – 2016. – 4 июнь).

Биредә журналист Ленар Шәехне Мәҗнүн белән чагыштыра. Әлеге исем татар әдәбиятында, матбугатында ялгызлык исеменнән уртаклык исемгә күптән әйләнде. Мәҗнүн дип гашыйк кешегә, өметсез мәхәббәт корбаны булган ир-егеткә карата әйтәләр. Бу сүз күмәклек һәм ялгызлык исемнәре арасындаторган арадаш берәмлекләр буларак караучылар да бар. Рус һәминглиз телендәге ялгызлык исемнәренең кулланылыш һәм үзара күчеш үзенчәлекләрен өйрәнгән Р.З. Ханичев аларны апеллонимик интерподсистема дигән термин белән атауны тәкъдим итә [Ханичев, 2004: 4]. Аның фикеренчә, бу төр лексемалар икетөрнең берсенә дә карамый, чөнки аларның аермалы булган сыйфатлары бар.

*Мәҗнүн* онимы хәзерге татар телендә тулы референциядә очрамый диярлек. Әмма аның күчерелмә референциядә бирү потенциал күләме зур. Татар лингвокультурологиясе белгечләре өчен Мәҗнүн – Низаминың «Ләйлә һәм

Мәҗнүн» әсәре герое. Әлеге оним татар лингвокультурологиясендә өметсез гашыйк булган кешене аңлату өчен кулланыла [Галиуллина, 2016: 118].

Шулай ук *мәҗнүн* онимы яшь кызга карата да кулланыла ала: *Кайсыгыз үз өстенә алып, дәлил итеп әйтер, мәрхүмә Гарифулла кызы Кәримә мәҗнүн идеме, әллә камил зат идеме? (Ф. Яхин).*

Әлеге прецедент исем аерым бер төркем кешеләргә дә карата куланылган очраклар бар: *Гаташта – Байроннар, Мәҗнүннәр мәхәббәте (Р. Миңнуллин); Әллә соң авылда Йосыфлар, Таһирлар, Фәрхадлар, Мәҗнүннәр, Хәлилләр булмадымы? Миңнурга кызыгып, аңа күз атып, күңеле төшеп, аның белән хыялланып йөргән егетләр булмады түгел, булды (З. Мәхмүди)* [Галиуллина, 2016: 119].

Әйтергә кирәк, прецедент исемнәрнең мәгънәсе контекст белән формалашмый, алар аңа «әзер» семантик төсмерләр белән кертелә. Алар тел ияләре өчен билгеле, татар лингвокультура җәмгыяте вәкилләре тарафыннан эмоциональ-бәяләү үзенчәлекләре белән кабул ителә һәм сөйләмдә актив кулланыла [Галиуллина, 2016:119].

Шулай итеп, татар матбугатында, шул исәптән баш исемнәрдә дә прецедент исемнәр куллану мисаллары күп. Алар туры мәгънәдә дә, күчерелмә мәгънәдә дә кулланылалар.

Сөйләм агышында прецедент сүзләр, денотатив, сигнификатив мәгънәләр белән бергә, коннотатив эчтәлеккә дә ия булалар.Аларның бергә кулланылышы сүзнең эчке табигатен, формасынбарлыкка китерә һәм сөйләм эчендә төрле семантик вариантлылыкка юл ача. Лексик мәгънә үз эчендә сөйләм эчендә ачыла ала торганбарлык төр компонентларны да берләштерә, шулар ярдәмендә чынбарлык күренешләрен атап кына калмый, бәлки төгәл бәя дә бирә.

**Әдәбият**

Галиуллина Г.Р. Прецедентные имена в современном татарском языке // Ученые записки Крымского федерального университета имени В.И. Вернадского. Серия «Филологические науки». Том 2 (68), № 3. 2016. – С. 117–121.

Ханичев Р.З. Сопоставительная характеристика процессов деонимизации в русском и английском языках: автореф. дис. ... канд. филол наук. – М., 2004. – 26 с.

*Һадиева Гөлфия Камиловна*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Khadieva Gulfiya Kamilovna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

# КАЗАН ШӘҺӘРЕ УРБАНОНИМИЯСЕНЕҢ ТАРИХЫ
# HISTORY OF URBANONE OF THE CITY OF KAZAN

Аннотация. *В современных условиях деятельность человека тесно связана со сферой расширения городского ландшафта, что определяет особенности восприятия языковой личностью внутригородского пространства. Представляется важным показать, что за названиями городского объекта стоит внутреннее богатство ментального пространства. В статье рассматривается история урбанонимии города Казани. Анализируются этапы развития названий улиц города Казани.*

Annotation. *In modern conditions, human activity is closely related to the expansion of the urban landscape, which determines the perception of the linguistic personality of the inner-city space. It seems important to show that behind the names of the urban object is the inner wealth of the mental space. The article discusses the history of the development of urbanonym of the city of Kazan. The stages of development of the streets of the city of Kazan are analyzed.*

Ключевые слова. *Урбанонимика, урбанонимия, топонимия города, названия улиц, история города.*

Keywords. *Urbanonymica, urbanonyty, city toponyty, street names, city history.*

Урбанонимнар җәмгыятьнең сәяси, социаль, икътисади, мәдәни сфералар белән тыгыз бәйләнештә торып, әлеге сфералардагы яңарышларны чагылдырып торучы элементлар булганга күрә, аларны телнең һәрдаим үзгәрешләр кичерә торган өлкәсе итеп билгеләргә мөмкин.

Без мәкаләбездә татар урбанонимиясен Казан шәһәре мисалында тикшерергә булдык. Беренчедән, язу кенәгәләрендә, тарихи документларда Казан шәһәренең кайбер урам исемнәре теркәлеп калган. Икенчедән, башкала шәһәренең атамалар системасы, провинциаль шәһәрләр белән чагыштырганда, иң зур үсешкә ия булып тора. Урбанонимик даирәнең формалашу концепциясе югары дәрәҗәдә эшкәртелгән булганга күрә, башкаланың атамалар системасы башка шәһәрләр өчен онимик терминнар чыганагы булып хезмәт итә.

Казан шәһәренә багышлап, күпсанлы тарихи очерклар, китаплар, мәкаләләр язылган, юлкүрсәткечләр төзелгән.

Г.Ф. Саттаровның «Ни өчен шулай аталган? Татарстан топонимнары» дигән хезмәтендә урам исемнәрен өйрәнү торышы, аларның элекке һәм хәзерге исемнәре, урам исемнәрен алмаштыру-яңарту, язуда дөрес чагылдыру проблемаларын күтәрә. Шулай итеп, профессор Г.Ф. Саттаров беренчеләрдән

булып татар урбанонимиясен тикшерә [Саттаров, 1971: 47-79]. Шуңа нисбәтле, галим татар топонимикасы фәненең урбанонимика бүлегенең нигез ташларын сала. 1993 нче елда Г.Ф. Саттаров «Башкалабыз атамаларына – милли рух» дигән мәкаләсендә урам атамаларында милли рухыбыз һәм йөзебез чагылмавы, татар урамнары исемнәренең бик азы татарча булуы, аларга татар халкына мөнәсәбәте булган күренекле шәхесләребезнең исемнәрен куярга кирәклеге мәсьәләсен күтәрә [Саттаров, 1993: 164-168].

К.Ф. Әмировның «Казань: где эта улица, где этот дом?» дигән белешмә китабында Казан шәһәре урамнары турында шактый тулы тарихи-лингвистик мәгълүматлар бирелә [Амиров, 1995].

Бүгенге көндә вакытлы матбугатта татар урбанонимнары проблемасына багышланган мәкаләләр басыла, массакүләм мәгълүмат чараларында топонимнарны тәрҗемә итү, аларны алмаштыру, тарихи атамаларны кайтару проблемалары күтәрелә.

Лингвистлар һәм фәлсәфәчеләр фикеренчә, тел берәмлекләрендә гасырлар дәвамында җәмгыять эволюциясе нәтиҗәсендә формалашып килгән милли психология, менталитет һәм милли үзаң чагылыш таба. Татар урбанонимнарының килеп чыгышы тарихы шуның белән тыгыз бәйле. Казан шәһәре урбанонимиясенең күпчелеген рус атамалары тәшкил итсә дә, шуның белән бергә татар халкы бары тик үз милләтенә генә хас булган үзенчәлекләрне дә урбанонимнарга күчергән. Бу аңлашыла да: урам исемнәре җирле халыкның дөньяны күзаллавына, аның гадәт-йолаларына, тарихына бәйле.

Россия тарихына бәйле рәвештә, татар урбанониясен, без, түбәндәге тарихи чорларга бүлеп карыйбыз: 1) революциягә кадәрге чорда барлыкка килгән урбанонимия; 2) совет чоры урбанонимиясе; 3) хәзерге чор урбанонимиясе (1990 нчы еллардан бүгенге көнгә кадәрге чор). Түбәндә һәрбер дәвернең үзенчәлекләрен карап китик һәм татар урбанонимиясенең тарихына күзәтү ясыйк.

1) революциягә кадәрге чорда барлыкка килгән урбанонимия

Борынгы Казан шәһәренә Идел Болгарстаны чорында нигез салына.XV йөздә шәһәр Казан ханлыгы башкаласына әйләнә.Казан шәһәре халкын башлыча болгар-татарлар һәм башка җирле халык вәкилләре тәшкил иткән. 1552 нче елда Казан ханлыгы рус дәүләтенә кушылгач, җимерелгән шәһәр торгызыла. Казан Кремленең чикләре арттырыла, яңа бистәләр төзелә. Татарлар шәһәр эченнән куылгач, шәһәргә руслар күченеп яши. Казан шәһәре дә рус шәһәрләре сыйфатларын чагылдыра башлый: борылмалы урамнар, тупиклы тыкрыклар, күп санлы ерымнар барлыкка килә.Казан шәһәренең язу кенәгәсендә кайбер урам һәм тыкрык исемнәре*Тау өсте, Тау асты, Ерым арты, Ярык өсте* дип теркәлгәннәр. Кабан күленең сул яры буенда *Татар бистәсе* була.

XVIII гасыр урталарына кадәр Казан ирекле рәвештә төзелүен дәвам итә. Ләкин Санкт-Петербургта оештырылган төзелеш Комиссиясе Казанны, башка 200 шәһәр белән беррәттән, регуляр план буенча төзелергә тиешле шәһәрләр исемлегенә кертә. Шулай итеп, 1767 нче елдан башлап, Казанда В.И. Кафтырев

исемле архитектор шәһәр планы төзү эшен башлап җибәрә. Аның проектлары буенча Казанда дистәләгән торак, административ һәм дини бина төзелә.[http://history-kazan.ru/kazan-vchera-segodnya-zavtra/istoriya-v-litsakh/zhzl-kazanskaya-seriya/3307-597]. Бу вакытта Казан составына 9 зур урам, 170 кече урам белән тыкрык, 10 мәйдан, 8 бистә кергән. Үзгәрешләр башлыча үзәк районнар эчендә башкарыла – шәһәр читендәге төзелеш һаман да ирекле характерга ия була.

Казан урамнары веер һәм турыпочмак системасында төзелә. Үзәк нокта булып Кремль санала, Кремльдән *Проломная, Воскресенская, Арская*урамнары сузылып китә.Төзелешнең башка юнәлешен билгеләүче булып *Болак* белән *Кабан күле* тора. Аларга параллель рәвештә *Вознесенская, Московская, Екатерининская* урамнары урнаша [Амиров, 1995: 7].

1815 нче һәм 1842 нче елдагы янгыннардан соң шәһәр үзәгендә таш биналар төзелеше активлаша.*Пләтән, Әмәт, Савин, Калуга, Игумново* исемле чиктәш авыллар шәһәр бистәләре статусына керә. *Проломная, Георгиевская, Петропавловская, Гостинодворская, Воскресенская* урамнарына таш түшәлә.

Бу чорда чиркәү һәм монастырь исеме белән аталган урам исемнәре күп була: *Воскресенский, Спас, Георгиевский, Петропавел, Вознесенский* урам һәм тыкрыклары; *Преображенский, Архиепископ, Федоровский, Архангель, Пләтән бистәләре* (соңгы икесе XVII йөздә шул исемдәге монастырьларга караган авыллар булганнар). XIX йөздә бу бистә һәм авыллар шәһәр эчендә калганнар, ә исемнәре урамнарга күчкән.

1899 нчы елда гына шәһәр Думасы утырышында шәһәр башлыгы С.В. Дьяченко урам исемнәрен алмаштыру белән шөгыльләнергә кирәк дигән мәсьәләне күтәрә. Моның проектын төзү Казан тарихчысы Н.Я. Агафоновка тапшырыла. Ул шул ук елны үзенең проектын тәкъдим итә [Агафонов, 1899].Бу проектның зур гына кимчелекләре була. Н.Я. Агафонов Казан урамнары исемнәрен алмаштыру мәсьәләсендә, югары катлау вәкиле буларак, үз сыйныфы интересларыннан чыгып эш итә. Ул, беренче чиратта, патшалар (*Александр II, Николай, Екатерина* урамнары), эре түрәләр, дворяннар (князь*Курбский,* подполковник *И.И. Михельсон*, Казан чиновниклары һәм дворяннары *М.А. Ахматов, И.С. Жарков, Ф.Н. Хворов*) һәм бай сәүдәгәрләр (*Г.Д. Чепарин, В.П. Ложкин*) исем-фамилияләрен Казан урамнарына бирүне күздә тота. Шул ук вакытта Н.Я. Агафонов проектының заманы өчен уңай, прогрессив яклары да бар. Автор күп кенә урамнарга атаклы язучылар, галимнәр, мәгариф һәм мәдәният эшлеклеләренең исемнәрен бирергә кирәк дип карый. Казанның аерым урамнарының исемнәрен *Л.Н. Толстой, А.С. Пушкин, С.Т. Аксаков, Г.Р. Державин, К. Фукс, А.М. Бутлеров*, татар галимнәреннән *Хәлфиннар* һ.б. хөрмәтенә алар исеме белән алмаштырырга тәкъдим итә. Ул елларда ук бөек рус язучылары *Л.Н. Толстой, А.С. Пушкин* исемнәре бирелгән урамнар бүген дә шулай аталалар [Саттаров, 1971: 72-73].

XX йөз башларында дәвалау, сәүдә, сәнәгать оешмалары исемнәрен алган *Госпитальная, Газовая, Заводская, Кузнечная, Горшечная, Бойничная, Толчок* урамнары, *Тулуповка, Рыбноряд* мәйданнары, географик үзенчәлекләренә нисбәтле *Подлужная, Заречная, Луговая* урамнары барлыкка килә.

1914 нче елда Казанның яңа планы төзелүе сәбәпле, дистәләгән урам исемнәрен алмаштыруны күздә тоткан карар чыгарыла. Үзгәрешләр иң беренче чиратта яңгырашы күңелгә ятмаган атамаларга кагыла: мәсәлән, *Кошачий* һәм *Собачий* тыкрыклары үзгәртелә, *Юшков* тыкрыгы *Некрасов* урамына әверелә.

2) совет чоры урбанонимиясе

Совет чорында татар урбанонимиясе тарихының яңа дәвере башлана. 1920 нче елның 25 нче июнендә Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелә. Шәһәр торгызыла, халык саны арта башлый. Бөек Ватан сугышына кадәр Казан индустриаль үзәккә әверелә. Моңа нисбәтле, *Дементьева, Техническая* һ.б. индустриаль урамнар калкып чыга.

Россиянең башка шәһәрләре кебек үк, Казан да 1917 нче елның инкыйлабыннан соң шактый урам исемнәрен алмаштыра. Хакимият алмашыну белән шәһәр урбанонимия тарихының яңа дәвере башлана. Идеологиягә нисбәтле исемнәр барлыка килә башлый: *Восстание, Маркс, Энгельс, Ленин* урамнары һ.б. Октябрь инкыйлабыннан соң илебездә булган зур үзгәрешләр йогынтысында барлыкка килгән һәм шул елларның рухын җиткергән урбанонимнар саны шактый: *Совет, Пролетар, Кызыл Октябрь, Пионерлар урамнары* һ.б. Шулай ук патша хакимиятенә каршы чыгучыларның исемнәре барлыкка килә чыга: *Разин, Пугачев* урамнары.

1950 нче еллардан башлап татар урамнарына Бөек Ватан сугышы геройлары, сәнгать, әдәбият эшлеклеләре, галимнәрнең исемнәре бирелә. Алар арасында татар фамилияләре дә еш очрый. Мәсәлән, *Хөсәен Ямашев, Гадел Кутуй, Салих Сәйдәшев, Әмирхан Еники, Һади Такташ* урамнары.

XX йөзнең 60 нчы елларында илдә барган прогрессив үзгәрешләр нәтиҗәсендә Космоска беренче космонавт чыгару куанычын уртаклашу һәм хөрмәт белдерү йөзеннән татар халкы урамнарына *Гагарин, Космонавтлар, Академик Королев* һ.б. исемнәре бирә. Илдә барган сәнәгать революциясе дулкынында *Мотор, Водоканал, Индустрия, Завод* урамнары исемнәре калкып чыга.

Совет заманы урбанонимиясе алдагы чор традицияләрен дәвам итә: кайбер урам исемнәре географик объектларга нигезләнеп исемләнә: *Озерная, Дачная* урамнары; кеше һөнәре исемен йөрткән урам исемнәре барлыкка килә: *Химиклар, Журналистлар, Мехчылар* урамнары.

3) хәзерге чор урбанонимиясе

Татар урбанонимиясенең хәзерге чоры иң беренче чиратта тарихи атамаларның яңадан кайтуы белән характерлана. *Кәҗә бистәсе станциясе, Сукно бистәсе, Ташаяк урамы* атамалары барлыкка килде.

XXI йөз башларында кайбер урбанонимнар башка исемнәргә үзгәртелә. Мәсәлән, *Земляничная 3-я – Рәхим Саттар, Владимирская 2-я – Коновалов,*

*Шатурская* урамының бер өлеше – *Симонов, Портовая* урамының бер өлеше – *Девятаев, Татцика – Мәсгут Латыйпов, Лесопарковая* урамының бер өлеше – *Алтынов, Совхозная – Сафин, Союзная 4-я – Әнвәр Кәримов, 50 лет Октября – Академик Кирпичников, Сакко и Ванцетти – Рөстәм Яхин, Тукай тыкрыгы – Михаил Худяков, Ухтомского – Борһан Шаһиди, Школьный пер. – Катановский пер., Революция – Нәкый Исәнбәт, Калинин* урамының бер өлеше – *Әмирхан Еники, Володарского – Гаяз Исхакый, Кирпично-Заводская – Һади Атласи, Ново-Кремлевская – Ташаяк, Армавирская 2-я – Муса Бигиев, Карл Либкнехт – Алафузов, Проходная – Сардар Вәисов, Забайкальская – Галимҗан Баруди, Ярмарочная площадь – Меңьеллык мәйданы, Нариманов* урамының бер өлеше – *Сара Садыйкова, Трубная – Гомәр Гали, Набережная – Азатлык* һ.б. Күргәнебезчә, татар урбанонимиясе системасында татарның күренекле шәхесләренең исемнәре мәңгеләштерелә, милли исемнәребез бирелгән урамнар саны арта. Шул ук вакытта, урам исемнәрен алмаштыру – тирәнтен уйлап эш итүне сорый торган җаваплы һәм мөһим эш булып санала.

Казан шәһәренең хәзерге чорында барлыкка килгән урам исемнәрен башкага алмаштыру нәтиҗәсендә генә барлыкка килгән дип әйтеп булмый, чөнки шәһәр һәм авылларда яңа төзелгән урамнар барлыкка килә. Бу аларның киңәю күрсәткече булып тора.

Гомумән, Казан шәһәрендә яңа барлыкка килгән урамнарга татар халкының күренекле җәмәгать эшлекләре, язучылары, мәдәният һәм фән хезмәткәрләренең исемнәрен бирү күпләрдә канәгатьлек хисе уятты.

**Әдәбият**

Агафонов Н.Я. Историческая объяснительная записка наименования Казанских улиц // Материалы к вопросу переименования улиц города Казани. – Казань, 1899.

Амиров К.Ф. Казань: где эта улица, где этот дом? – Казань: Изд-во Казань, 1995.– 320 с.

Первый генеральный план – от Василия Кафтырева http://history-kazan.ru/kazan-vchera-segodnya-zavtra/istoriya-v-litsakh/zhzl-kazanskaya-seriya/3307-597 Дата обращения: 04.11.2019.

Саттаров Г.Ф. Ни өчен шулай аталган? Татарстан топонимнары. – Казан: Тат. кит.нәшр. 1971. – 127 б.

Саттаров Г.Ф. Башкалабыз урамнарына – милли рух // Казан утлары, 1993. – № 1. – 164-168 б.

*Һадиева Илүзә Фәнүсовна*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Khadieva Iliuza Fanusovna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

# З. ХӘКИМНЕҢ «СӘЕР КЫЗ» ДРАМАСЫН ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ӨЙРӘНҮ
# STUDYING THE DRAMA OF ZULFAT XAKIM AT THE LESSONS OF TATAR LITERATURE

Аннотация. *Данная статья посвящена изучению произведения современного драматурга Зульфата Хакима в седьмом классе в татарских группах татарских школ.*

Annotation. *This article is devoted to the study of the work of the modern playwright Zulfat Hakim in the seventh grade in Tatar groups of Tatar schools.*

Ключевые слова: *драма,анализ, сюжет, проблематика, образ.*

Keywords: *drama, analysis, plot, problematics, image.*

Танылган замана драматургы Зөлфәт Хәким иҗаты тематикасы, күтәрелгән мәсьәләләре буенча шактый киң колачлы булуы белән аерылып тора. Аның кайбер әсәрләренең мәктәп программаларына кертелгән булуы – әлеге әсәрләрнең мәгънәви тирәнлеге, үзенчәлекләре хакында яшь буын укучылар белән дә өйрәнергә, фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

Драматургның «Сәер кыз» драмасы татар мәктәбенең татар төркемнәренең 7 сыйныфында өйрәнелә («Татар урта мәктәпләре өчен әдәбият программалары»на (авторлары: А.Г. Әхмәдуллин, Ф.Г. Галимуллин, Ф.Г. Ганиева, Ф.Ф. Исламов, «Мәгариф» нәшрияты, 2010), «Татар телендә гомуми төп белем бирү мәктәпләре (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа» (Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова, 2013) әлеге әсәрне өйрәнүгә 3 сәгать вакыт бирелә.

Бу әсәр – сәнгать, сәнгать әһелләре турындагы пьеса. Шуңа күрә аны интеллектуаль драма дип характерлыйбыз. (Бу очракта да терминны сүзлектән карап, искә төшерү уңай нәтиҗә бирә). Әсәрне Т. Миңнуллинның «Миләүшәнең туган көне» трилогиясе белән янәшә куеп анализларга да мөмкин. З. Хәким укучы һәм тамашачы күрергә гадәтләнгән образлардан читләшеп, өр-яңа заман кешеләре – интеллигенция вәкилләре, зыялылар образларын тудыра. Бу геройларны төрле ситуацияләргә куеп, автор җәмгыятькә һәм иҗади кеше шәхесенә кагылышлы проблемаларны киң катлам укучыга, тамашачыга җиткерә, аны тагын бер кат уйландыра. Пьесаның проблематикасын билгеләү максатыннан, драмадагы образлар системасына характеристика бирүне кирәк дип табабыз.

Әсәрдәге төп образ – 19 яшьлек Дилбәр. Ул китапханәче булып эшли, укытучы булырга укый, әмма саф күңелле кыз бала шәһәрдә тупаслык һәм әхсазлыклык чәчәк атуын үз күзләре белән күргәч, бу гаделсезлек белән килешә

алмыйча, укуын һәм киләчәккә булган хыял-планнарын ташлап, кире авылына кайта. Үзенең теләк-омтылышларында, мәхәббәтендә буталып калган Дилбәр күңелен ниндидер билгесезлек, борчу биләп алган. Авылда аңа аралышырга, аның фикерләрен аңлаучы кеше юктыр кебек, әмма көтмәгәндә авылда мәдәният йортын бизәргә дип, шәһәрдән Мөхтәр исемле рәссам – урта яшьләрдәге ир-ат килә. Алар аралаша башлый. Табигыйлеге белән күпләрне сокландырган кыз белән рәссам-иҗатчы диалогы тормыштагы, сәнгатьтәге матурлык турындагы бәхәскә үсеп әверелә, аңа төрле социаль катламдагы кешеләр килеп кушыла. Әлеге әсәрне анализлай барышында да галимнәр фикерен файдалану уңай нәтиҗә бирә (Мисалга Ә. Закирҗановның «Эзләнү юлында» мәкаләсе кызыклы [Закирҗанов, 2012: 5].

Мөхтәр тормышка, җәмгыятькә карата карашы кызыклы булуы һәм индивидуальлеге белән аерылып тора. Ул барлык иҗат кешеләрен дә өч төркемгә бүлеп карый: кәсепчеләр, профессионаллар, мин-минле иҗатчылар, ягъни үзләрен әллә кемгә санап йөрүче бушкуыклар.

Кәсепчеләр төркемендә Мөхтәр үзен дә күрә. Әмма аның яшәве – акча эшләүгә генә кайтып калмый, ул матурлык тудыра. Кешеләргә аның иҗаты ошый, ул үзе дә моңардан матди файда гына түгел, ә җан тынычлыгы да ала, ягъни үз-үзе һәм тирә-юнь белән гармониягә керә. Биредә укучылар белән матурлык төшенчәсе хакында сөйләшү кирәк дип табабыз. Әлеге эстетик категориянең асылын аңлатабыз (яки сүзлек өстендә эш оештырабыз). Эстетик категория – ул үзенчәлекле рухи, кешенең дөньяга мөнәсәбәте. Эстетика үз эченә кечерәк бинар оппозицион категорияларны җыя. Алар – матурлык – ямьсезлек, трагиклык – комиклык, коточкычлык – камиллек. Заманча тикшеренүчеләр фикеренчә, зур күләмле булу сәбәпле, югары күренешләр шундук тулысынча үзләштерелә алмый, шуңа күрә кеше аларга карата ирекле түгел. Гүзәллек – кеше иреге өлкәсендә, югарылык исә – көн кадагындагы өлкә.

Эстетика үз эченә ул матурлык төшенчәсен ала. Борынгы антик чордан башлап, бүгенге көнгә кадәр фәлсәфәчеләр, язучылар, иҗатчылар матурлык төшенчәсенең асылына төшенеп, аны төрлечә интерпритацияләргә омтылып яши.

З. Хәким пьесасын Ә. Еникинең «Матурлык» хикәясе белән янәшә куеп, шәрехләү мөмкинлеге бар. Укучыларга Мөхтәрнең матурлыкка карата булган мөнәсәбәтен ачыклау максатыннан әлеге репликасын таптырып, яңадан бер кат укытабыз:«Матурлык ул кайда да матурлык. Аңа мөнәсәбәт кенә төрлечә булырга мөмкин, - ди ул һәм дәвам итә,- Матурлык күпме кешене иҗатка илһамландыра, күпме җырлар җырлана матурлык турында».

Бу урында Дилбәр белән Мөхтәрнең фикерләре туры килми. Әсәрдәге төп конфликт әлеге каршылыктан гыйбарәт. Дилбәр тормышында уңышсыз тәҗрибә аның дөньяга карашын үзгәртә. «Ә минем гүзәллегем үзен-үзе саклый алмый бит. Аны саклар өчен, янәшә ниндидер көч булырга тиеш. Ә ул көч ямьсез генә була ала».

Әсәрдә матурлык һәм матди байлык каршылыгы тагын бер вакыйгада ачык күренә. Дилбәрнең апасы Рания эшмәкәр ире Әүхәт белән шушы тирәдәге

фикерләренең капма-каршы килүе сәбәпле аерылыша. Әүхәт шушы мәсьәләдә Мөхтәр белән дә сүзгә керешә. Аның фикеренчә, Әүхәт алып кайткан азык-төлек Мөхтәр ясаган рәсемнәрдән күпкә мөһимрәк, ягъни кеше рәсем, җыр-биюсез тора ала, ә ашамыйча тора алмый. Мөхтәр бу фикергә каршы килми, әмма иҗат, культура төшенчәсенең киң булуын, аңа кемнең нинди мәгънә салуына бәйле булуын аңлата. Әлеге бәхәстә ул культураның тотып карап була торган сәнгать үрнәге генә булмавын, бәлки кешенең күңел халәте дә булуын яклап чыга.

3. Хәким төп герое Дилбәрнең дөньяга карашы үсүенә ярдәм итәрлек танып белүнең баскычларын, кичереш һәм уйларының чылбырын сурәтли, эчке фикерләү үсешен күзәтә. Язучы Дилбәрнең тормышындагы иң тотрыксыз бәйләнешләрне дә, иң кечкенә кисәкчәләрне дә күрсәтә, аларның тоташуын һәм үзгәрүен игътибар үзәгенә куя.

Дилбәр образының әсәрдәге антиподлары Әсәд һәм Нәҗиб. Дилбәр табигать, сәнгать, кеше күңеле матурлыгын күрә белә. Дембель Әсәд исә көн саен исерек, Дилбәрне нахакка гаепләп йөрүдән башка эше юк. Авторегетнең түбән җанлылыгын, эчке культурадан мәхрүм булуын үз-үзен тотышы, сөйләме аша тасвирлый. Аның да Дилбәргә карашы Әүхәтнең Раниягә карата булган карашлары белән туры килә, ягъни алар икесе дә сөйгән ярларына шәхси милеккә караган кебек карый.

Бу урында автор сәнгатькә бөтенләй үзгә карашлы герой – Ләйләне кертеп җибәрә. Ләйлә – Мөхтәрнең хатыны. «Тормышта, чынбарлыкта сәнгать – күз явын алырдай, күңелне яулардай ямьле ялган, - ди ул.- Үзең иҗат итеп, шул сәнгатьтә үзең яшәсәң генә ул мәгънәгә ия. Ә сәнгатьне күзәтүчеләр үзләрен үзләре алдыйлар Йөз кешенең ничәсе аңлый икән картинаны?» Әлеге ханымның күңел борчулары, тулы канлы гаилә бәхетен таба алмавы сәнгатькә мөнәсәбәтен, карашын билгели, күрәсең. Сәнгать тирәсендә ясалмалылык, алдау, кылану бик күп, ә болар артында исә һәр кешенең эгоистик асылы, чынбарлыктагы күңеленә хуш килгән нәрсәләрне үзенең милке итү теләге ята дип саный ул. Ләйләнең әлеге фикерләренә ачык караш белдерелми, шулай да Дилбәр белән диалогы ахырында аңа ачыклык кертелә. Дилбәрнең «Сез бәхетлеме?» дигән соравына Ләйлә «Моннан утыз ел элек Мөхтәр ясаган сурәтемдә бәхетле» дип җавап бирә эчке сыкрануын яшермичә [Закирҗанов, 2012: 6].

Шул рәвешле, әлеге әсәрдәге геройларны сәнгатькә мөнәсәбәтле өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин: сәнгать сөючеләр, аны өнәмәүчеләр һәм сәнгатькә ышанмаучылар. Гыйбрәтле язмышларга ия геройларны тудыру аша автор әсәрендә төп фикерне әйтергә тели: әлеге кешеләрнең берсе дә бәхетле түгел. Шулай да әсәр ахырында өмет-ышаныч рухы көчәя. Ул, билгеле, Дилбәр белән бәйле. Чынбарлык дорфалыгына, тупаслыгына сәнгать матурлыгын каршы куеп, кешеләрне яктырак, чистарак итәргә омтылган яшь кыз авылның әлеге караңгылыгыннан китәргә карар кыла. Апасы Рания әйткәнчә, аның «бәхеткә лаеклы булуы – үзе бәхет ләбаса».

З. Хәкимнең аерым әсәрләрен өйрәнгән чакта аларны үзаллы гына түгел, ә гомуми-тарихи һәм әдәби фонда тикшерелергә тиеш дип саныйбыз, ягъни хәзерге татар әдәбияты кыссаларында аңлатылырга, шәрехләнергә.

Әсәрләрне тикшерү барышында түбәндәге эшләр башкарылырга тиеш:

- әсәрнең барлык компонентларын исәпкә алып, һәрьяклап тикшерү; иҗат итү тарихын өйрәнү (әсәргә нигез булган тормыш материалын ачыклау, прототипларны билгеләү, типиклаштыру принципларын күрсәтү һ.б.);
- әдәби комментарийлар яки аңлатмалар язу (ул гадәттә томнарга, җыентыкларга карата языла);
- текстологик анализ (басылып чыккан әсәрне кулъязмалар белән чагыштырып карау, төрле вариантларын чагыштыру, күчермәләрен өйрәнү һ. б.);
- аерым образларын тикшерү (авторның образ өстендә эшләве, образга характеристика, сурәт тудыру чаралары);
- әсәрнең художество үзенчәлекләрен тикшерү (сюжет-композициясе, поэтик теле, образлылык һ.б.);
- әсәрне нинди дә булса яңа иҗат методын формалаштырудагы роле ноктасыннан карап тикшерү;
- әдәби тәнкыйть һәм әдәбият фәне өлкәсендә әсәрне өйрәнү йомгакларын барлау. Әлеге барлык таләпләр дә үтәлгән чакта гына укучыларда әдәби әсәр турында ныклы белемнәр булдырылачак һәм эстетик, әхлакый тәрбия биреләчәк.

Дәреслектә бирелгән драма әсәрләрен укучы башка эпик әсәрләрне анализлый белгән кебек анализлый белергә тиеш. Моның өчен драма әсәрләрен төрле чорлар, вакыйгалар агышы, аларның әдәбият һәм сәнгать үсешенә йогынтысы турында мәгълүмат белән үреп бирергә, һәр әсәрнең театр тарихы һәм драматургиядә тоткан урынын аңлатырга, укучыларда теоретик белемнәр формалаштырырга кирәк. Укучылар драма әсәрләрендәге образлар системасын характерлый, сюжет элементларын табып, анализлый белергә тиеш.

З. Хәкимнең пьесаларын татар әдәбиятындагы башка әдәби әсәрләр белән янәшә куеп, параллельләр үткәреп өйрәтүне кулай күрәбез. Аның әсәрләрендә заманыбызның иң актуаль темаларының берсе булган – эстетик тәрбия темасы күтәрелә. Укучының эстетик зәвыгын тәрбияләү – әдәбиятның төп максаты. Бүгенге көн кешеләрен тәрбияләүдә З. Хәким әсәрләре зур роль уйный: ул укучыны эстетик, әхлакый сыйфатларны югалтмаска, төрле киеренке вакыйгаларда да Кеше булып кала белергә өйрәтә, өнди.

**Әдәбият**

Әдәбият. 7 сыйныф : татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 2 кисәктә. 2 кисәк / Д.М. Абдуллина, Л.К.Хисмәтова, Ф.Х. Җәүһәрова. – Казан : Татар. кит. Нәшр., 2017. – Б. 137-169.

Закирҗанов Ә.М. Эзләнү юлында (З.Хәкимнең соңгы еллар иҗатына бер караш) // Казан утлары.– Казан, 2012. – Б. 31-43.

*Шакирова Гөлнара Расиховна*
*Shakirova Gulnara Rasikhovna*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Садикова Светлана Максутовна*
*Sadikova Svetlana Maksutovna*
МАОУ “СОШ 18”
Казан, Россия
*Мөхәммәтҗанова Динә Марсиловна*
*Mukhametzyanova Dina Marsilovna*
Казан милли тикшеренү технологик университеты
Казан, Россия

# ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ КРЕАТИВ МЕТОДЛАР КУЛЛАНУ (CREATIVE WRITING МИСАЛЫНДА)
# THE USE OF CREATIVE METHODS AT THE LESSONS OF THE NATIVE LANGUAGE (ON THE EXAMPLE OF CREATIVE WRITING)

Аннотация. *В статье рассматриваются некоторые аспекты применения элементов креативного письма на уроках родного (татарского) языка.*

Abstract. *The article deals with some aspects of the use of elements of creative writingat the lessons of the native (Tatar) language.*

Ключевые слова: *родной язык, письменная речь, креативное письмо*

Keywords: *native language, written speech, creative writing*

Бүген лингвометодика укучыларның сүзлек байлыгын арттыруга, бәйләнешле сөйләм телен үстерүгә, сөйләм эшчәнлеген активлаштыруга һәм телне өйрәнү процессын стимуллаштыруга йөз тотучы уку-укыту методларын, алымнарын, алдынгы педагогик технологияләрне куллануның әһәмиятен ассызыклый һәм ФДББС шартларында шәхес үсешенә, регулятив осталыкка, танып-белүгә, телдән һәм язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерүгә кагылышлы эш-гамәлләр уздыру нәтиҗәлелеген күрсәтә.

Әлеге мәкалә кысаларында туган тел дәресләрендә укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен үстерү мәсьәләсе яктыртыла. Язу, сөйләм эшчәнлегенең дүртенче төре буларак, эзлекле рәвештә башка төрләр белән дә тыгыз бәйләнгән. Язма сөйләм үзенең тулылыгы, аныклыгы, җәенкелеге белән аерылып тора.

Татар теле дәресләрендә укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерү максатыннан creative writing (креатив язу) элементларын куллану укучыларның креативлыгын, иҗади мөмкинлекләрен ача, тәнкыйди фикер йөртә алу сәләтен үстерә, танып-белү эшчәнлеген активлаштыра, телне өйрәнүне мотивлаштыра. Практикада күренгәнчә, укучылар язма эшләрне башкарырга яратмыйлар. Аларны язма эшкә тарту, кызыксындыру максатыннан дәрестә креатив язу элементларына мөрәҗәгать итәргә мөмкин [Макарова, 2016: 29].

Креатив язуның асылында ятучы креативлык төшенчәсе «яңа идеяләр булдыруга сәләтле, традицион фикерләү схемаларына буйсынмаган» дигәнне аңлата [Левинзон, 2014: 26]. Креатив фикер йөртү нәтиҗәсендә гадәти булмаган фикерләр туа,проблемаларның яңача чишелешләре ачыла. Дәрестә креатив язу алымы язма сөйләмнең стандарт булмавын, төрле ситуацияләрдә көтелмәгән чишелешләрне, бай күзаллауларны, юмор хисен таләп итә. Креатив биремле язма эшләр (язма җавапка этәрүче, стимуллаштыручы әдәби әсәрләрдән өзекләр, әдәби персонажларның репликаларын тәкъдим итү һ.б.) укучыларны кызыксындыру, мотивлаштыру, аларның иҗади сәләтләрен ачуга ярдәм итүне максат итеп куя.

Туган тел дәресләрендә креатив язуны оештыру буенча берничә эш төрен күрсәтеп китик.

1. «Кем? Кайда? Нәрсә?»

Һәр укучыга төрле төстәге карточкалар өләшенә. Һәр төснең үз соравы була: Кем? / Кайда? / Нәрсә? (Ни өчен? Кайчан?). Укучылар төсләргә туры килүче сорауга җаваплар язалар. Мәсәлән: кеше исеме (Кем?), эш-хәлнең урыны (Кайда?), детектив, әкият, шигырь, реклама (Нәрсә?) һ.б. Алга таба барлык карточкалар бергә җыела һәм укучылар һәр төстән берәр карточка тартып алып үзенә эләккән сүзләрдән хикәя төзи, язма эш башкара.

2. «Эмпатия»

Укучыга әйләнә-тирә табигать күренешләре ролен уйнап карарга, песи, яңгыр, салават күпере, торнадо һ.б. булып үзе турында беренче заттан хикәя төзергә, үзенә хас сыйфатларны, фигыльләрне һ.б. санарга тәкъдим ителә.

3. «Прогнозлаштыру»

Укучыларга сюжетлы рәсем һәм түбәндәге сораулар бирелә: 1). Рәсемдә сез нәрсә күрәсез? 2). Бу рәсем сездә нинди хисләр уята? 3). Рәсемгә карагач, сезнең нәрсә турында беләсегез килә? Кыска вакыт эчендә укучылар җавапларын язалар. Яки рәсемдә сурәтләнгән образларның кәефен, әлеге кәефнең сәбәпләрен һ.б. ачыклыйлар.

Креатив язу кысаларында хикәянең башын яки ахырын уйлап язу, теге яки бу ситуацияне төрле герой күзлегеннән чыгып сурәтләү, герой булып фикер йөртү, бирелгән репликалардан диалог төзү кебек эш төрләре дә башкарылырга мөмкин.

Креатив язу барышында язуның өч нигезе дә (фонетик, морфологик, график) тормышка ашырыла, укучылар хәл-вакыйгаларны хикәяләргә, аларны тәнкыйди күзлектән бәяләргә, үз фикерләрен төгәл, образлы итеп язма рәвештә әйтеп бирергә, сүз һәм фразаларны урынсызга кабатламаска, төрле төзелешле җөмләләр кулланырга, чагыштыру, сынландыру кебек сурәтләү чараларын урынлы файдаланырга өйрәнәләр.

**Әдәбият**

1. Левинзон А.И. Креативное письмо: модель англоязычных стран в российской школе // Вопросы образования. – 2014, № 1. – С. 25-45.

2. Макарова Ю.А. Методика креативного письма для создания поэтических произведений на иностранном языке // Сибирский педагогический журнал. – 2016, № 1. – С: 25-30.

*Шәйхетдинова Айгөл Фидаэлевна*
*Җамалетдинова Гөлнара Фәндәсовна*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Shaikhutdinova Aigul Fidaelovna,*
*Zamaletdinova Gulnara Fandasovna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

# ТАТАР ДӨНЬЯ ТЕЛ СУРӘТЕНДӘ «ҖИЛ» КОНЦЕПТЫ
# CONCEPT WIND (ZHIL) IN THE TATAR LANGUAGE PICTURE OF THE WORLD

Аннотация. *В данной статье рассматриваются и выделяются ассоциативные ряды, репрезентирующие парадигматические связи концепта ветер на основе фольклорного материала татар*.

Annotation. *This article discusses and highlights the associative series, representing the paradigmatic connections of the concept wind (zhil) based on the Tatar nation folklore*.

Ключевые слова: *фольклор, концепт, ветер, ассоциативные ряды.*

Keywords: *folklore, concept, wind, associative series.*

Хәзерге вакытта лингвистика өлкәсендә тел һәм иҗтимагый-мәдәни процессларны комплекслы өйрәнү юнәлеше актив. Лингвокультурологиянең төпбурычы булып тел һәм мәдәниятнең, тел һәм этносның, тел һәм милли менталитетның мөнәсәбәтен өйрәнү, сурәтләү, анализлау тора. Чыннан да, телнең нигезе булган лексик берәмлекләр үзеннән-үзе яши алмый. Һәрбер төшенчә кеше, милләт аны атаганда, күз алдына китергәндә яши. Аерым бер кешенең, җәмгыятьнең дөньяны күзаллавы, аңлавы үзенчә. Моңа тормыш-көнкүреш, гореф-гадәтләр, дини карашлар, менталитет, географик урнашу тәэсир итә. Билгеле бер күренешкә төрле җәмгыять, милләт вәкиле төрле бәя бирә, аның аңында ассоциация, төрле бәйләнешләр туа. Шул ассоциацияләр, күренешләр милли дөнья сурәтен хасил итә.

«Милли дөнья сурәте» термины В.Фон Гумбольтның телнең эчке формасы турындагы идеяләренә һәм Америка лингвсты Сепир-Уорфның лингвистик нисбәтлелек гипотезасына барып тоташа.

В.фон Гумбольт беренчеләрдән булып телнең һәм фикерләү кануннарының милли эчтәлегенә игьтибар иткән. Төрле телләр милләтнең оригиналь, үзенчәлекле фикерләү һәм кабул итү органы булып тора дип билгели ул. Һәр кешедә билгеле бер предметка карата субъектив образ туа һәм бу образ башка

кешенекенә тулаем тәңгәл булмый. Әлеге күзаллау бары сүздә генә объективлаша ала. Шулай итеп, сүз билгеле бер кысалар эчендә аермалыклары булган субъектив күзаллаулардан тора. Бу субъектив күзаллауны милли характер һәм милли аңга ия булган билгеле бер тел коллективындагы кешеләр тудыра. Әлеге галим фикеренчә, нәкъ менә тел төшенчәләр һәм кыйммәтләр системасының формалашуына тәэсир итә [В. фон Гумбольдт 1985: 324].

Хәзерге вакытта милли дөнья сурәтенең төп төшенчәләренең берсе булып концептны аерып чыгарып була.

Д.С. Лихачев фикеренчә «Концепт сүзнең сүзлектәге мәгънәләрендә генә ачылмый, әлеге мәгънә – кешенең шәхси һәм этник, милли тәҗрибәсе кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килә» [Лихачев 1993: 4].

Халыкның тормыш тәҗрибәсе аның фольклорында – мәкаль-әйтемнәр, йолалар, җырлар, әкиятләрдә, ышануларда, сынамышларда, фразеологик берәмлекләр, гореф-гадәтләрдә ныклы сакланган. Әлеге мәкаләдә без «җил» концептының татар фольклоры үрнәкләрендә чагылышына кыскача күзәтү ясарбыз, ассоциатив рәтләрен аерып чыгарырбыз.

Җил – атмосфера басымы үзгәрүе нәтиҗәсендә җир өстендә барлыкка килгән һава агымы хәрәкәте; нәрсәнең дә булса тиз хәрәкәте белән барлыкка килгән һава дулкыннары.Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә «җил»гә бирелгән аңлатма шундый.Шулай ук 3 төрле күчерелмә мәгънәсе дә бирелгән. Ягъни җил ул – нинди дә булса берәр хәл яки вакыйганың башлангыч билгеләре, үзгәреш;нинди дә булса эш, хәл, вакыйганың барышы; нәрсәнең дә булса көчле тәэсире, шаукымы [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге 2016:325].

Ләкин моннан тыш, концепт буларак өйрәнгәндә, аның башка мәгънәләрен дә аерып чыгарып була.

Татар теленең этимологик сүзлегендә *җил –»ветер; невидимый дух»*. Җил < җәл, җәл образлы-имитативйәл//йал//чал//сал//тал тамырыннан; бу тамыр кискен, җитез хәрәкәт һәм яктыртылышларны белдерә (*җил-җил атлау, җилт-җилт хәрәкәтлән,җәлт кенә карап алу һ.б.*) [Әхмәтьянов 2015: 254-255].

Фольклор үрнәкләрен һәм матур әдәбият әсәрләрен тикшергәннән соң, җил концептының парадигматик бәйләнешен түбәндәге ассоциатив рәтләр ача:

Җил – тере җан иясе ассоциативы. Халыкта җилнең барлыкка килгән урыны, «яшәгән» урыны да бар дигән ышану да булган: *Яман җилләр җиде юл чатында, тауларда, кыяларда хөкем сөрә*. Борынгы төрки мифологиядә «җил» шаян, шук, көчле, сугыш чукмары кебек персонажны символлаштырган. Җилнең кыяфәте, сурәте юк, шулай да кайбер мифларда аны йөгәнсез атка охшаталар. Төркиләрдә җиңел холыклы кешеләр һәм атлар турында «*җилдән туган*» дигән әйтем булган. Татар телендә исә никахлы гаиләдә тумаган бала турында «*җилдән туган*», никахсыз бала тапкан хатын турында «*җилдән тапкан*» диләр. Җилбәзәк дип җиңел холыклы, тормышка җиңел карый торган, иләс-миләс кешеләрне атыйлар – әлеге сүзнең килеп чыгышы да алдагы мәгънәгә барып тоташа.

Җил – мәҗүси алла ассоциативы. Борынгы төрки сүзлектә *jel tdŋrï* (Җил Тәңре) искә алынган. Җил Тәңрене чакыру өчен билгеле бер ритуаллар, йолалар булган. Хәзерге вакытта әйтемнәрдә, ышануларда әлеге чакыру элементы сакланган. Халыкта әле дә «*сызгырсаң, җил чыга*», «*өйдә сызгырсаң, җил ыжылдап торыр*» диләр.

Җил – тынычлык, иминлек ассоциативы *(җылы җил, бәхет җиле, тынычлык җиле, бәрәкәтле җил).*

Җил – сугыш, кайгы-хәсрәт ассоциативы *(сугыш җиле, кайгы җиле, хәсрәт җиле, кара җил, «Җил – хәбәр ул: ач үлемнең куркусыннан ил җылый!»).*

Җил – тормыш-көнкүреш рәвешен билгеләүче фактор ассоциативы *(җил капка, җил тегермәне, җил капчыгы).*

Җил – кешегә ярдәм итүче, иркәләүче ассоциативы (*«...Сәлимәкәй суга барган чакта // Җилләр сыйпап сөя башыннан ...», «Таң чыкларын җил үбә...»*).

Җил – арадашчы, хәбәр җиткерүче ассоциативы (*«хәбәреңне сал җилләргә», «җил йөгереп хәбәр йөртә», «таң алдында искән җилгә / әйтеп җибәр хәлеңне, хәлеңне...» һ.б.*).

Җил – зур көч ассоциативы *(«җил – ул галәм көче»; «Җил – ул Ходайның яратылышларының берсе»; «җил ул – дөньяның ике башлангычының берсе», «Яктылык акылында җил – Җир-Ананың сулышы»).*

Җил – ирек, ихтыяр ассоциативы (*«Җил – давыллар белән көрәште»).*

Җил – табигать матурлыгы ассоциативы, эстетик күзәтүнең предметы (*саба җиле, Рәйхан җиле, йомшак җил, талгын җил, зәңгәр җил, баллы җил, назлы җил, сөйкемле җил, иркә җил, илаһи җил, нечкә билле җил,җил шаяра, җил тирбәлә, җырлый, серләшә;*).

Җил – дәва бирүче көч ассоциативы. Авыру, зәхмәт, чирне, бозымны, күз тиюне өшкерү белән чыгарганнар. Әлеге ритуалының мөһим элементлары – дога, имләү, өрү. Димәк, явыз, көчле җил чир алып килсә, аңа каршы әкрен җил, өрү чирне кешедән чыгара дип ышанганнар. Халык куллана торган ырым, им-том, әфсен-төфсен тезмәләрендә дә җил еш кына чир, авыру, төрле зәхмәтләрне юкка чыгаручы, таратучы образ буларак ачыла: «*бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде – / җилгә китсен*!» һ.б.

Җил – тавыш, аваз ассоциативы. Без аның тәэсирен, көчен генә сизәбез, тавышын ишетәбез. Татар халык җырларында еш кына «*җилфер-җилфер*», «*җилбер-җилбер*» кебек яңгырашын күзәтәбез: *«җилфер дә җилфер, әй, җил исә // җитен тамырларын җир кисә»; җил елый, үкерә, сызгыра, өрә,авазлар чыгара,шаулый, чиный, җыр көйли).*

Җил – билгеле бер функция үтәүче ассоциативы (*җил исә, уйный, ашый, күтәрелә,кабарта, күтәрә, төшерә, очыра, себерә, ега, сөрә, өстери, ыжгыра, бәреп керә, камчылый, куып китерә, тарата, кага, этә, зәһәрләнә, шомарта, җилфердәтә, йолкына, коя, сарыла, оча; җил оясы, җил уңае һ.б.).*

Җил – салкын, эссе, түбән яки югары һава торышы, табигатьнең кискен үзгәреше ассоциативы*(төньяк җиле, җәйге җил, язгы җил, көзге җил, кышкы*

*җил, салкын җил, ачы җил, тыгыз җил, ярсу җил, каты җил, утлы җил, кайнар җил, зәһәр җил, әшәке җил, үзәккә үтә торган җил, үтәли тишә торган җил).*

Җил – кеше тормышына зыян салучы, хәвеф-хәтәр китерүче, авыру, чирләр таратучы. Борынгы төрки сүзлектә дә «җил» JEL сүзенең 2 мәгънәсе бирелгән. Аның беренчесе – физик күренеш, икенчесе– явыз көч. Борынгы төрки сүзлектә бирелгән *jel tart* сүзтезмәсе – җилнең бәрүе авыруга, чиргә китерә дигән мәгънә йөрткән [Древнетюркский словарь 1969: 254]. Хәзерге вакытта татарларда да мондый ышану бар. Салкын, үтәли җил бәрүе аркасында авырулар барлыкка килсә, *«җил бәргән»* диләр. Җил кагылу – нәрсәнеңдер тәэсире, йогынтысы булу.*»Җил җелеккә үтәр»* әйтеме җилнең кеше организмының үзегенә кадәр үтеп керә алуы, зарарлый алуы хакында. *«Битне җил ашавы»* бит тиресенең кубалаклануы, кибүе, ярылуына китерә.

Җил – юкка чыгаручы ассоциативы. *«Карашлар аерылса, мәхәббәт җилгә оча», «үпкән-кочкан җилгә очкан, өстенә үскән үлән», «җилгә каршы җикеренмә, сүзең бушка китәр».*

Җил – җимерүче көч ассоциативы (*«җил тотканнан җилгә очыралар», «җирдән аерылган җилгә оча»; Җил туздыра, җимерә, сындыра;пырдымсыз җил*).

Җил – образлар ассоциативы (*«Мардышана – җил алласы», «Җил-малай», «Җил кызы», «Җил иясе»).*

Җил – юклык, бушлык ассоциативы. Җил күзгә күренми, аның төсе, исе юк.*» Илгә ышанган – җилгә ышанган», «ага булыр егетнең әйткән сүзе им булыр // булыр-булмас егетнең әйткән сүзе җил булыр», «карт кеше җилгә сүз сөйләми»*мәкальләре әлеге фикерне дәлилли.

Матур әдәбият әсәрләрендә җилнең «органнары бар» *(җил йөрәге, җил күзе, җил тырнагы, җил сулышы).*

Әлеге мәкаләдә без «җил» мисалында лингвомәдәни тикшеренүләрнең әле бер өлешенә генә тукталдык. Татар халкының фольклор материаллары һәм матур әдәбият әсәрләрен өйрәнеп, без «җил» турында шактый материал тупладык, аның ассоциатив рәтләрен аерып чыгардык.

**Әдәбият**

Әхмәтьянов Р. Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А-Л). – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. – 543 б.

Древнетюркский словарь. – Ленинград: Наука, 1969. – 677 с

Гумбольд В. Избранные труды по языкознанию. – М.: Наука, 1984. – 450 с.

Лихачев Д.С. Концептосфера русского языка // Изв. РАН – СЛЯ. 1993. – №1. – С. 3-9.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: II том: Г-Й. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – 748 б.

*Шәкүрова Мөслимә Магесумовна*
ТР ФА нең Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
*Shakurova Muslima Magesumovna*
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan
Kazan, Russia

# КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ ГАЛИМНӘРЕНЕҢ ФӘННИ-МЕТОДИК МИРАСЫ: ФӘРИТ ЙОСЫП УЛЫ ЮСУПОВ
# SCIENTIFIC AND METHODICAL HERITAGE OF SCIENTISTS OF KAZAN UNIVERSITY: FERITS YUSUPOVICH YUSUPOV

Аннотация. *В статье содержится обзор научного наследия доктора филологических наук, профессора Ф.Ю. Юсупова. Основное внимание уделяется анализу лингвометодических трудов ученого. Выявлена роль Ф. Юсупова в истории национального образования РТ.*

Annotation. *The article is devoted to an overview of the scientific heritage of Doctor of Philology, Professor F.Yu. Yusupov. The main attention is paid to the analysis of the linguistic and methodical works of the scientist. The role of F. Yusupov in the history of national education of the Republic of Tatarstan is revealed.*

Ключевые слова. *Татарский язык, методика преподавания, Ф.Ю. Юсупов, коммуникативные способности учащихся, речевая деятельность, образовательные технологии современности.*

Keywords. *Tatar language, teaching methods, F.Yu. Yusupov, communicative abilities of students, speech activity, educational technologies of our time.*

Филология фәннәре докторы, профессор, халкыбызның күренекле тел галиме Фәрит Йосып улы Йосыпов үзенең бөтен эшчәнлеген Россия һәм чит төбәкләрдә таралган татар сөйләшләрен өйрәнүгә, татар телен балалар бакчаларында, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укытуга багышлады.

Фәрит Йосыпов Татарстан Республикасының Яшел Үзән районы Зур Карауҗа авылында туа. Әтисе һәм әнисе тирә-якта иң игелекле һәм абруйлы кешеләрнең берсе була. Әтисе Камалиев Йосыф Камали улы сугышта батырларча һәлак була, әнисе Мөхәммәдшакирова Асия Мөхәммәтшакир кызы берсеннән-берсе кечкенә сабыйларны берүзе тәрбияләп үстерә. Кечкенә Фәрит әтисез үссә дә, аңа ике дәү әтисе - Шакир һәм Камали бабайлар тарафыннан ата тәрбиясе һәм күңел җылысы насыйп була. Балачактан туган авылының тарихы, шушы төбәккә хас булган тел үзенчәлекләре, этнографиясе белән кызыксына. Зур Карауҗа урта мәктәбен тәмамлагач, Фәрит абый 1956 - 1961 елларда Казан дәүләт университетвның тарих-филология факультетында укый. 1972 елда - «Көньяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре» дигән темага кандидатлык, 1988 елда «Татар фигыльләрен ареал

ысул белән өйрәнү» дигән темага докторлык диссертацияләрен яклый. Ул татар теленең диалектологик атласын төзүгә зур өлеш кертә.

Фәрит Йосыпов фәнни эшчәнлеген 1962 елда СССР Фәннәр Академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтында фәнни хезмәткәр буларак башлап җибәрә. 1972-1984 елларда Алабуга педагогия институтында чит телләр факультеты деканы, 1984 - 1996 елларда Россия Мәгариф министрлыгының Милли мәгариф проблемалары институты Татарстан филиалы директоры булып эшли. Бу елларда беренче тапкыр профессор Ф.Й.Йосыпов җитәкчелегендә татар һәм рус балалар бакчалары өчен дә, рус мәктәпләренең I-IV сыйныфларында укучы рус телле балалар өчен дә программалар, «Гөлбакча» [Йосыпов, 1990] һәм «Балалар бакчасы» дигән хрестоматияләр [Йосыпов, 2002], рус телендә сөйләшүче балалар өчен «Татарский букварь - Әлифба» [Йосыпов, 1994], татар теле дәреслекләре һәм методик кулланмалар, сүзлекләр, фонохрестоматияләр һ.б. басылып чыга. Бу хезмәтләр рус мәктәпләрендә укучы татар балаларын - ана теленә, рус телендә сөйләшүче балаларны татар теленә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия булды.

Проф. Ф.Й. Йосыпов җитәкчелегендә татар балалар бакчалары өчен чыккан хрестоматия - «Гөлбакча», «Балалар бакчасы» - балаларга кече яшьтән үк ана телендә тәрбия бирүдә зур роль уйнады. Бу китаплар Татарстан АССР Халык мәгарифе министлыгы тарафыннан расланган «Балалар бакчасы һәм гаилә өчен ана теле программасы» (Ф.Й.Йосыпов, 1986; 1988) нигезендә төзелгән. Әлеге хрестоматияләрдә тупланган материаллар, нәфис сүз әсәрләре биш группаны да күз уңында тотып эшләнгән: «Нәниләр авазы» (1-2 яшьтәге балалар өчен), «Беренче адым» (2-3 яшьтәгеләр өчен), «Үсә барабыз» (3-4 яшьтәгеләр өчен), «Без инде зур үстек» (4-5 яшьтәгеләр өчен), «Хуш инде, гөлбакча!» (5-6 яшьтәге балалар өчен). Хрестоматияләрдә тәкъдим ителгән халык авыз иҗатыннан алынган иң матур җырлар, әкиятләр, такмаклар, табышмаклар, мәкаль һәм әйтемнәр, уеннар, әйтешләр, тел көрмәкләндергечләр, тел шомарткычлар, сынамышлар һәм эндәшләрдән тәрбиячеләр дә, ата-аналар һәм студентлар да, бик яратып, дистәләгән еллар файдаланды. Хрестоматиянең ахырында бирелгән иллюстрацияләр балаларның сөйләм телен үстерүдә, баетуда кыйммәтле чыганак булып торды. Гомумән, әлеге хрестоматияләр халык авыз иҗаты җәүһәрләре - татар милли педагогиканың тутыкмас әсәрләре җыелган, шулай ук язучы һәм шагыйрьләребезнең нәкъ менә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп сайланган гүзәл әсәрләре бирелгән, бәйрәм, юл йөрү кагыйдәләре, ел фасыллары һ.б. бик кирәкле мәгълүматлар тупланган. [Йосыпов, 1990]

XX гасырның 90 еллар башындататар телен укытуның сыйфатын күтәрү, башлангыч сыйныфтан башлап туган телне тирәнтен үзләштерү, сөйләмне дөрес төзеп, әдәби тел нормаларына туры китереп, телдән һәм язма рәвештә башкаларга җиткерә белү, татар телен рус теле белән чагыштырып өйрәтү - уку-укыту мәсьәләләреннән иң мөһиме булып тора. 20 гасыр башларында

М.Х. Корбангалиев, Р.С. Газизов, Х. Бәдигый, М.Ә. Фазлуллиннарның тәҗрибәсен истә тотып, Ф.Й. Йосыпов татар теле дәреслекләрен бик уйлап эшли: текстлар белән эшләү, сүзлек эше, грамматик материалны үзләштерү, сәнгатьле уку, грамотлы итеп язу күнекмәләрен булдыру, иҗади характердагы күнегүләр белән эшләү һ.б. күз уңында тота. Галимне 1980-90 елларда педагогларның иң тәҗрибәлесе дип әйтергә тулы мөмкинлек бар. Әлеге елларда илдә барган иҗтимагый яңарыш мәгариф өлкәсенә, шул исәптән рус телле укучыларга татар теле укыту методикасы фәненә зур үзгәрешләр алып килде. Профессор Ф.Й. Йосыпов җитәкчелегендә рус телендә сөйләшүче балалар өчен иң беренче татар теле дәреслекләре чыкты. Алар арасында «Татар теле. 2 нче сыйныф өчен (рус телендә сөйләшүче балалар өчен» (1993) (З.А. Казыйханова, Р. Мөхиярова белән берлектә), «Татар теле. 3 сыйныф (рус телендә сөйләшүче балалар өчен)» (1993), «Әлифба» (1994), (Л.К. Новикова белән берлектә), «Әлифба» (1994), «Татар теле. 4 сыйныф. Рус телендә сөйләшүче балалар өчен» (1998) (В.З. Гарифуллин белән берлектә) дәреслекләре аеруча игътибарга лаек. Бу дәреслекләр үз заманында иң күренеле урын тоттылар, чөнки беркемнең дә бу өлкәдә әле тәҗрибәсе юк иде. Авторларның тәҗрибәсе зур, бай, материал кызыклы, дәреслекләр югары зәвык белән, төгәл, матур итеп эшләнгән.

Ф.Й. Йосыпов һәм Л.К. Новикова җитәкчелегендә төзелгән «Әлифба» татарча сөйләшергә өйрәтүне күздә тотып, телдән хәзерлек курсын, грамотага өйрәтү чорын һәм әлифбадан соңгы чорны үз эченә ала. Программада каралган темалар әлифбаның беренче өлешендә рәсемнәр белән бирелгән. Биредә һәр яңа сүз, коммуникатив компетенциягә нигезләнеп, сөйләмгә сорау-җавап диалогик һәм монологик күнегүләр ярдәмендә кертелә һәм активлаштырып барыла. Грамотага өйрәтү дәресләрендә татарча уку һәм язу күнекмәләре махсус күнегүләр, биремнәр ярдәмендә ныгытыла. Әлифбадан соңгы чорда кечкенә хикәя, экият һәм шигырьләр укыйлар, татар халык авыз иҗаты үрнәкләре белән танышалар, кыскача эчтәлеген сөйләп бирәләр. Авторлар, текстлар белән бәйләп, диалогик һәм монологик сөйләм үстерү күнегүләрен дә тәкъдим иткәннәр һәм бу, үз чиратында, әлеге китапның кыйммәтен тагын да арттырган. Ачык, матур итеп, рус телле балаларның барлык үзенчәлекләрен күздә тотып эшләнгән «Әлифба» белән бүген дә рус телендә сөйләшүче балаларны татар теленә өйрәтеп булыр иде.

«Татар теле. 2 нче сыйныф өчен (рус телендә сөйләшүче балалар өчен» (1993) дигән дәреслекнең эчтәлегенә килгәндә, ул унике бүлектән тора: «Исәнме, мәктәп!», «Туган җирем», «Алтын көз», «Әти-әни һәм мин», «Габдулла Тукай», «Безнең җырларыбыз» һ.б. Дәреслектә темаара бәйләнеш сакланган, билгеле бер эзлеклелек, системалылык бар. Дидактик принциплардан предметара бәйләнеш принцибына килгәндә, тел материалы этика, эстетика, культуралогия, ботаника, зоология, география һ.б. предметлар белән тыгыз үрелеп бара: мәктәптә, өйдә үз-үзеңне тота белү, йорт хайваннары турында кызыклы мәгълүматлар, Яңа ел бәйрәме, яз аеның серләре һ.б. Күнегүләр барысы да сөйләмә телне үстерүгә

корылган. Мәсәлән, егерме тугызынчы дәреснең («Безнең гаилә») төзелешен карап чыгыйк (51-52 нче битләр):

1. Прочитайте правильно:

*Әткәй, әнкәй, җидәү, җиденчесе, песи, безнең.*

2. Ответьте на вопросы.

*Сезнең гаиләдә кемнәр бар?*

*Сез өйдә ничәү?*

3. Разговор.
4. Прочитайте и запомните..
5. Скажите по-русски.
6. Вместо вопросов напишите нуңные слова.

Әлеге күнегүләр рус телле укучыны татар телендә аралашырга, сөйләшергә өйрәтүгә корылган.

Гомумән, Ф.Й. Йосыпов җитәкчелегендә төзелгән татар теле дәреслекләрендә авторлар телнең бөтен мөмкинлекләрен күзаллап, укучыны грамматик конструкцияләрдән файдаланырга өйрәтә, әдәбият белән бергә үреп бирә. Бу дәреслекләрдә тәкъдим ителгән иҗади характердагы күнегүләргә күзәтү ясап, таблицада аларны язма күнегүләр һәм сөйләм күнегүләренә бүлеп урнаштырдык [Шәкүрова, 2012]:

| **Язма күнегүләр** | **Сөйләм күнегүләре** |
|---|---|
| 1. Текстны тәрҗемә итү. | 1. Бирелгән сүзләр белән җөмләләр төзегез (телдән). Җ, ң, һ хәрефе кергән сүзләр белән эшләгез. |
| 2. Сорауларга тулы җавап бирү (язма). Җөмләләрне язып бетерү. | 2. Өйрәнелә торган әдәби әсәрдән синонимнарны табыгыз. |
| 3. Бирелгән сүзләрне кулланып, хикәя (җөмләләр) төзегез. | 3. Капма-каршы мәгънәдә булган сүзләрне табыгыз һәм дөрес итеп укыгыз. |
| 4. Омонимнар белән җөмлә төзегез (мәсәлән, «матур» сүзен «чибәр» һәм «ямьле» мәгънәләрендә куллану). | 4. Табышмакларның җавапларын табыгыз һәм аларны рус телендәгеләре белән чагыштырыгыз. |
| 5. Рәсемнәргә карап сорау бирегез һәм җавапларны языгыз. | 5. Җөмләләрне дәвам итегез. Рәсем буенча хикәя төзегез. |
| 6. Исем, сыйфат, рәвеш һәм алмашлыкларны кулланып, җөмләләр төзегез. | 6. Күрсәтелгән сүзләрне синонимнар белән алмаштырып, текстны сөйләгез. |
| 7. Бирелгән темага кечкенә хикәя языгыз. | 7. Күрсәтелгән сүзләрне берлек санга куеп, текстны сөйләгез: |

Таблицага карап шуны әйтеп була: язма күнегүләрдән «тәрҗемә итү, сорауларга тулы җавап бирү, күпнокталар урынына кушымчаларны, сүзләрне

куеп, җөмләләр төзү, кирәкле урынга фигыльләрне тиешле заманга, зат-санга куеп язу» кебек күнегүләр күбрәк кулланылса, сөйләм күнегүләреннән беренче чиратта «бирелгән сүзләр белән җөмләләр төзү яки җөмләләрне дәвам итү, рәсемгә карап, хикәя төзү, синонимнар, антонимнар белән эшләү» кебек күнегүләр күз уңында тотыла. Гомумән алганда, проф. Ф.Й. Йосыпов җитәкчелегендә рус телендә сөйләшүче балалар өчен чыккан татар теле дәреслекләре бик нык уйлап эшләнелгән: текстлар белән эшләү, сүзлек эше, грамматик материалны үзләштерү, сәнгатьле уку, грамотлы итеп язу күнекмәләрен булдыру, иҗади характердагы күнегүләр, сөйләм үстерү кунегүләре белән эшләү - барысы да җиренә җиткерелеп башкарылган. Бу китапларда сөйләмә һәм язма телләрне үстерү өчен, текст белән эшләү дә алгы планга чыгарылган.

Аның хезмәтләрен тикшереп чыкканнан соң, шуны әйтәсе килә: Фәрит Йосып улы Йосыпов – чын мәгънәсендә үз эшен белеп, яратып башкаручы методист, тел белгече, тәҗрибәле укытучы. Аның методик кулланмалары, мәктәп дәреслекләре бүген дә үрнәк булып торырлык. Ул тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уятуны һәм иң мөһиме – аңлап, дөрес итеп сөйләшергә, укырга һәм язарга, логик фикерләргә өйрәтүне, телнең психолингвистик үзенчәлекләренә игътибар бирүне дә таләп итә. Галимнең методик хезмәтләрен барлап, татар теле дәреслекләренә күзәтү ясап чыккач, шундый фикергә киләсең: ул – оста укытучы, методист һәм сизгер тәрбияче дә, иң тәҗрибәле педагогларныңберсе дип тә әйтергә тулы мөмкинлек бар.

**Әдәбият**

Йосыпов Ф.Й. Гөлбакча (Хрестоматия для татарских детских садов). – Казань: Татар. кит. нәшр., 1990. – 255 б. 10.

Йосыпов Ф.Й. Балалар бакчасы (Хрестоматия для татарских детских садов). – Казан: Раннур, 2002. – 650 б.

Йосыпов Ф.Й., Новикова Л.К. Алифба – Татарский букварь: Башлангыч мәктәпнең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек (Рус телендә сөйләшүче балалар өчен). – Казан: Мәгариф, 1994. – 114 б.

Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры - XX гасыр). – Казан: «Ихлас», 2012. – 144 б.

*Шәкүрова Мөслимә Магесумовна*
*Гиниятуллина Лилия Миңнулловна*
ТР ФА нең Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
*Shakurova Muslima Magesumovna*
*Giniyatullina Lily Minullina*
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan
Kazan, Russia

# «ТУГАН ТЕЛ (ТАТАР ТЕЛЕ)» ДӘРЕСЛЕГЕНДӘ ТӨРЛЕ ДӘРӘҖӘДӘГЕ БИРЕМНӘРНЕҢ ДИДАКТИК ТӨЗЕЛЕШЕ
# DIDACTIC CONSTRUCTION OF EDUCATIONAL TASKS OF DIFFERENT LEVELS OF COMPLEXITY IN THE NATIVE (TATAR) LANGUAGE

*Публикация осуществлена в рамках мероприятия 4.1.3. Государственной программы «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014-2020 годы»*

Аннотация. *Данная статья посвящена структуре заданий, включенных в учебники начальных классов по предмету «Родной (татарский) язык». Здесь анализируются продуктивные технологии, применяемые во время обучения. Их эффективность конкретизируется примерами заданий из учебников.*

Annotation. *This article is devoted to the structure of tasks included in primary school textbooks on the subject «Native (Tatar) language». It analyzes the productive technologies used during training. Their effectiveness is specified by examples of tasks from textbooks.*

Ключевые слова. *Родной язык, татарский язык, структура заданий, технология.*

Keywords. *The native language, the Tatar language, structureexercises, technology.*

Бүгенге көн кешесенең иң мөһим сыйфатлары булып актив аналитик фикерли белү, яңа иҗади эшләү юллары эзләү теләге, үзлектән белем туплау сәләте тора. Уку-укыту системасын үзгәртеп, аны яңартып, без күнеккән традицион укытуга алмашка икенче бер төрле – замана таләпләренә җавап бирерлек методлар, яңа технологияләр кирәк.

Әлеге гамәлләрнең бурычы – укыту барышын яңалыклар кертү бәрабәренә даими камилләштереп тору. Алар арасында модульле укыту технологиясе (Т.И. Шамова, П.И. Третьяков, И.В. Сенновский), үстерелешлеукыту технологиясе (И.С. Якиманская, Л.В. Занков һ.б.), уен технологиясе (Ш.А. Амонашвили, О.В. Канарская, Д.Б. Элъконин, Г.К. Селевко), проблемалы-эвристик укыту технологиясе(А.В. Хуторской, И.Я. Лернер, М.И. Мәхмүтов һ.б.), кечкенә төркемнәрдә укыту, проектлар укыту методы, мәгълүмат чаралары ярдәмендә укыту технологиясе (Е.С. Полат), алгоритмнар нигезендә мәгълүмат чаралары кулланып укыту технологиясе (Н.Н. Алгазина) һ.б технологияләр бар. [Шәкүрова, 2012]

ФДБС таләпләре буенча укучы дәреслектә эшчәнлекнең нәтиҗәсен, материалны үзләштерү дәрәҗәсен бәяләп барырга тиеш: «монысы – үземнеке, бу

– иптәшемнеке». Бала мөстәкыйль тикшерү алып бара, теманы үзе әйтә, йомгаклый, нәтиҗә чыгара, үзен-үзе бәяли.Укучылардан әледән-әле»Хаталы сүзне төзәтү», «Махсус хата ясау», «Мин нәрсәне беләм һәм нәрсә белмим?», «Нәрсә эшләнде?», «Эш ничек башкарылды?» кебек эш төрләренә җаваплар эзләтергә кирәк. Мондый биремнәрнең дәреслекләрдә булуы да шарт.

Мәсәлән: *Сүзләрдә хәрефләр буталган. Дөресләп яз.*

*такрун, нчмактакы, лытболы, кдыбылтбы.* [Шәкүрова, 2019: 56]

Дәрестә уен технологиясен куллану баланың фән белән кызыксынуын көчәйтә, мөстәкыйль эшләргә өйрәтә, ихтыяр көчен арттыра, зирәклеген, тапкырлыгын үстерә. Уеннар укучыны милли менталитет, фәлсәфә, үзаң, әхлак кануннары белән таныштыруны үз эченә ала. Уеннар сөйләм осталыгын үстерүдә һәм дөрес итеп сөйләшергә өйрәтүдә дә зур әһәмияткә ия. Бу өлкәдә Л.С. Выготский, А.А. Леонтьев, Д.Б. Эльконин, Г.К. Селевко һ.б. галимнәр тикшерүләр уздырган. Баланың логик фикерләвен үстерә, уку һәмязу күнекмәләрен камилләштерергә ярдәм итә торган уеннарбашлангыч сыйныф дәреслекләренә дә кертелергә тиеш.

Мәсәлән: *Башваткычны чиш.* [Шәкүрова, 2019: 70]




Уен технологиясенең роле һәм әһәмияте татар теленә өйрәтүнең барлык этапларында да бәхәссез.

Проблемалы укыту технологиясе XIX гасыр ахырында барлыкка килгән. Америка галиме Дж. Дьюнфәнни метод теориясенә һәм проблемалы ситуацияләргә нигезләнгән. Бу теория М.И. Мәхмүтов хезмәтләрендә тагын да үстерелә. [Гыйниятуллина, 2018: 54] Ул укучыларның акыл үсешендә, мөстәкыйльлеген формалаштыруда зур роль уйный. Проблемалы укыту ул – укытучының дәрестә проблемалы ситуация тудыруы, идеяне таптыруы, проблемалы сорау куя белүе һәм аны чишү юлларын эзләтүе. Проблемалы укыту проблемалы ситуацияләрне чишүгә юнәлтелгән эшчәнлек буларак карала, шуның нәтиҗәсендә яңа белемнәр үзләштерелә, күнекмәләр формалаштырыла, фикерләү үсә. Проблемалы укыту материалны проблемалы ситуацияләр формасында тәкъдим итүне сорый. Проблемалы ситуация укучыны активлаштыра торган эш-

гамәлләр ярдәмендә тудырыла. Укытучы укучыларны каршылыклы күренеш белән таныштыра, аны чишү юлын табарга тәкъдим итә.

Проблемалы ситуацияне чишү өчен, текстның идеясен табарга, фактларны билгеләргә, проблемалы сораулар куярга, шулардан чыгып проблемаларны чишү юлларын эзләргә кирәк.

Идея (гипотеза) Фактлар

(фактлар күп була)

1. 1. …

2. 2. …

3. 3. …

Проблемалы сораулар Чишелеш

(Идеядән чыгып, проблемалы сорау бирелә) (кыен ситуациядән чыгу юллары)

1. ... 1. ...

2. ... 2. ...

3. ... 3. ...

**Проблемалы ситуация**

Укучыларга түбәндәге текст тәкъдим ителә. Алар иң элек текстны татарчага тәрҗемә итәләр.

*Летом группа путешественников отправилась в полет на воздушном шаре. И в конце полета им пришлось идти на вынужденную посадку. Приземлелись они на поляне в незнакомом лесу. При аварийной посадке поломалась часть оборудования, в том числе разбился компас. Андрей, Саша (и Шарик) взглянули на часы, до заката солнца оставалось не больше часа. Но они помнили, что перед аварией мелькнул поселок в юго-восточном направлении.*

Сорау: Сез сәяхәтче урынында булсагыз, бистәгә юлны ничек табар идегез?

Идея (гипотеза)

1. Һава шарына утырып сәяхәткә чыгу бик куркыныч.
2. Сәяхәткә чыкканчы, оча торган шарның төзеклеген җентекләп тикшерергә кирәк.
3. Юлга чыкканчы, маршрутны алдан яхшылап өйрәнергә кирәк.
4. ...
5. ...

**Фактлар**

1. Һава шарында очу.
2. Туктарга мәҗбүр булу.
3. Таныш булмаган урман.
4. Җиһазның ватылган детале.
5. Кояш баерга бер сәгать вакыт калу.
6. Көньяк-көнчыгышта урнашкан бистә.
7. ...

**Проблемалы сораулар**

1. Ни өчен сәяхәтчеләр сәяхәткә чыкканда шундый төр транспорт сайлаганнар?
2. Юнәлешне компастан башка ничек билгеләп була?
3. Сәяхәтчеләр бистәгә юлны таба алмасалар, вакыйгалар ничек үзгәрер иде?
4. Әгәр дә ...?

**Чишелеш (ситуациядән чыгу юллары)**

Юнәлешне билгеләү үзенчәлекләрен өйрәнү:

- кырмыска оясына карап;
- үсемлекләрнең үсү үзенчәлекләренә, формаларына, урынына карап;
- кояшны күзәтеп;
- агачлардагы мүкләр буенча;
- йолдызларга карап;
- ...

Гомумән алганда, әлеге технология түбәндәге нәтиҗәләрне бирә:

1) Укучыларның акыл эшчәнлеге активлаштыра (барлыкка килгән кыенлыклар укучыларны уйланырга, куелган проблемалы ситуациядән чыгу юлын эзләргә мәҗбүр итә).

2) Туган кыенлыкны үзенә хәл итәргә өйрәтә (проблеманы үзлектән күрә белергә, проблемалы сорау куя белергә һәм проблеманы чишү юлларын сайларга өйрәтә);

3) Креатив фикерләргә этәрә (стандарт булмаган чишелешләр эзләү)

Туган тел дәресләрендә проблеманы тирәнтен өйрәнеп хәл итү, нинди дә булса мәсьәләне чишү юлларын эзләү, авыр ситуациядән чыгарга өйрәтү – иң уңышлы технологияләрдән санала.

Шулай итеп, белем алу барышын нәтиҗәле итү өчен, укучының эшен төрле күнегү һәм биремнәрне мөстәкыйль чишә алырлык итеп оештыру зарур.

**Әдәбият**

Башлангыч сыйныфларда «Туган тел» предметын укыту: яңартылган эчтәлек һәм перспективалар. Методик ярдәмлек / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина. – Казан, 2018. – 40 б.

Гыйниятуллина Л.М., Шәкүрова М.М. Туган телне укыту методикасының бүгенге көн проблемалары. – Казан: Вестфалика, 2018. – 119 бит.

Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр). – Казан: Ихлас, 2012. – 144 б.

Шәкүрова М.М. Туган тел. 1 сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов. – Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты, 2019. – 151 б.

*Юсупов Айрат Фаик улы*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Yusupov Ayrat Faikovich*
Kazan Federal University
Kazan, Russia
*Юсупова Нурфия Марс кызы*
Казан федераль университеты
Казан, Россия
*Yusupova Nurfiya Marsovna*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

# КИҢ КАРАШЛЫ ГАЛИМ (ТЕЛ ГАЛИМЕ Ф.Й. ЮСУПОВНЫҢ ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН)
# ЭРУДИРОВАННЫЙ УЧЕНЫЙ (К ЮБИЛЕЮ ЯЗЫКОВЕДА Ю.Ф. ЮСУПОВА)
# ERUDED SCIENTIST (ON THE ANNIVERSARY OF THE LANGUAGE STUDENT Yu.F. YUSUPOV)

Аннотация. *Статья посвящена изучению жизненной биографии и научно-педагогической деятельности Ф.Ю. Юсупова. Научная деятельность ученого рассматривается в ракурсе казанской лингвистической школы. В статье показано значение его научных трудов для развития тюркского языкознания.*

Annotation. *The article is devoted to the study of life biography and scientific and pedagogical activity of F.Yu. Yusupova. The scientific activity of the scientist is considered from the perspective of the Kazan linguistic school. The article shows the importance of his scientific works for the development of Turkic linguistics.*

Ключевые слова. *Фарит Юсупович Юсупов, татарское языкознание, научная деятельность, диалектный язык, диалект, система.*

Keywords. *Farit Yusupovich Yusupov, Tatar linguistics, scientific activity, dialect language, dialect, system.*

Ф.Й. Юсупов – филология фәннәре докторы, профессор, тел белгече, галим-диалектолог, ТРның атказанган фән эшлеклесе (2000), Төрек теле җәмгыятенең (Төркия – Әнкара) мөхбир-әгъзасы, Казан университетының атказанган профессоры (2009), күпсанлы мактау грамоталары, медаль, күкрәк билгеләре иясе, яшь белгечләргә фән дөньясына юл ярган Остаз, олпат шәхес ул.

Фәрит Йосыф улы Юсупов 80 ел элек – 1939 нчы елның 15 маенда Яшел Үзән районы Зур Карауҗа авылында дөньяга килә. Әтисе Камалиев Йосыф Камали улы, әнисе Мөхәммәдшакирова Асия Мөхәмәдшакир кызы аны кечкенәдән чын мәгънәсендә татар җанлы, иманлы-динле, мәгърифәтле кеше итеп тәрбияләргә омтылалар. 1956 нчы елда Зур Карауҗа унъеллык мәктәбен тәмамлаганнан соң, белемгә омтылган егет шул ук елны университетның тарих-филология

факультетына укырга керә һәм 1961 нче елда аны уңышлы тәмамлый. 1961-62 нче елларда ТРның Кама Тамагы районында чыгып килүче «Кызыл байрак» исемле район газетасында җаваплы сәркатип буларак сынап караганнан соң, язмыш аны урау юллар аша фән дөньясына кайтара. 1962-72 нче елларда Фәрит Юсупов Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында гыйльми хезмәткәр булып эшли, аспирантура үтә. Биредә ул фән юлына беренче адымнарын күренекле тел галиме Галимҗан Шәрәфнең фәнни мирасын өйрәнү, фәнни архивын эшкәртүдән башлап җибәрә, аның моңа кадәр билгеле булмаган яисә басылмаган «Татар теленең фонетикасы», «Татар сузык авазларының сонорлык озынлыгы (II кисәк)», «Революциядән соңгы чорда татар теле системасының үсеше» кебек хезмәтләрен эзләп табып, матбугатка әзерли.

1964 нче елдан Фәрит Юсупов татар теленең диалектларын лингвистик география һәм ареал лингвистика методларын кулланып өйрәнү белән шөгыльләнә башлый. Татар халкы күпләп яши торган Татарстан, Башкортстан, Удмуртия, Марий-Эл, Чувашстан Республикаларына, Курган, Чиләбе, Рязань, Тамбов, Түбән Новгород, Киров, Свердловск, Новосибирск, Омск, Төмән, Кемерово, Красноярск өлкәләренә фәнни диалектологик экспедицияләргә чыгып, халыкның җирле сөйләшләрен өйрәнә, бер үк вакытта аларны фәнни эшкәртү юнәлешендә дә эш алып бара. Булачак галим бу өлкәләрдә яшәүче татарларның тел үзенчәлекләренә, халык авыз иҗатына, этнографиясенә, тарихына кагылышлы гаять бай материал туплый һәм шулар низендә күп санлы фәнни мәкаләләр, монографияләр бастырып чыгара. Шушы эзләнүләрнең бер нәтиҗәсе буларак, 1967 елда Ф. Юсупов күренекле диалектолог Н.Б. Борһанова җитәкчелегендә «Көнъяк Урал һәм Урал арты сөйләшләре» дигән темага уңышлы төстә кандидатлык диссертациясен яклый. Курган һәм Чиләбе өлкәләрендә таралган, моңа кадәр татар тел белемендә билгеле булмаган сөйләшләрне өйрәнүгә багышланган әлеге хезмәте аны чит регионнарда формалашкан татар сөйләшләрен өйрәнүче галим буларак таныта, Милли, шулай ук төрки телләрнең Диалектологик атласларын төзүгә ныклы нигез булып тора.

Ф. Юсуповның 1972 нче елдан 1984 нче елга кадәрге гомер баскычы, эшчәнлеге Алабуга педагогия институты белән бәйләнгән: галим биредә татар теленнән лекцияләр укый, чит телләр факультетының деканы буларак җаваплы вазифа башкара. Биредә үткән унөч ел, ялгышулар-табышлар аны чын мәгънәсендә галим, укытучы, җитәкче һәм шәхес буларак формалаштыра. Әлеге факультетның педагогик һәм гыйльми базасын көчәйтүдә, дәрәҗәсен күтәрүдә Ф. Юсуповның да лаеклы өлеше бар. Галим һәм җитәкче буларак бай тәҗрибә туплап, 1984 нче елда галим кабат Казанга – олы фән дөньясына әйләнеп кайта һәм 1995 нче елга кадәр Татарстан Милли мәктәпләр институтының директоры вазифаларын башкара. Шулай да эрудицияле, киң карашлы галимне университет диварлары үзенә тарта: 1995 нче елда Фәрит Юсупов Казан дәүләт университетына чакырыла, татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетының татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасына

профессор буларак эшкә алына. Берничә ел Төркия университетларында һәм Төркия Чит илләр министрлыгында да эшләп ала.

Җитәкчелек вазифасы белән галимлек эшчәнлеген бергә үреп бара алу сәләте бик сирәк кешеләргә генә бирелә, Ф. Юсупов зур институт белән җитәкчелек иткән дәвердә – 1989 нчы елда – Казахстан Фәннәр Академиясенең Тел белеме институты каршында эшләп килүче докторлык диссертацияләрен яклау советында «Татар фигыльләрен ареал ысул белән өйрәнү» дигән темага докторлык диссертациясен яклый, бу диссертациясенең фәнни консультанты күренекле галим Ә.Р. Тенишев була. Әлеге хезмәт Мәскәү астыннан алып, Ерак Көнчыгышка кадәрге татар сөйләшләренең ареал лингвистик зоналарын, тел үзенчәлекләрен өйрәнүе белән татар тел белеменә яңалык алып килә. Татар диалектологиясе фәнендә беренче булып, галим өч диалектның классификацион билгеләрен ачыклау һәм аныклауга ирешә, *диалект теле* төшенчәсен гомумкулланылышка кертеп җибәрә.

Галимнең кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренең нигезе, дәвамы буларак дөньяга аваз салган «Көнъяк Урал Һәм Урал арты сөйләшләре» (1979), «Татар диалектлары. Урал сөйләшләре» (2003), «Красноуфим татарлары: тарих, тел, фольклор» (2003) дигән монографияләре дә татар тел белемен, диалектология фәнен бай фактик һәм гыйльми эзләнүләргә баета. Лингвистик география һәм системалы-синхрон методларны кулланып язылган әлеге монографияләрдә Урал географик зонасында таралган *красноуфим, нократ-кистем, эчкен, нагайбәк, сафакүл* сөйләшләренең формалашулары, этник тарихы, төп үзенчәлекләре тикшерелә. Лингвистик материаллардан тыш, архив материалларының, тарихи чыганакларның да урын алуы хезмәтләрнең актуальлеген, фәнни кыйммәтен тагын да арттыра, тикшерелә торган сөйләшләрнең татар диалект системасындагы урыннарын билгеләргә ныклы нигез булып тора.

Әлеге фикер-карашларын Фәрит Юсупов «Неличные формы глагола в диалектах татарского языка» (1985), «Изучение татарского глагола» (1986), «Морфология татарского диалектного языка: категории глагола» (2004) кебек зур күләмле хезмәтләрендә, күпсанлы мәкаләләрендә, чыгышларында да даими исбатлый, үстерә, камилләштерә. Галимнең фикер-карашлар «Tatar şive dilinin morfolojisi. Fiil kategorileri» исеме белән төрек телендә дә дөнья күрә (Анкара, 2013).

Ф.Й. Юсуповның «Татар теленең диалектлары. Урал сөйләшләре» (2003) хезмәтендә, архив материалларына таянып, Урал алды, Урта, Көньяк Урал, Урал арты төбәкләрендә яшәүче татарларның тарихы һәм сөйләшләре турында тулы мәгълүмат бирелә. Хезмәттә, системалы-синхрон, лингвистик география методларын кулланып, *красноуфим, нократ-кистем, нагайбәк, эчкен, сафакүл* сөйләшләре турында системалы күзаллау булдырыла, сөйләшләргә хас фонетик, морфологик, синтаксик үзенчәлекләр аерып чыгарыла [Юсупов, 2003].

Галимнең «Морфология татарского диалектного языка: категории глагола» (2004) монографиясе аерым игътибарга лаек. Бу китап татар теленең барлык

диалектлары һәм сөйләшләре турындагы материалны системага салган, төрки тел белемендә диалект телен система буларак модельләштергән беренче зур хезмәтләрдән саналырга лаек [Юсупов, 2004]. Ул Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы филология буенча укыту-методик берләшмәсе Россия Федерациясенең классик университетларының милли бүлекләре өчен дәреслек буларак тәкъдим ителә, Казан дәүләт университетында гуманитар фәннәр арасында үткәрелгән конкурста да 2005 нче елның иң яхшы фәнни хезмәте буларак җиңеп чыга.

Фәрит Юсуповның хезмәтләренә аны башкалардан аерып торган бер үзенчәлек хас: диалект теле белән янәшәдә ул үзе тикшерү объекты итеп алган сөйләш вәкилләренең тарихын, мәдәниятен, фольклорын да туплый, системага сала, тикшерә. Бу исә тел үзенчәлекләрен, аларның формалашу яссылыгын ачыграк тоярга ярдәм итә. Икенче яктан, Фәрит Йосыф улы хезмәтләре үзе туплаган, шәхсән үзе шул сөйләш вәкилләре белән аралашып җыйган материалга нигезләнеп языла. Галим озак еллар буена фәнни-диалектологик экспедицияләр белән җитәкчелек итә, сөйләшләрнең сөйләмә һәм язма әдәби үрнәкләрен бөртекләп җыя, картотекаларга туплап системага сала һәм хезмәтләрендә фәнни нигездә тикшерә. Шуңа да Фәрит Йосыповның монографияләре фәнни булу белән бергә фактологик, фактик материалга байлыгы белән дә игътибарны җәлеп итә. Мәсәлән, «Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты» (2006) монографиясендә Курган һәм Чиләбе өлкәләрендә яшәүче сафакүл һәм коншак татарларының тарихы, тел үзенчәлекләре һәм халык авыз иҗаты турында тулы мәгълүмат бирелә. Аларның килеп чыгышы бай тарихи әдәбиятка һәм архив чыганакларына таянып аңлатыла [Юсупов, 2006]. Халык авыз иҗаты, дини йолалар хакындагы материал тел белгечләренә генә түгел, әдәбият галимнәренә дә тикшерү нигезе итеп алырлык бай гыйльми чыганак булып бәяләнергә лаек.

«Бараба татарлары» (1913; Юсупов Ф.Ю., Сайфулина Ф.С., Хисамов О.Р., Гумеров И.Г.) хезмәте һәм себер татарлары диалектына караган дүрт томлык та (2014-2018) шушы сукмакны дәвам итеп, үстереп языла. Биредә себер татарларында яшәп килгән хикәят, риваять, мифлар, мәсәлләр, әкиятләр, музыкаль мирас тупланып бирелә, кереш мәкаләләрдә аларга хас специфик хасиятләр аерып билгеләнә, язылу, таралу тарихлары барлана.

Татарстанның Милли мәктәпләр институты директоры булып эшләгән елларында ук Татарстанда һәм Россиянең татарлар күпләп яши торган төбәкләрендә татар мәктәпләре, гимназияләре ачу юлында зур эшләр башкарган галим татар һәм рус балалары өчен уку-укыту программалары, дәреслекләр язуда да актив катнаша. Бу фикерне галимнең «Татарский букварь – Әлифба» (1994, 1998, 2012), «Татар теле. Татарский язык. 2, 3, 4 нче сыйныфлардагы рус телле укучылар өчен татар теле дәреслеге» (1993, 1998, 2006, 2010, 2013, 2014), «Рус телендә сөйләшүче балаларга әлифба укыту» (1996,1999, 2010), Татар теле. Татар мәктәпләренең 6 нчы сыйныфы өчен татар теле дәреслеге (1992, 1996, 2003, 2006, 2012), «Гөлбакча. Балалар бакчалары өчен хрестоматия» (1990), «Балалар

бакчасы. Балалар бакчалары өчен хрестоматия» (2003, 2013) кебек хезмәтләре-дәреслекләре дә раслый. Соңгысы хәзерге көндә дә балалар бакчаларында дәреслек функциясендә иркен файдаланыла. Биредә галим балалар өчен язылган җыр, шигырь, әкият, кечкенә хикәя, табышмак һ.б. жанрларга мөнәсәбәтле әсәрләрне яшь үзенчәлекләренә бәйле төстә туплап бирә [Балалар бакчасы, 2003].

Соңгы елларда галим үзенең эшчәнлеген диалектолог, тюрколог галимнәрнең фәнни мирасын кабат гыйльми кулланылышка кертү, аларны киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү юнәлешендә киң эшчәнлек алып бара. Аның тырышлыгы, яхшы мәгънәсендә үҗәтлеге нәтиҗәсендә шактый тюркологларның фәнни мирасы кабат киң катлам татар укучысына «әйләнеп кайтты». Мәсәлән, 2014, 2017 нче елларда басылып чыккан «Фәнни мәкалә һәм очерклар җыентыгы»ның ике томлыгы шул хакта сөйли. Биредә Фәрит Йосыф улы Н. Катанов, Е. Малов, А. Бессонов, Җ. Вәлиди, Л. Җәләй, Д Тумашева, Л. Мәхмүтова, Н Борһанова, Ф. Фасеев кебек диалектология өлкәсендә тирән эз калдырган галимнәрнең фикер-карашларын бергә туплый, аларның тарих тузанына капланып калган, әмма әле дә актуальлеген югалтмаган мирасларын бүгенге укучыга кайтара.

Үзенең шәкертләре даирәсендә Фәрит Йосыф улының аерым урыны бар. Ул безне – шәкертләрен – һәркайсыбызның холкын-фигылен, мөмкинлекләрен тоеп, дөньяга карашын бизмәннәрдә үлчәп, фән дөньясына әзерләде. Алай гына да түгел, тормышны, кешеләрне «таныргa» өйрәтте, мең борылышлы, шактый катлаулы фән дөньясының байтак нечкәлекләренә төшендерде. Без аны хезмәттәшләре, шәкертләре исеменнән чын күңелдән олы юбилее белән котлыйбыз һәм алга таба да фәнни куәс теләп калабыз.

**Әдәбият**


Балалар бакчасы: Әти-әниләр һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен уку китабы / Төз. Ф. Юсупов, Г. Юсупова, Ф. Хамидова. – Казан: Раннур, 2003. – 656 б.

Юсупов Ф.Ю. Татар теленең диалектлары: Урал сөйләшләре. – Казан: Мәгариф, 2003. – 351 б.

Юсупов Ф.Ю. Морфология татарского диалектного языка: категории глагола. – Казань: Фэн, 2004. – 592 с.

Юсупов Ф.Ю. Сафакүл татарлары: тарих, тел, халык иҗаты. – Казан, 2006. – 608 б.

*Юсупов Рузаль Абдуллазянович*
*Казанский федеральный университет*
*Казань, Россия*
*Yusupov Ruzal Abdullaziynovich*
Kazan Federal University
Kazan, Russia

# КАК СОХРАНИТЬ РОДНОЙ ЯЗЫК?
# HOW TO SAVE NATIVE LANGUAGE?

Аннотация. *Статья посвящается вопросу о сохранении и развитии литературного татарского языка. Рекомендуя начинать реализацию этой важнейшей задачи с разработки и принятия специальной государственной программы, автор описывает механизмы усиления заинтересованного отношения населения к изучению и употреблению родного языка, воспитания уважения к своему народу, его культуре и языку, а также пути повышения культуры речи.*

Annotation. *The article is devoted to the preservation and development of the Tatar literary language. Recommending to begin implementation of this most important task with the development and adoption of special state program, the author describes the mechanisms of strengthening of interested attitude of the population to the study and use of native language,of education of respect for the people, its culture and language, and also ways to improve the culture of speech.*

Ключевые слова. *Родной язык, сохранение, развитие, обучение, культура речи, национальная школа.*

*Keywords. Native language, preservation, development, education, speech culture, national school.*

В беседах с различными людьми, в выступлениях многих представителей духовной сферы в последнее время небезосновательно проявляется большая озабоченность по поводу состояния и перспективы татарского языка. Для каждого здравомыслящего человека должно быть понятно, что положение с татарским языком становится все более тревожным: масштабы употребления его неуклонно сужаются, количество владеющих им всемерно сокращается, уровень культуры родной речи падает, язык средств массовой информации изобилует грубыми нарушениями лексических, фонетико-орфоэпических, грамматических и стилистических норм литературного языка.

Проблем с употреблением и изучением татарского языка было немало и в предыдущие периоды, после же непродуманного изменения системы обучения родным языкам, ограничив объем времени преподавания их в школе двумя часами в неделю и лишь по желанию родителей, ситуация с изучением и знанием татарского языка становится еще более омрачительной. Бесспорно: если не принять безотлагательные и кардинальные меры, судьба развитого татарского литературного языка будет печально предрешена, рассчитывать на

благополучный исход и строить благостные иллюзии не приходится. Пришло время бить в колокола.

Что же нужно сделать, какие меры следует предпринимать, чтобы остановить процесс утери позиций и падения престижа татарского языка? Вопрос не праздный и нахождение на него правильного ответа с тем, чтобы его успешно реализовать, имеет непосредственное отношение к вопросу о сохранении родного языка татар, их культуры и в конечном счете самих как нации.

Отвечая на свой вопрос, попытаемся изложить, какие пути и средства, на наш взгляд, имеются для восстановления былой значимости и расширения функций и развития современного татарского языка.

Разумеется, эта архиважная задача может быть успешно реализована лишь при активном участии в этом процессе как самих носителей языка, то есть самого татарского населения, так и соответствующих органов власти Татарстана. При этом решающее значение будут иметь действия руководства республики. Без инициативы и усилий президента, парламента и правительства в этом деле успеха не будет.

С чего следует приступить к реализации задачи сохранения и развития татарского языка?

Начинать необходимо с разработки и принятия специальной государственной программы развития татарского языка, в которой должны быть тщательно, глубоко, во всех деталях продуманы механизмы повышения заинтересованного отношения татарского населения к изучению и употреблению родного языка, воспитания любви и уважения к своему народу, его культуре и языку, способы привития его носителям чувств национального достоинства и гордости. Важнейшей задачей этой программы, как нам представляется, должно быть четкое описание путей и средств коренного улучшения обучения татарскому языку учащихся и студентов, а также повышения у населения культуры родной речи. Разумеется, задачи реализации программы развития татарского языка должны будут предполагать выполнение комплекса мер, направленных на повышение уровня знаний населением своего языка, эффективности преподавания его, что потребует совершенствования системы изучения в учебных заведениях родного языка, укрепления их материальной базы, повышения стимулирования учителей и усиления требовательности к преподавателям и обучающимся за качество знаний и т.д.

Какие же конкретные действия правительства Татарстана должны быть предусмотрены в этой программе?

В основе восстановления и повышения престижа татарского языка, всеобщего вооружения населения знаниями этого языка и расширения масштабов его функционирования естественным образом лежит максимальный охват молодого и среднего поколения татар результативным обучением своему родному языку. Такая задача предполагает серьезное совершенствование преподавания татарского языка, что в свою очередь не может быть выполнено без того, чтобы

повернуться лицом к этой сфере образования. Ведь не секрет, что к организации обучения татарскому языку в основном всегда относились как ко второстепенному предмету, по остаточному принципу, как находящемуся по рангу после таких дисциплин, как русский язык, математика и другие. Если мы действительно хотим повышения престижа татарского языка, то позитивное изменение должны начать именно с перелома в отношении к обучению этого языка. Татарский язык - это родной язык многомиллионной передовой нации с высокой культурой, народа, некогда имевшего свою государственность и активно участвовавшего в создании и содержании российского государства. Поэтому и отношение к этому языку, как и самому носителю его, должно быть уважительное, и процесс изучения его в учебных заведениях должен быть организован самым серьезным образом. Следовательно, учебный предмет «татарский язык» надо считать таким же важным, нужным, как и все другие дисциплины. И условия для его изучения должны быть нисколько не хуже, чем освоения других предметов. Святой долг руководства республики - с учетом сложной ситуации с татарским языком, безотлагательно создавать лучшие условия для изучения его - открывать современные престижные татарские школы и классы, обеспечивая их высококвалифицированными учительскими кадрами, оснащая соответствующим учебным оборудованием, необходимой литературой и, основываясь на законе о языках, изыскать возможность стимулировать учителей татарского языка и литературы материально.

Для ускоренного строительства новых татарских школ в случае необходимости следует привлекать и частный и, возможно, иностранный капитал: для такого святого дела, как обучение родному языку, все средства хороши.

